КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№ 21
8 декабрь
1995 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

БҮГЕНГЕ САНДА:

2 *Нияз АКМАЛ.* «Музыканың чуарлануы»на, «шигырьнең ваклануы»на, бер-бер артистканың «фәлән төрле киенеп» чыгыш ясавына зарланып язылган әсәрләр — алар әле әдәби тәнкыйть түгел.

14 *Разил ВӘЛИЕВ.* Мин АКШ Конгрессы китапханәсендә шагыйрьләребез Зөлфәт, М.Әгъләмов, Р.Әхмәтҗанов, Ф.Сафиннарның китапларын күрдем.

15 *Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА.* Татар авылларында аракы хәзер төнлә дә сатыла, самогон чишмә булып ага, көмешкә куучыларны эзәрлекләгән кеше дә юк.

20 *Зәки ЗӘЙНУЛЛИН.* Генерал Дудаевның кулында 600гә якын атом коралы булуы мөмкин.

Милли гөлләр бакчасында ул бер мәшһүр бакчачы...

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Адәм баласы мәрхәмәтле туган җирендә дә көчкә-көчкә җан асрар хәлгә төшәргә мөмкин. Хәзерге җаһил заманда өлкәннәрнең ялгыз калуы аеруча куркыныч. Мамадыш районы Кече Кирмән авылыннан безгә хат юллаучы Миңнур апа бүгенге көндә нәкъ менә шундый хәвефле язмышка дучар: өе җимерек, утыны юк, ашарына такы-токы, йорт әйберләре урланган... Хөрмәтле кирмәнлеләр, колхоз һәм авыл советы рәисләре, район җитәкчеләре! Моңарчы әллә кемнәргә ялварып караган якташыгызны күрә-ләтә әҗәл тырнагына бирмәгез инде. Татар авылында миһербанлык саекмагандыр бит әле, иншалла, саекмагандыр...

Зиннур МАНСУРОВ

МИН ӘЙТТЕМ

Бервакыт шулай, иртәнге якта, ишегемне шагыйрь Мөдәррис Әгъләм как-ты. Өйгә узуын үтенүемә карамастан, ишек төбендә туктатты да, кесәсеннән бер бит кәгазь чыгарды:

— Тыңла әле! — диде. Мин тыңладым, аның тавышыннан күршеләр уяныр дип тә курыкмыйча тыңладым. Шигырь яхшы иде. Тәэсирләндерә иде. Мин хәзер инде, шактый еллар үткәннектән, аны тулысынча хәтерли алмыйм. Әмма хәтердә нык сакланган юллар бар:

Ачыгыз тәрәзәгезне,
Тәрәзәгез булса!..

Мин ул шигырьне йотлыгып тыңладым. Ләкин соңыннан, чәйләр эчеп чыккач, Мөдәррисне озатканда кинәт, әйтеп ычкындырдым:

— Карале, теге ике юл алдыннан, бәлки, бүтәнчәрәк юллар кирәктер. Мәсәлән:

Дәүләт башында утырыр
Дәрәҗәгез булса —
Ачыгыз тәрәзәгезне,
Тәрәзәгез булса?! — дидем.

Баш тартты. Башын кинәт кырын гына салып:

— Син нәрсә, тәнкыйтьче булдыңмы әллә? — диде. Шуның белән ул миңа үзенең киңрәк уйлар уйлавын аңлатты. Әйе шул, шигъриятнең сүзе-үгы аерым кешеләргә генә түгел, ә бик күпләргә — меңнәрчә-меңнәрчә кешеләр игътибарына төбәлгән, төбәлергә тиеш еллары иде...

Хәер, хәзер дә шулай. Тик минем сүз бу хакта гына түгел. Сүз, гомумән, әдәби тәнкыйть хакында. Әле күптәнме соң (инде шактый еллар элек икән) Рафаэль Мостафин үзенең «Тәнкыйтькә тәнкыйть» исемле язмасы белән сискәндергән иде. Әле күптәнме соң мәрхүм Фәрваз Миңнуллин Язучылар берлеге каршында яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәге оештырып, аны үстереп җибәрергә өметләнеп караган иде?! Әле күптәнме соң...

Менә шул «әле күптәнме соң» дигән еллар узганнан соң татар язучылары арасында «Бүгенге көндә әдәби тәнкыйть кирәкми, әнә, Көнбатышта андый тәнкыйть юк, китап язмышын базар хәл итә», — кебек сүз ишетелде.

Бу фикернең урнашып китүе хак: бүгенге көндә татар әдәбиятында әдәби тәнкыйть юк дәрәҗәсендә. Әдәби тәнкыйть исеме астында, гадәттә, бер-бер китапка рецензия (анысын да аннотация дәрәҗәсендә дип аңлау кирәк), күзәтү-мактау, библиографик ысулда язылган мәкалә, инде дә булмаса «Олуг юбилей уңае илә» туган мәдхияләр генә күренә. Нәкъ менә шундый хәлне, нәкъ менә шундый фикерләрне күздә тотыптыр, татарның бер бөек шагыйре — базар шартларында яшәгән шагыйре — «Тәнкыйть кирәкле шәйдер» дип язып калдырган!

Әйе, тәнкыйть кирәкле шәйдер. Мин монда, һич тә икеләнмичә, XIX гасырның демократ тәнкыйтьчеләрен күз алдыма китерәм. «Кому на Руси жить хорошо?» дип елап язган Некрасовка Глеб Успенский нинди киная ташлый?! Халыкны кызганудан гына

Нияз АКМАЛ

Талантлырак булыгыз, талантлар!..

зур файда юклыгын, ә бәлки аның үзенә үз мескенлеген күрсәтеп көлү кирәклеген ул әйтеп чыкмыймы?

Ярар, Успенскийны да, Добролюбовны да, Писаревны да — барысын да калдырып торыйк. Кайтыйк әле «үзебезнең» бүгенге урыс һәм татар «демократлары»на: әйтик, бүгенге көнебездә матбугатта еш пәйда булган, газетләрдә ялкынлы тәнкыйть сүзе белән чыккан каләмдәшләргә! Юк, әдәби тәнкыйть турында сүз дә юк. Сүз — тәнкыйть турында гына. Бу тәнкыйть мондый күренештә:

1) социализмны һәм коммунистларны сүгү, 2) урысларны, шовинистларны һәм Мәскәүне сүгү, 3) үзебезнең «тарлыкны һәм татарлыкны» сүгү, 4) Татарстанның эреле-ваклы җитәкчеләрен, бакча-сарай салучыларны «фаш итү», эчкечелеккә һәм фәхишәлеккә, эшмәкәрлеккә һәм акча юклыкка ачыну, сугышта җиңелеп бетмәгән сугыш ветераннары белән якалашу...

Йә шуннан, шуннан, тагын нәрсә бар?! Ә, минемчә, матбугат сүзе — әдәби тәнкыйть сүзе — нәкъ менә шул эреле-ваклы сүгенү-зарланулардан күп тапкырлар югарырак булган, бүгенге һәм киләчәк көннең мәгънәсен фәлсәфи (тирән фәлсәфи!) уйлар аша аңлатып-әйтеп бирә белгән сүз булырга тиеш! Әдәби тәнкыйть, минемчә, нинди дә булса әдәби күренешкә бәя биреп кенә калмаска, ә бәлки әдәбиятка юнәлеш тә бирә алырга тиеш!

Минем абыем, мәктәп укытучысы, моннан бик күп еллар элек, әле хәзер үзе укыткан сигезьеллык мәктәпнең алтынчымы-җиденчеме сыйныфында укыган чагында шундыйрак шигырьләр язган, аны район газетендә бастырган иде:

Әбүгалисина кебек
Тылсым иясе булсам,
Кайда нәрсә эшләнгәнен —
Барын да белеп торсам, —
Крокодиллар мыжлап торган
Тирән күл ясар идем,
Патрисны үтерүчене
Шул күлгә ташлар идем...

Йә булмаса, болай:

Африка уяна,
Өзә богауларын —
...Вулкан булып яна
Батырларның каны!
Сим агай борчыла,
Китә, дип, калҗалар.
Улый сатлык җаннар —
Африкада пожар!..

Әй, абый, Нәҗип абый... Шул үсмер елларында ул бу шигырь юлларын, мөгаен, пропагандистик сүзләр тыңлап-ишетеп-укып язгандыр инде. Ләкин... үзенең шул үсмер күңеле белән, мөгаен, ул тагын бер нәрсәне тойган: Африка илләрендә, Латин Америкасы илләрендәге кебек үк дөньяны бүлешү бара. Үсмер егетнең күңеле гаделлек ягында калырга теләгән. Пабло Неруданың, Виктор Харaның ничек һәлак булуын яңа буын инде белми.

«Любовь Габриэллы» исемле искиткеч бер романны урысчадан Кыям Миңлебаев тәрҗемә итте. Бразилия язучысының (авторның исемен хәтерләмим инде) һәйбәт романы иде ул. Әлеге тәрҗемә әсәрне Татарстан китап нәшрияты миңа эчке рецензия язарга тапшырган иде (китап булып чыкканчыга кадәр, элегрәк шундыйрак эш тә эшләнә иде). Ул китапның урысчасын минем бер танышым да укып чыккан икән. Минем аның тәрҗемәсенә эчке рецензия язарга тиешлегемне, әсәр белән танышып йөрүемне ишеткәч, ул әйтте:

— Ну, шәп тә китап инде, андагы мәхәббәт, андагы секс! — диде. — Укыганда да чәчләрең үрә тора! — диде.

Белмим, ул шаяртып әйттеме, әллә чынлапмы, ә китапта чыннан да чәчләр үрә торырлык хәлләр сурәтләнгән иде. Анда хәтәр бер вакыйга — Бразилиянең ничек итеп колониягә әйләнеп калуы сурәтләнгән һәм шушы хәтәр вакыйга мәхәббәт-секс уены һәм депутатлыкка сайлану «шухыр-мухыр»ы астына яшерелгән иде. Менә шулай шул...

Без хәзер үзебез дә дөнья бүлешүнең үзәгендә торабыз. Әле соңгы гасырга килсәк, мондый бүлешүнең иң зурларыннан берсе Беренче бөтендөнья сугышы, икенчесе — Икенче бөтендөнья сугышы (мин дә аны Ватан сугышы дип әйтмим бит әле) булды. Һәм менә өченчесе хәзер бара.

Безнең «тәнкыйтьчеләр» исә әле чүп-чар бүлешүдән уза алмый. Йә шунда, үзе дә аңламыйча, сугыш ветераннарын хурлап алган була, йә шунда инде күптән юкка чыккан коммунистлар партиясенә тибеп уза. Юк, тибеп узулары — һич тә үзмаксат түгел, болар да «дөнья бүлешә». «Тәнкыйть утын яудырып» авторитет яулый, исем яулый, акыл-фикер иясе булып исәпләнергә хокук даулый.

Матбугатта чыккан башка шундый — хәтта бик кызыклы язылганнарының — тәнкыйть мәкаләләренең дә хәл-халәте шул алар тәгәл адрессызлык белән, фәлсәфи фикерсезлек белән авырыйлар. Аларның күбесе үгет-нәсыйхәт формасында. Алар дәлилле дә, дәлилсез дә. Аларга хәтта җавап бирердәй зат та юк.

Әдәби тәнкыйтьнең бер өлеше — тарихи-библиографик өлеше — бүгенге көндә галим-голәма кулында. Мин галим халкына һәрчак сокландым. Аларның кулында күпме материал, күпме рухи байлык, әдәби мирас?! Алар, архив тузаннары эчеп, ничәмә-ничә еллар буена әнә шул мирасны барлап-яшәтеп килделәр. Ә «теге» елларда, үзегез беләсез, тел һәм әдәбият галимнәре иң кирәкле-кадерле кульязмаларны матбугатта да чыгара алмадылар, үз эшләре буенча фәнни-гыйльми дәрәҗә дә аларга һай авыр килде, акчасы-абруе да түбән иде. Соңгы вакытта юл ачылды әмма... Әлеге галимнәребезнең күбесе бүген шундый хәл-тәсмердә: алар, әйтерсең, үзләре тапкан-барлаган кульязмаларны басма матбугатка һәм радио-телевидениегә ташучылар гына. Ул да файдалы эш! Ул да кирәк халкыбызга күпме рухи мәгълүмат алып килебез бит! Әмма... Кайда соң әдәби тәнкыйть? Әлеге галимнәребезнең әлеге дә баягы кыйммәтле кульязмаларга кереш сүзе, күзәтүе, тәкъдим итүе кебек аннотация-хәбәрдән югарырак булырга тиешле гыйльми фикер кайда?

Әйе, әдәби тәнкыйть үз югарылыгында булырга тиеш. Әмма «музыканың вакланып чуарлануы»на, «шигырьнең ваклануы»на, бер-бер артистканың «фәлән төрле киенеп» чыгыш ясавына зарланып язылган әсәрләр — алар әле әдәби тәнкыйть түгел. Ә бәлки әлеге чуарлык шул югары дәрәҗәдәге тәнкыйтебез булмаудан киләдер?

Сүземнең азагында шагыйрь Равил Фәйзуллинның «Сәйдәш» поэмасындагы юлларын юри сайлап алдым. «Усалрак булыгыз, талантлар!..» — дип язган иде ул. «Теге» еллар шундый сүзләрне таләп иткәндер. Сәйдәш язмышы аша шагыйрь үз тарафдарларын, гомумән, «яшь вә ят алмаш»ка шундый таләп куярга теләгәндер. Ләкин бүгенге көннең әдәби тәнкыйте турында, көннең хәл-халәте турында язучыларга минем әлеге сүзләрне чак кына үзгәртеп әйтәсем килә: талантлырак булыгыз, талантлар! Ә инде язманың исем башында телгә алынган юлларны искә төшерсәк, Мөдәррис Әгъләм минемчә бүген ул теге, мин өстәгән сүзләрдән дә баш тартыр иде. Юк, баш тартмас иде, киресенчә, әйтер иде:

— Үзегез языгыз, ямә! — диләр иде. — Дәүләт башында утырыр дәрәҗәгез булса...

Җидегән 1 2 3 4 5 6 7 вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

Журналларда кеше язмышлары

«Казан» милли мәдәният үзәгендә «Татарстан» журналының чыга башлавына 75 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды Октябрь ватаны халыклары белән каршылыклы һәм катлаулы заманалар кичеп, үзенең чын асылына кайткан журналны олуг бәйрәме белән Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев, шулай ук мәгълүмат һәм матбугат министры Ислам Әхмәтҗанов, Казан шәһәр хакимияте башлыгы урынбасары Наил Хөснетдинов, Татарстан Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов, Совет, Вахитов районнары хакимияте башлыклары Альберт Камалов, Сабирхан Мөхәрләмов һ.б.лар тәбрикләде. Юбилярны республикада чыга торган гәзит һәм журналлар вәкилләре, шул исәптән «Мәдәни җомга» атналык басмасының баш мөхәррире Зиннур Мансуров, сәнгать осталары котлады

Тантаналы кичәдә дөнья күләмендә танылган әдәбият һәм сәнгать әһелләре Петр Проскурин, Михаил Боярский, Вилли Токарев, Никита Михалков, Галина Волчек, Мәхмүт Эсенбаев, Фоат Мансуров һ.б.ларның бик җылы тәбрикләү телеграммалары да укылды. Һәрнәрсәгә ышанмыйча караган кайбер кешеләрдә сорау да туарга мөмкин «Үзләренең гомерләрен элекке «Татарстан коммунисты»ннан башка күз алдына китерә алмаучы» әлеге күренекле шәхесләр бәйрәм уңаеннан мөхтәрәм язучыбыз һәм җәмәгать эшлеклесе, журналның баш мөхәррире Рафаэль Мостафинның үзен котламадылар микән?! Хәер, барыбер түгелмени? Журнал юбилее көнендә җылы сүзләрен ирештерүчеләр бит.

Шашурин акланмады

Русия Федерациясе Югары судының суд коллегиясе Татарстан Республикасы Югары судының Сергей Шашуринны хөкем итү турындагы карарын үз көчендә калдырды. Шулай итеп, хөкем ителүченең адвокатлары язган кассацион шикаять канәгатьләндерелмәде.

Шашурин тикшерүче Б.Логиновка сорау алу вакытында көч кулланганы өчен бер ел да тугыз айга хөкем ителгән иде.

Казан шәһәренең Совет районы судында Сергей Шашуринны зур күләмдә салымнар түләүдән читләшүдә гаепләгән тагын бер җинаять эше тикшерелә.

Кемне нәрсә борчый

«Комсомольская правда» гәзите редакциясе РФ Премьер-министры Виктор Черномырдин белән телефон аша туры элемтә оештырды. Хөкүмәт җитәкчесе икә сәгать буенча Русия белән сөйләште. Элемтәгә көрүчеләрнең зур күпчелеге үзе яшәгән өлкә, республика мәнфәгатьләрен, шулай ук шәхси ихтыяҗларын кайгыртып, Виктор Степановичка төрледән-төрле сораулар бирергә ашыктылар. Ә Татарстаннан бердәнбер шалтыратучыны, атап әйткәндә, Ирек Дәүләтшинны нәрсә борчый соң? Русия хөкүмәте башлыгына ул мондый киңәш бирде: «Беләсезме, миндә зур сәяси сиземләү сәләте бар һәм мин беркайчан да ялгышмыйм. Виктор Степанович, Русия президентлыгына сайлауларда Сезгә үз кандидатурагызны күрсәтергә кирәк. Сез һичшиксез үтәчәксез...»

Телефон чыбыгының Мәскәүдәге очыннан мондый җавап ишетелде: «Рәхмәт, Ирек. Хәзер безгә Борис Николаевич Ельцинны якларга кирәк. Ул Русия өчен әле бик күпне эшли ала...»

Менә шулай, милләттәшебез Ирек. Ә исемең шулкадәр күңелгә ятышлы һәм бик мәгънәле икән.

Казан артын беләбезме?

Кичә Биектауда башланган Беренче җирле фәнни-гамәли конференция Казан арты тарихына, мәдәниятенә, мирасына кагылышлы мәсьәләләрне күтәрә. Анда Идел-Вятка елгалары арасындагы тарихи һәйкәлләребезне саклау, өйрәнү, тыюлыклар турында сүз барды.

Конференциядә җитмештән артык фәнни чыгыш ясалды.

«Казан арты тарихы һәм мәдәнияте мәсьәләләре»нә багышланган әлеге очрашу бүген Казанда «Археология», «Казан арты халкының этник тарихы һәм тарихи-мәдәни бәйләнешләре», «Тарих һәм мәдәният сораулары», «Туган як тарихы» секцияләрендә дәвам итә.

ЕЛМАЙТА ТОРГАН ЯҢАЛЫК

Президентка кисәтү

Көтмәгәндә Жириновскийны рэкетирлар урлап киткән. Ельцинга шалтырата болар: «Илле миллион доллар түләсәгез генә кайтарабыз!» Президент авыр сулап куйган: «Моның кадәр акча миңа каян килсен?!» Рэкетирлар: «Теләмисез икән — кирәк түгел. Без сезне кисәттек. Иртәгә аны иреккә чыгарачакбыз...»

3 нче гимназиягә биш яшь

Заманында бик зур кыенлыклар белән Казанда беренчеләрдән булып ачылган 3 нче гимназия үзенең бишенче туган көнен уздырды. Ата-аналар, укучылар, укытучылар, химаячеләр җыелган бу бәйрәм бик күңелле узды. 10 нчы мәктәп канаты астына сыенган гимназиядә 300ләп укучы белем ала. Биредә сыйныфлар түгел, кафедралар эшли. Башлангыч укыту һәм тәрбия, табигать фәннәре һәм төгәл фәннәр, гуманитар фәннәр, чит телләр, сәнгать һәм музыка кафедралары Казан дәүләт университеты һәм педагогик коллият укытучылары белән бәйләнештә тора, студентлар биредә педагогик практика үтә. Шунда ук музыка мәктәбе эшли. «Сәфәр» вокаль-инструменталь ансамбле, курайчылар, баянчылар кунакларга бик матур концерт күрсәтте.

Хатын-кыз азрак эшләргә тиеш

«Моннан берничә ел элек балалы хатын-кызларга һәр айда 1 көн өстәмә ял бирү турында закон кабул ителгән иде. Кайбер оешмаларда аена бер көн ял бирү урынына һәр атнада хатын-кызларны җомга көнне төшке аш вакытында ук өйләренә кайтарып җибәрәләр, ә кайберләрендә әнә шул 1 көн ял хисабына балалы хатын-кызларның эш сәгатьләрен 30 минутка кыскартканнар. Болар барысы да закончамы, юкмы?

С.Галиуллина, Казан шәһәре.
И.Зөбәерова, Сарман районы».

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 1991 елның 14 июнендә чыккан 261 номерлы карары нигезендә 16 яшә тулмаган баласы булган хатын-кызларга атна дәвамында ике сәгатьтән дә ким булмаган өстәмә ял вакыты бирелергә тиеш. Моннан файдаланмаган очракта ай саен бер көн өстәмә ял көне бирелә. Бу ял көне айныкы айда бирелеп барыла һәм ел саен бирелә торган ялга кушылмый.

Инде шул өстәмә ял хисабына эш көнен 30 минутка кыскартуга килгәндә, бу вариант та закон тарафыннан тыелмаган. Атна саен ике сәгатьтән дә ким булмаган ялны бүлгәләпмә, әллә бүлгәләмичә генә бирергәмә, дигән сорауга төгәл җавап юк. Әмма атна саен бирелә торган ялны бергә кушып аена бер көн өстәмә ял көне бирү каралган икән, нишләп соң шул ике сәгатьне һәр көнгә бүлгәләп биреп булмаска тиеш, ди.

Хатыннарга ирләреннән өйгә алдарак кайтып төмлә ризык әзерләр өчен әнә шул ярты сәгать вакыт кына җитми бит инде, җомәгать.

Назыйм САФИН, юрист



Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры

Атналык программа

(Декабрь)

8. Җомга	Лопе де Вега **БИЮЧЕ** Комедия	
9. Шимбә	Татарстанның халык артисты Һидият Солтановның иҗат кичәсе	
10. Якшәмбе (Көндез)	Аманулла **ӘЛЕПЛЕ ӘРТИСЛӘРЕ** Комедия	
12. Сишәмбе	Туфан Миңнуллин **ГӨРГӨРИ КИЯҮЛӘРЕ** Комедия	
13. Чәршәмбе	Гаяз Исхакый **ҖАН БАЕВИЧ** Комедия	
14. Пәнҗешәмбе	Туфан Миңнуллин **ГӨРГӨРИ КИЯҮЛӘРЕ** Комедия	
15. Җомга	Туфан Миңнуллин **ИЛГИЗӘР + ВЕРА** Драма	

Хезмәтенә күрә хөрмәте

*Татарстан Республикасы Президенты Указы белән актив фәнни эшчәнлек алып барган өчен **Балтач районы, Чепья авылы Халыклар дуслыгы музее коллективы Татарстан Республикасының Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.*

*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе рәссам **Рәшит ИМАШЕВКА** Башкортстан Республикасы Президенты Указы белән **«Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.*

ҖОМГАДАН — ҖОМГАГА

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

Үткән чәршәмбедә башланган Дәүләт Советы сессиясендә Татарстан Республикасы Президентының 1996 елга бюджет юлламасы карала.

Татарстан Министрлар Кабинеты карары белән Әтнә районы Комыргуҗа урта мәктәбенә Шиһабетдин Мәрҗани, ә Күлле Киме урта мәктәбенә шагыйрь Сибгат Хәким исемнәре бирелде.

Татарстан дәүләт милли университеты булдыру җәһәтеннән «Татарстан Республикасында халыкларның телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру турында» Дәүләт Советы карары нигезендә Татарстан Министрлар Кабинеты Татарстан гуманитар югары уку йортын булдыру буенча оештыру комитетының составын раслады.

Күптән түгел вафат булган Сергей Абуладзе урынына республика клиник хастаханәсенең баш табибы итеп сәламәтлек саклау министры урынбасары булып эшләгән Разин Фатыйхов билгеләнде.

9-10 декабрьдә «Болгар» физкультура йортында Әнәс Шәрәфетдинов истәлегенә самбочыларның икенче республика турниры үткәреләчәк.

Тинчурин театрында премьера

ИГЪЛАК БУЕНЧА ӨЙЛӘНҮ

Әлеге моңсу комедия В Константинов һәм Б.Рацер әсәре буенча куелган. Аны Татарстанның атказанган артисты Нуретдин Нәҗми тәрҗемә иткән.

Фәүзия ролендә Русиянең һәм Татарстанның атказанган артисткасы Исламия Мәхмүтова. Дилбәр — Татарстанның халык артисткасы Һаҗәр Шәкүрова. Әсфән — Татарстанның атказанган артисты Әнәс Галиуллин, Ислам — Татарстанның атказанган артисты Нуретдин Нәҗми.

Спектакльгә музыканы Мәсгуд Имашев язган.

◉ Спектакльнең режиссеры Рәшит Заһидуллин (уртада) премьера алдыннан соңгы күрсәтмәләрне бирә.

Әкрам ШӘФИГУЛЛИН фотосы.

«Ике урман арасы»нда Сайрый былбыл баласы

Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев җитәкли торган «Шагыйрь остаханәсе» утырышлары гадәттә Язучылар берлегендә уза торган иде Бу юлы остаханә үзенең чираттагы утырышын «Ватаным Татарстан» газите редакциясенең музеенда үткәрде. Утырыш шагыйрь Зөлфәт иҗатына багышланган иде. Моңа матур сәбәп тә бар Татарстан китап нәшрияты «Шигырь китапханәсе» сериясендә Зөлфәтнең «Ике урман арасы» исемле сайланма әсәрләрен бастырып чыгарды «Шагыйрь остаханәсе» шушы китапны киң катлам укучыларга тәкъдим итте

Шагыйрьне яңа китабы белән котларга бер төркем язучылар. сәнгать әһелләре. каләмдәшләре килде И Юзеев. Р Гаташ. М Әгъләмов. Н Гамбәров Ш Галиевләр Зөлфәт һәм аның китабы турында үз фикерләрен әйттеләр Иҗат бәйрәменә әйләнгән бу утырышта Зөлфәтнең шигырьләре. аның шигырьләренә язылган җырлар яңгырады.

Өстәлдә ак кәгазь...

Без танылган фантаст-язучыбыз **Адлер ТИМЕРГАЛИННАН** телефон аша.

— Соңгы вакытта каләмегездән ниләр тама? — дип сорадык.

— Бу араларда мин эшләгән эшләр фантастикадан бик ерак тора бит әле Әйтик, 11 нче сыйныфлар өчен астрономия дәреслеге тәрҗемә иттем һәм иң мөһиме — йолдызларны. планеталарны татарча. төркичә Шәрык телләренә хас булган исемнәр белән атарга тырыштым Төрки телләрдә бит аларның үз исемнәре бар ул халыклар күк җисемнәрен яхшы белгәннәр Бу исемнәрне мин гомерем буе җыйдым барладым Аннары без бәләкәй чакта Мөслим районында метеорит төшкән иде. шуларны да кыстырып дәреслекне мөмкин кадәр укырлык итәргә тырыштым

Каләмнән төшкән башка әйбер юк әле хәзергә Шулай да бер зур әйбернең караламасы эшләнеп бетте диярлек Ләкин фантастика түгел Кайбер татар кешеләренең бала чакта ук Германиягә барып эләгеп. аннары әйләнеп кайтып һәлак булулары турындагы әсәр караламасы ул

Аннары элек тыелган китапларны укып тәм табам Бик яхшы әсәрләр укыгач, язасы да килми

Сары, ак, зәңгәр

битле китапны күргәнегез бармы? Булмаса, менә шул — бик матур итеп Финляндиядә басылган телефон белешмәсе ул. Анда телефон номерлары гына түгел, предприятиеләрнең төрләре һәм эшчәнлекләре турында мәгълүматлар бирелә. Ул аерым кешеләргә, төрле предприятиеләргә, чит ил инвесторларына эшләрендә бер-берсен табарга мөмкинлек бирә.

Сары. ак, зәңгәр битле итеп телефон белешмәсен 80 ел элек АКШта чыгара башлаганнар Аны инде хәзер Австралиядә, Яңа Зеландиядә дә шулай эшлиләр икән Ниһаять, ул стандарт Русиягә һәм безнең Казанга да килеп җиткән Бездә аны ТЕРРА агентлыгы бастыра.

Кыр үрдәге белән... каз өмәсе

Төмән өлкәсенең Салехард шәһәрендә татар-башкорт мәдәни үзәге эшләп килә. Күптән түгел мәдәни үзәк шәһәрдә яшәүче милләттәшләребез өчен «Каз өмәсе» бәйрәме үткәрде Салехард шәһәре тирәсендә казлар юк — алар котыпта яши алмыйлар Хатын-кызларга каз урынына кыр үрдәге йолкырга туры килде. 11 кыр үрдәген шәһәрдә яшәүче татар эшмәкәрләре атып китергән иде.

Кяферләргә «азык» биргән өчен хәзрәткә ни диярләр икән?

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бинасы тирәсендәге вакыйгаларны күпләр онытканнардыр да инде Алдагы көннәрдә бу хәлләрнең төп «каһарманы» Габдулла хәзрәт исеменең янә матбугатта күренүе мөмкин Хәзерге вакытта тикшерүчеләр Казан үзәгендә булып үткән вакыйгаларны җентекләп өйрәнәләр һәм аларның фикере халыкка җиткерелер дип уйлыйбыз. Республика мөселманнары Диния нәзарәтенең тиздән булачак корылтае да Габдулла хәзрәтнең гамәлләренә тиешле бәя бирер дигән өметтә калабыз Чөнки аның гамәлләре мөселман динендәге бәндәне, әле җитмәсә Диния нәзарәте җитәкчесен. бер дә бизәми Ул кылган эшләр Ислам диненә тап төшерә, кяферләргә «азык бирә»



Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры

Атналык программа:

(Декабрь)

8. Җомга — ПРЕМЬЕРА
В.Константинов, Б.Рацер
(Н.Нәҗми тәрҗемәсе)
ИГЪЛАН БУЕНЧА ӨЙЛӘНҮ
Моңсу комедия

9. Шимбә (Көндез) — Шакир Мәҗитов
(Илдар Юзеев поэмасы буенча)
РЕЗИДӘКӘЙ
Лирик-музыкаль комедия

9. Шимбә (Кич) — В.Константинов, Б.Рацер
(Н.Нәҗми тәрҗемәсе)
ИГЪЛАН БУЕНЧА ӨЙЛӘНҮ
Моңсу комедия

10. Якшәмбе (Көндез) — В.Константинов, Б.Рацер
(Н.Нәҗми тәрҗемәсе)
ИГЪЛАН БУЕНЧА ӨЙЛӘНҮ
Моңсу комедия

10. Якшәмбе (Кич) — Шамил Фәрхетдин
ЙОЛДЫЗЛЫ ЯҢГЫР!!!
(Звездный дождь)
Музыкаль тамаша

13. Чәршәмбе — Ризван Хәмид
ИСӘНЛЕККӘ-САУЛЫККА
Шаян такмак

14. Пәнҗешәмбе — Шамил Фәрхетдин
ЙОЛДЫЗЛЫ ЯҢГЫР!!!
(Звездный дождь)
Музыкаль тамаша

15. Җомга — Эсфир Янудин
МӘХӘББӘТКӘ МӘДХИЯ
Моңсу комедия

«Чулпан» милли үзәге
һәр атнада

Чәршәмбе, якшәмбе
АУЛАК ӨЙ
Милли бию, күңел ачу
19-22 сәгатьтә

Пәнҗешәмбе, җомга, шимбә
Дискотека (яшьләр өчен)
19-22 сәгатьтә

Шимбә
Дискотека (үсмерләр өчен)
15.30-18.30 сәгатьтә

Үзәкнең адресы:
Җиңү проспекты, 48-А.
Телефон: 34-61-76.

Сәхифәдә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, «Татар-Информ» һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

ХӘТЕР КАЙТАВАЗЫ

Кыям МИҢЛЕБАЕВ

Авылымны уйлап уйга калсам...

(Нәсер)

Әниемнең 100 еллыгына багышлыйм.
Автор.

Туган авылга ешрак кайтасы иде дә бит... Җан тарта, кан тарта, күңел шул якны каера инде, югыйсә, әмма көнә килеп җиткәч, өметләреңне чәлпәрәмә китә — мең төрле мәшәкать синең тезгенеңне умырып тоткан, җибәрергә, ичмаса бераз гына бушатырга уенда да юк. Халык телендә еш очрый торган «Дөнья куабыз» дигән тәгъбирнең мәгънәсе, миңа калса, мал артыннан чабу түгелдер, үзеңнең вазифаларыңны төп-төгәл иттереп, җиренә җиткереп үтәргә омтылу гынадыр. Ниһаять, дөнья куудан арынып, ямьле май урталарында туган якларны күреп килергә җай чыкты бугай.

Авылга бу юлы Зөфәр абый Алимов белән бергә кайттык. Юл мәшәкате дигәнебез бигрәк тә матавыклы булып чыкты. Шулай да, мең бәла белән булса да, кайтып җиттек тагын. Хәер, поездда, автобуста кайтканда да, машина-мазар көткәндә дә уҗымнарга сокланып, авылның үткәнен искә төшереп, тәмам дөньябызны оныту дәрәҗәсендә идек. Фәкать «КамАЗ» кабинасында гына сүзебез бүленде: гөрелтенә һич җиңәрлек түгел иде.

Бүгенге авылны син, абзыкай гынам, танырмын димә. Бөтенләй үзгәргән. Яңадан туган безнең Кече Чынлыбыз. Югыйсә бит нинди мәхшәрләр кичергән, нинди мескенлекләргә дучар ителгән иде бичаракаебыз. Гасыр башында албут (алпавыт) белән алышып — көчләр сынашып тарихларга кереп калган «Чынлы бәете» һич тә уйдырма түгел, булган хәлне тасвирлый. Инде хәерчелектән арынабыз гына дигәндә, авылның арада бер уңган-булган, ике бите белән җир себереп бераз тернәкләнеп киткән гаиләләргә «кулак» дигән кара тамга салалар. «Мисный влас» аты күтәреп йөргән миһербансыз бәндәләр күпме күз яше түгелүгә сәбәпче булалар. Хәтта әле Себер сөрмәгән тәкъдирдә дә үз авылдашларын хәерчелеккә дучар итәләр — бер кабарлык ризык калдырмыйлар, атларын вә сыерларын тартып алалар, әдәп-инсаф дигән нәрсәне гел онытып, карт-корыны вә бала-чаганы җылы өйләреннән урамга куып чыгаралар. «Елгабыздан акмасын кулак каны!» — дип, елап торган нарасыйларны, дөҗҗаллар шикелле, тибеп кенә очыралар. Булсынга тырыша торгач, азмы-күпме хәлләнә башлаган, аякка баса башлаган хуҗалыкларны «Бетсен! Тамыры корысын!» дип, тәмам пыран-заран китерәләр. Береннән-бере ямьле вә зиннәтле өйләрне сүтеп алып киткәч, авылыбызда усак яисә юкәдән өштер-өштер генә корыштырган, агач димәсәң хәтере калырдай, сыңар тәрәзәле, шыксыз-кыяфәтсез өйләр, аннан да күбрәк балчык ызбалар тырпаеп кала...

Улыска ничәмә-ничә глава биргән (шагыйрь җанлы Әбделнәфи бабамны 30-35 ел буена «Нөптәй галава» дип зурлап йөрткәннәр, урыны оҗмахта булсын), типсә тимер өзәрдәй егетләре бөтен төбәктә үткәрелгән Сабан туйларында батыр кала килгән, япон вә ярман сугышларында куркуның ни икәнен белмәгән, «Георгий» тәреләре белән бүләкләнгән Кече Чынлы кешеләре берни эшли алмый, паралич суккандагыдай, аптырап-югалып кала.

Гәрчә, үзем яшь тулганчы йөреп китсәм дә, фәкыйрьлекнең ачысын-төчесен бик тиз татыганмын — аяксыз калганмын. Төпчегенең шуышып кына йөри алуын күрүләре әниемә, әлбәттә, җиңел булмагандыр, җәрәхәтле йөрәгенә кан саугандыр. Нинди генә әмәл эзләмәгән бичаракаем, кемнән генә өшкертеп карамаган... Сабир мулланың сулышы килеште, дип сөйли торган иде. Нәзерен исә күп еллар үткәч кенә, мин үсеп җиткәч кенә, үти алды — авылга кайткан чагында Сабир хәзрәткә бүләк алырга онытмады.

Әлеге дә баягы «уфалла»ны төпкә җигелеп тарткан чаклар булды инде, булды. Атыбыз һәрчак булып тормады. Кулак сыйфатында «мисный влас» тарафыннан бик нык таланганнан соң әтиебез, — типсә тимер өзәрдәй ир-ат иде мәрхүм, — ягага китеп, аз-маз мал туплап кайткан иде, яңадан ат алып җибәрде. Үзе «индук» инде, аерым хуҗалык. Әти җир сөргәндә, аңа ашарга илткәндә, әнигә мин дә тагылмыйча калмый торган идем. Бервакыт шулай әтиебез яңа җирне сөрәсе икән.

— Кай тирәдән соң ул? — дип сорагач, әнигә кыска гына итеп:

— Диңгелдене чыккач та сул кулда, — дип «төшендереп» биргән.

Өйлә вакыты җитәрәк әни белән икәүләп ашарына илтәбез, имеш. Диңгелде елгасын чыккач та, басуда эшләүче ир-ат арасыннан үз әтиебезне эзләп табу вазифасы, әлбәттә, миңа йөкләнгән. Хатын-кызга чит-ят кешенең җиренә кереп йөрүне шәригать хупламый икән. Көкре аякларымны чалыш-чолыш китереп межа саен атлый-йөгерә әйләнеп килә дә:

— Юк, бусы да безнең әтәй түгел, — дим икән.

Шулай озак кына йөргәч, әллә арыганмын, әллә өметем өзелгән инде, бермәлне әнигә:

— Әтәйне тапмасак, бутканы ашарбыз да кайтырбыз соң, — дим икән.

Йортыбызда юаш кына ат булгач, мин аңа сабый чактан ук ияләштем. Иярсез-нисез генә ике-өч яшемнән үк атка атланып йөрергә өйрәндем. Өлкәннәрнең атландырганын көтеп тора димени егет кеше: яр буена, чокыр-чакыр янына китерәм дә — ялт итеп атланып та куям.

Сугыш башланганда гаиләбез белән Казанның Дәрвишләр бистәсендә яши идек. Әтиебез Сәләхетдин, урыны җәннәттә булсын, әүвәл «Вагонострой», соңыннан «КОМЗ» дип исемләнгән завод корыла башлау белән, шунда кара эшче булып эшләде. Шунда билен каймыктырып, ат белән эшләүне кулайрак күрде һәм сугыш алдыннан гына ат алып җибәрде. Бистәнең аксакалы дәрәҗәсе аңа, могаен, илаһи зур көтле-кодрәтле була торып та, искиткеч фидакяр-гадел, вөҗданлы-миһербанлы булуы аркасында килгәндер. Сугыш мәхшәре белән мохтаҗлыкка тарыган бистә халкы — татары, чувашы, урысы, мукшысы — аксакал янына бармыйча, кая барсын?!

— Бала-чагабызны ачлыктан коткарсаң, син генә коткарырсың, Сәләхетдин абый, атың да бар, тап берәр төрле җаен... — дип аңарга ялваралар.

Үз мәнфәгатен кайгыртып яши белмәгән, бүтәннәр өчен җаны фида аксакал, әлбәттә, аларның гозерен аяк астына салып таптый алмый. Таба ул җаен-әмәлен. 20-30 гаилә башлыгы үз өендәге яңарак нәрсәне, кием-салымны онга-ярмага алмаштыру нияте белән безгә китерә. Үзебезнең әйбер-караны да өстәгәч, шактый җыела шул, шактый. Ике чемоданга шыплап тутыралар да, шуларны чанага салып, туган якларга юл тота әтиебез.Әмма шул китүеннән соң күрешүләр безгә насыйп булмый: аны кулга алалар, спекулянтлыкта гаепләп, ун елга утыртып та куялар...

Шунда берәр гайрәтлерәк ир-ат кайсы чемоданга кемнең нинди әйбере салынганын күрсәтеп исемлек төзесә, ихтимал, «җинаятькә» икенче күз белән караган булырлар иде. Әмма тәвәккәлләүче табылмады: берәүләре үз мәнфәгатен артыграк күргәндер, икенчеләре исә, үземне дә утыртып куймагайлары, дип шүрләгәндер. Ни хәл итмәк кирәк, үпкәләп булмый берәүгә дә.

Өйе, дөрес анысы, авызың кыек булгач, көзгегә үпкәләмиләр. Фәкать безнең әтисез һәм ач-ялангач калуыбыз гына рас. Уйладык, уйладык та, ичмаса бакчабызга бәрәңге утыртырбыз, дигән өмет белән, 1942 елның язында, юллар өзелгәләгәнче, авылыбызга кайтып егылдык.

Ярый әле әнинең туган апасы Мәхүпҗамал (Зурәптәй), Шакир җизни Гайниевләр, авыр туфраклары җиңел булсын, ачык чырай күрсәттеләр — без шуларга кайтып төштек. Гәрчә алар хәлле генә гомер итсәләр дә, кеше өстендә озак яшәү һич килешми — үзебезнең балчык ызбаны рәткә китердек, түшәменә ике-өч терәү куйдык та кайтып урнаштык.

Әтиебез, бичара, Пеләтән төрмәсенә китереп япкач, уйга калган булса кирәк. Гадәтләнгән көнкүрешеннән, гаиләсеннән аерылып яшәүгә дучар ителгән һәркемгә уйлану хас.

— Мин соң берәрсенең әйбер-карасын урладыммы? Кемне дә булса рәнҗеттемме? Әллә берәрсен үтердем үкме? Нинди гөнаһым яки гаебем бар шушы хәлгә салырлык?

Тынгы бирмәгән уйланулар, бала-чагасының язмышы өчен борчылу, яну-көюләр, сагыну-уфтанулар пәһлеван шикелле әтиебезне 54 яшендә тәмам аяктан ега, гүргә илтеп кертә...

Гәрчә ирегеннән мәхрүм ителгәннәрнең балаларына гомер буе кырын карау яшәп килсә дә, әтием төрмәдә үлү сәбәпле күпме генә кыенлык татысам да, аек акыл белән фикер йөрткәндә, һичбер гаеп ташлап булмый үзенә. Фәкать аның фидакярлегенә, бүтәннәрнең мәнфәгатен яклап тәвәккәллек итүенә, гуманистлыгына сокланам.

— Әти урынында булсам, мин дә нәкъ шулай эшләр идем, — дип армый-талмый тәкрарлыймын.

Пеләтән төрмәсендә фани дөнья белән бәхилләшүчеләрне, барча «халык дошманнарын» гадәттә ерак илтеп азапланмаганнар — тимер юлның аргы ягындагы Архангель зиратына илтеп, исемсез-нисез генә, өзер кабергә күмә торган булганнар. Хәзер инде елның-елында, бер кочак чәчәк алып, шунда барам, әтиемнең язмышын уртаклашкан Мулланур Вахитов белән Галимҗан Ибраһимовларның һәйкәлләре төбенә, шулай ук туганнар каберлегенә һәм дә 1942 елны казылып-күмелгән бүтән каберләргә чәчәкләр салып чыгам. Тыныч йокласыннар. Барысы да...

Авылым халкы бер хәерчелектән икенче хәерчелеккә түнә: Бөек Ватан сугышы гәрчә безгә килеп җитмәсә дә, Сталинградтан бире узмаса да, сугышның ярыйсы ук саллы бер өермәсе нәкъ безнең авыл өстеннән узгандыр сыман тоела.

Сугыш башланган елны игеннәр хәтсез уңган иде, әмма аны һәммә төбәктә дә юньләп җыя алмадылар — саламында шактый калды бугай. Җыйган кадәресен бөртегенә хәтле дәүләт амбарларына тапшырганнан соң халык, авыл халкы, шул икмәкне иккән-үстергән-урган авылдашларым ипекәйсез калды. Буш трудоденьгә эшләү әнә шуннан модага кереп китте, законга әйләнде. Әмма тырыш халык авыз күтәреп ач утырырга риза түгел иде. Һәркем ачтан үлмәүнең, бала-чаганы саклап калуның дәртенә кереште. Аеруча мохтаҗлыкка дучар булган гаиләләр исә язын, басулар кардан арынгач та, башак чүпләргә, салам өскертләре төбеннән бөртек җыярга ябырылды.

Халыкта, дөя аунаган җирдә төгә кала, дигән гыйбрәтле әйтем бар. Салам эскерте төпләрендә нәкъ шушындый хәл иде: башакта калган бөртекләр акрынлап кына җиргә коелып ятканнар икән ләбаса. Уңган хатын-кыз, аларга карап бала-чага, саклык белән генә эскертнең чабуын бераз күтәреп, җиргә коелган арыш яки бодай бөртекләрен туфрагы-ние белән җыеп алалар. Ике бите белән җир себерә, дигәннәре әлеге шөгыльне башкаручыларга хәйран туры килә иде.

Тик инде кар астында кышлаган, язын бүрткән бодайны ашап, авылыбызда шактый гаилә шешенеп җәфа чикте, җан тәслим кылучылар да булгалады. Ачлыкның беренче корбаннары шулар булды бугай...

Безнең әниебез — Ләйлиҗамал, җаны җәннәттә булсын, — мин Нөптәй галава кызы, мин Коръәнне яттан беләм, үзем дә шигырен-бәетен чыгарам, дип тормады — ике бите белән җир себерүчеләрнең алгы сафында булды. Тик инде эскерт кырыеннан бөрәмтекләп җыеп кайткан бодайны туфрагыннан арындыру белән генә чикләнмәде, бәлки, җиде кат суда юып, җиде кат кояшта киптерде. Фәкать шуның аркасында гына исән-сау калдык, шешенүнең ни икәнен белмәдек. Әниебезнең тырышлыгы-уңганлыгы аркасында, гәрчә, үзебез фәкыйрьлекнең аскы баскычына тәгәрәгән булсак та, капчык асып хәер сорарга чыгып китмәдек. Шунысы хак, нинди зур мөлкәтне әрәм-шәрәм итеп, түрәләр үзара бүлешеп, бүгенге көндә, мин бөек держава, миңа тернәкләнеп китәргә генә кирәк, дип, мескен хәерче кебек кулын сузып, Аурупадан ярдәм өмет итүче, Русия хәленә дә төшмәдек — өҗәткә бер чиләк бәрәңге дә, бер көлтә салам да алмадык.

Әмма иртәгәне уйламыйча ярамый, бәрәңге бакчасын кысыр калдыру дан түгел иде. Ни хәл итик икән инде, дип уйлаштык-уйлаштык та әлеге дә баягы бодайны, җиде кат юып, җиде кат кояшта киптергәннән соң, уптым-илаһи ашап бетермәскә булдык: бәрәңге юнәтергә ниятләдек. Әни белән «уфалла»га салдык та, аны 30-40 чакрым тартып барып, Зөя буендагы су тегермәнендә тарттырдык. Ул ак онны авылга алып кайткач, 60 чакрымдагы Ульянга юлландык, анда мыскаллап саттык. Аннан килгән бәрәкәтсез акчага тоз сатып алдык.

Ләйлиҗамал апа оныгы Альберт белән. 1959 ел.

(Ахыры бар).

МИЛЛИ КИНО

Күңел чишмәләре челтериме?

Кыска метражлы фильмнар һәм мультипликацион фильмнар төшерүче һәвәскәрләрнең «Күңел чишмәләре» дигән III республика конкурсы булды. Анда Казаннан, Зеленодол, Азнакай, Минзәлә, Актаныштан унбиш студия катнашты. Фильмнарның темасы — сәнгать, көнкүреш, тормышка караш. Кинорежиссер Идмас Үтәгәнов җитәкчелегендәге жюри җиңүчеләрне билгеләде. Кинофильмнар буенча Зеленодол станциясеннән Караморкиннарның «Письмо» һәм «Первые шаги» дигән фильмнары I дәрәҗә дипломга лаек булды. Алар аны дүртәүләп — әтиләре Геннадий, ике улы Вадим һәм Саша, әбиләре Евдокия бергә төшергәннәр. II дәрәҗә диплом белән Актаныштагы 1 нче гимназиянең информатика укытучысы Рим Мостафин «Жара» һәм ««Актаныш таңнары» дигән фильмнары өчен бүләкләнде.

Видеофильмнар буенча I урынны Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Вадим Дросин «Кривая погоня» дигән фильмы өчен алды. Аның фильмы галим-физик Мәхмүт Зариповның Сталин лагерьларында үткәргән 15 еллык гомере, кургәннәре хакында.

Беренче урын тагын Зеленодолдан Светлана Серовага — «Уйти и вернуться» дигән фильмы өчен бирелде. II дәрәҗә дипломны шулай ук ике видеофильм — Минзәләнең «Энтузиаст» студиясеннән Н.Петров «Народные умельцы» һәм Зеленодолдан Илсөя Ибраһимова «Путешествие вокруг Европы на корабле дураков» дигән фильмнары өчен алдылар. III дәрәҗә диплом белән «День Победы» дигән фильмы өчен Казаннан В.Кузьмин һәм «Один день деревни» дигән фильмы өчен Ф.Маннапов бүләкләнде.

Мультфильмнар арасында Казандагы «Феникс» балалар студиясеннән А.Павлов белән В.Митрофановның «Нәни җир» дигән мультфильмы беренче бүләккә лаек булды.

Шамил АБДЮШЕВ.

- **Вадим Дросин.**
- **Илсөя Ибраһимова.**
- **Рим Мостафин.**
- **Идмас Үтәгәнов һәм Г.Караморкин.**

Нур ГАЙСИН

Ни аяныч, татар әдәбиятына югалту арты югалту килә. Танылган балалар язучысы Нур Гайсин шушы елның 1 декабрендә 81 яшендә арабыздан китте.

Нурулла Әхъяр улы Гайсин 1914 елның 2 ноябрендә Башкортстанның Чакмагыш районы, Әхмәт авылында крестиян гаиләсендә туган. Җиде яшеннән ул әти-әнисез кала һәм чит кеше кулында тәрбияләнә. Авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң Уфадагы телеграфистлар курсында укый. 1933 елда Татарстанның Зөя шәһәрендәге төзелеш институты рабфагында белем ала. Шунда укыганда Нур Гайсин әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый.

1934 елда, әдәбият дөньясына якынрак булу өчен, ул башта Казандагы су юлы инженерлары әзерли торган институт рабфагында, аннары Казан педагогия институтының кичке курсларында укый. Педагогия институтында укыган елларында яшь шагыйрьнең беренче шигырь җыентыгы басылып чыга.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Нур Гайсин, армиягә алынып, сугыш беткәнчегә кадәр һава оборонасы гаскәрләрендә взвод, аннары батарея командиры булып хезмәт итә.

Фронттан кайткач, Уфада «Кызыл таң» газете редакциясендә әдәби хезмәткәр, Казан театр училищесында директор урынбасары вазифаларын башкара.

Алтмыш елга якын иҗат дәверендә Нур Гайсинның ике дистәгә якын шигырь һәм проза китаплары басылып чыкты. Әдипнең яшьләргә багышланган «Давыллы көннәрдә», «Айсылу мәхәббәте», «Ялгышу», «Югалган макет» кебек драма әсәрләре дә бар.

Әдипнең исеме, аның балалар өчен язылган әсәрләре һәрвакыт безнең күңелләрдә сакланыр.

Татарстан Мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге.

ҮКЫ ДА УЙЛА

Алтын казып баеп буламы?

Әлмәт районының Сөләй авылында туып-үскән татар җегете Зиннәтулла Мамамедовны язмыш кайда гына йөртми. Армиягә чаклы нефть чыгару белән шөгыльләнә, аннан соң солдат хезмәте, соңра Вилюйски ГЭСы, Чернышевский соргендә булган урыннарга «сәяхәт», аннан соң Колымада алтын юу...

— Зиннәт туган, «Колымада алтын юу» дигән сүзнең мәгънәсе бик куркыныч бит. Син ничек барып эләктең ул Алла каргаган якка?

— Үз иркем белән йөрдем мин анда, тормыш рәтләргә дип, озын акча артыннан...

— Ничегрәк эшләнә иде ул «озын акча?»

— Алмаз-алтын ятмаларын эшкәртү өчен 1962 елда Вилюйски ГЭСын төзергә тотындылар. Мин 1970 елда ГЭС төзелеп беткәндә Колымага киттем. Чатырлар корып, карурман уртасында, черки арасында яши башладык.

— Черкигә анда адәм чыдый алмый, диләр, ничек түздегез?

— Диметил дигән эремәдә коенабыз, күлмәк-ыштанны чиләктәге шул эремәгә манчып, өскә киябез. Ике сәгать синең янга черки килеп тә карамый. Тора-бара җил, тир диметилне юып алып китә, черки өере тагын сине сырып ала. Шуннан соң янә тегә эремәгә манчыласың, умартачы битлеге кебек, челтәр-пәрәнҗә бөркәнәсең. Җәһәннәм җәзасы инде.

— Ихтыярый җәһәннәмгә керү батырлар эше инде ул...

— Дөресен әйтим, акча күп төшә иде ул вакытта. Айга җиде йөз сум. Монда иң югары хезмәт хакы йөз егерме чагында — зур байлык иде. Ашау да шәп иде анда. Шулай итеп, тайганың иң куе җиренә җиттек. Колымада безнең төркем арасында беренче чатыр корган кеше мин идем. Безнең эш, электр баганалары утыртып, тайга аша электр чыбыклары сузу иде. Мәңге эремәс туң җирне казып, баганаларны үзебез кисеп, шомартып, чокырларга утыртып, чыбык сузабыз. Дүрт кырлы лом бер көн эчендә шоп-шома бармакка әйләнә. Каторга хезмәте. Элек бу урыннарда бары тик сәяси тоткыннар, явыз җинаятьчеләр генә эшләгән. Бериянең махсус максатларда кулланыла торган армиясе яшәгән казармалар без килгәндә бушаган иде инде. Бу солдатлар тайгага качкан тоткыннарны тотып, тапкан урыннарында атып үтерергә куелган булганнар. Хисабын алу өчен һәр мәетнең уң кул чугын кисеп алганнар. Ул якта төрмәдән качу — үлем белән бер. Урман эче тулы ерткыч җанварлар, черки, сазлык, зәһәр суык — качкан кешегә исән калу мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә. Димәк, төрмәдәге җәзаларга караганда, тайгада үлүне бичаралар артык күргән. Тайга уртасында баш сөягә тишелгән, кабыргалары чәрдәкләнгән һәм уң кул чугы булмаган кеше сөякләренә тап булсаң, беләсең: бу бичараны аю ботарламаган, бу бәндә төрмә җәзаларына чыдый алмыйча, үтерелер өчен тайгага качкан.

(Ахыры 19 нчы биттә).

ТУФАННЫ ЮКСЫНУ

Тормыш үзенекен эзләп табачак...

Менә унбишенче ел инде Туфансыз яшибез. Бу елларда аның иҗат язмышын искә аласың да, җан тетрәнеп китә. Без нинди заманда яшәдек? Халыкның мәдәният язмышы нинди монополия кулына тапшырылган? Бу елларда кемнәрнең генә күптомлыклары ничәмә мәртәбәләр басылып чыкмады?!. Мин үзем Туфанның 4-5 томлык әсәрләр җыелмасын әзерләп, шуны чыгарып булмасмы дип, Матбугат йортында да күп мәртәбәләр булдым, Язучылар берлегенә дә, ярдәмләшүләрен сорап, мөрәҗәгать итеп карадым. Юк, булмады. Бүген инде: «Мөмкинлегебез юк: кәгазь юк, акча юк...» — дип, җәмәгатьчелек алдында акланырга сылтау да таптылар кебек. Әйе, гадәттән тыш әрнүле язмышлы Хәсән агайның иң тирән һәм зур җан рәнҗүләре үлгәннән соң да калган икән шул. Һәм бу хәл үзләрен милләт яугирләре, мәдәниятебез турында кайгыртучанлык күрсәтергә тиешле дәрәҗәле һәм җаваплы шәхесләрнең яки шуны дәгъвалап йөрүчеләрнең берсен дә борчымый. Гүя мондый мәсьәлә юк та; гүя барысы да ал да гөл. Моның бер чиге булырга тиештер бит инде. Эчтәлекле, мәгънәле эшчәнлекне буш мактану, мактаулар, ялган шапырынулар белән алмаштырып яшәүләрнең нинди нәтиҗәгә китерүен, тормыш үзе, күзләрдән чаткылар чәчрәтерлек итеп күрсәтмәдемени? Туфаннарны кайтару, Туфаннарны яшәтү шул афәткә комачау итү, тормышыбызга (тоталитарлыкның балта түтәсе белән тәеп) үтәдән-үтә сеңдерелгән шул дәһшәтле афәтне чикләү була торгандыр шул... Тик бер юаныч: әдәбият — тормыш мәйданы, ахыр чиктә ул, барыбер Х.Туфаннарныкы булып калачак!

Мәсгуд ГАЙНЕТДИН.

Хәсән ТУФАН

ШАГЫЙРЬ
НЕЧКӘЛЕК БИЛГЕСЕ БЕЛӘН ЯЗЫЛА

* * *

Борыныгыз — ак. Ә йөзегез —
Кап-кара!
Ник юмадыгыз аны сез,
Господа?! —
Юмый аны җир йөзенең
Бар суы! —
Гафу итик тә йолыйкмы
Без шуны.

Бәхетебезгә урлаучы
Сезме? — Сез!
Туганнарны үтерүче
Сезме? — Сез! —
Тәүбәгә килмәкчеме сез,
Иудалар?!
Һәм гафу итсенме сезне
Бу Ватан?!.

* * *

Туды. Шуннан, кулын бутый-бутый
Тавышын күрсәтергә теләде...
Авызын япты — чүпрәк имезлеге.
Кулын — богаулады биләве.

Үсте. Киереп җәеп җилкәләрен,
Җиңеп, алыр тәсле дөньяны!
Ул тын алып иркен күкрәк белән
Кычкырырга тели... Булмады:

Кулын тотты аның «монарх» дигән
Албастысы кара чорларның.
Тыны бетте. Хәтта өн калмады:
«Нигә болай бу?..» — дип сорарлык.

Ә күңелдә моңлы бер җыр сызлый:
«Каләм җуынырга ташым юк!..» —
Ташым да бар, дуслар! Йөрәгемнең,
Әрнүләрен әйтергә тавышым юк!..

Мәрхүм

Яман кешә түгел иде ул,
Ярыйсы бер бәндә, асылда. —
Тик
Уяулыкны иянәк иткән
Әллә нинди ягы бар шунда:
Әйтерсең лә аңа туганчы ук
Ниндидер бер гаеп салынган, —
«Акланырга» тырышып яшәдә
Бөтен гомере буе шуңардан
Кайда мөмкин сукрак сүз әйтү —
Шул тирәдә һаман әйләндә.
Фахишлекне фахиш дигәнгә,
Такташка да байтак бәйләндә.
«Татар», «милләт» дигән сүзләрдән,
Ладаннардан шылган җен кебек,
Шүрләде ул гомер буенча. —
Халык исә килгән һәр нәрсә —
«Контр» иде, аның уенча.
Дуга белән печән чапкандай,
(«Балык» тотар өчен, әлбәттә)
Замананы буташтырды ул
Һәм уяулык күрсәтүләрдә
Очны очка тоташтырды ул.

Иянәге аяк астында
Менә шулай гомер итте ул.
Чорга күпме зарар иткәнен
Тик белмәгән хәлдә китте ул.
Җиңел булсын, әйдә, туфрагы:
Бичара бер бәндә, асылда.
Чын күңелдән тырышты, мәрхүм,
Ярашырга безнең гасырга.

* * *

«Агыйдел» дә, «Кызыл таң» да
Килеп керә өемә.
Йөрәк шунда яшьлегенә
Кайткан сымак сөенә.

Сездән почта килде исә
Яме арта көнемнең.
Әйтерсең лә саф озонын
Китерә почта Өфемнең:

Хәтерлим дә Өфедәге
Дусларымның барын да,
Мажор тонга күчә минем
Минор минутларым да.

1962.

Гомуми һәм хосусый турында

Ишек шакый, —
Гадәтне дә, ахры,
Әдәпне дә кирәк санамый:
Рестораннар ябылып беткәндәрәк,
Ишек шакый иптәш Шаһгали.

Йомышы да,
Хакы да бар сыман,
Кергәләргә шулай өенә,
Аякларын сөртми-нитми генә
«Рәхим итте» өйнең түренә.

Ә кем соң ул,
«Шәхес» бар чагында,
Күркә кебек, кукрайганнарның,
Культ бетерелгәч, —
Ил яктырып киткәч,
Ярканат күк, сукырайганнарның —

Догмантларның типик вәкиле?..
... Рәхим итте өйнең түренә ул,
Сөртми-нитми генә төпине,

Ниндидер бер таш балталы вәхши
Тәкәлгәндәй кыргый хайванга,
Бөбәкләрен гөрәп китапларга, —
Насыйрига, Гомәр Хәйямга
Сүз башлады:
«Мин — Востокның мондый хламнарын
Аткан идем азмы, учакка! —
Ничек әле болар
Сау калган да,
Яшәп ята синең почмакта?!.»

Әйтерсең ул —
Погром өчен туган:
Әзер, гүя, һәрбер вәхшәткә:
Гасырлардан килгән китапларны
Бөрергә ул әзер... бәдрәфкә.

Соңгы еллар бераз «шомарткан» ул
Бу гадәтен — бераз «яңарган»,
(Нигилизм сарымсагы исе
Аңкый ләкин һаман аңардан):

«... Почмак, — ди ул, — ясно, частный нәрсә, —
Мөмкин, имеш, анда һәммәсе:
Хет укын син, анда, хет чукын син, —
Бу — личный эш синең, — янәсе. —

Ә бит синдә личный белән
Общий
Аерылгысыз бергә кушыла!
Тел-ни диеп сөйләнгәләүләрең
Безнең, — ди ул, — эчне пошыра...»

Шул «почмаклы» карашларын мәлдә
Аңлатырга килгән бу хәшәп:
«Общий белән, имеш, личный эшең
Бер-береннән аерым булса шәп.

Телне, — ди ул, —
Азмы баеттык без,
Сезнең ишеләр «читтә» көннәрдә,
«Чумара»ны, «салдым»нарны, дескать,
Бирә-бирә күрше-күләнгә.

Тыгылма син, ди ул, — «общий» эшкә:
Узынма син — бездән, яшьләрдән,
Ята бир син шунда,
Почмагыңда, —
Аш — ашалган, яшең — яшәлгән...

Синең, имеш, нинди хакың бар соң
Халык исемен телгә алырга?!» —
Яраларны минем зурайтырга —
Канатырга тели, тагын да!..

Синең бәхетең миңа, газиз илем,
Синең хәлең миңа читмени? —
Арба ватыла икән — утын гына,
Үгез үлә икән — итмени?!

Йөрәктәге барлык җәрәхәтләр
Төзәлде бит инде дигәндә,
Тоз сипмәкче ҫ̧ла шушы бәндә
Ярадагы иске җөйләргә!..

... Уңы белән
«Үти» личный эшен,
Сулы белән исә — «общийны» —
Һәрбер чорның, һади,үзенә күрә,
Бар икән шул берәр сукины...

Тыңлый калсаң, үзенең
«Личный эшен»
Лыгырдарга аның исәбе:
Тол-ятимнәр арасында, имеш,
Һәр районда — өчәр бикәче...

Их, әйтәсе килә:
— Вон, бәдбәхет! —
Водкаң исен бетереп кил монда,
Бу «почмакка»:
Бабич, Такташларның
Изге эзе калган урынга
«Төпиеңне сөртеп кер» монда!..

Җир улы

Фатих СИБАГАТУЛЛИН

Русия Федерациясе Федераль Җыенының Дәүләт Думасына депутатлыкка «Русия аграр партиясе» сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән.

Ул 1950 елда Татарстан Республикасының Арча районында, крестиян гаиләсендә туган. 1973 елда Казан ветеринария институтын тәмамлаган. Ветеринария табибы, колхоз рәисе, аннары партия-совет органнарында эшләгән.

1991 елдан Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, 1995 елдан — Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары.

Ветеринария фәннәре кандидаты, өйләнгән, ике баласы бар.

Фатих Сибагатуллинның эшлекле сыйфатлары һәм оештыру сәләте Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры вазифаларын башкарганда аеруча ачык чагылды. Ул эшләгән елларда авыл хуҗалыгы производствосының тотрыклы үсеше һәм республика халкы барлык төп азык-төлек продуктлары белән өзлексез, тулысынча тәэмин ителде.

Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, уңыш һәм терлекләрдән продукт алу буенча Татарстан Республикасы Идел буе өлкәләре һәм республикалары арасында гына түгел, тулаем Русия Федерациясендә ныклы рәвештә алдынгы урыннарның берсен алып тора. Авылны социаль үстерү, хуҗалыкларны үзгәртеп кору мәсьәләләре уңышлы хәл ителә, шәһәр һәм авыл арасында икътисади элементлар ныгый.

Фатих Сәүбән улы Сибагатуллинны яклап сез тавышларыгызны:

— авыл хуҗалыгын комплекслы һәм тотрыклы үстерү, халыкны югары сыйфатлы һәм арзанлы азык-төлек белән тулысынча һәм өзлексез тәэмин итү;

— аграр секторда үзгәртеп коруларны тизрәк үткәрү, авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең икътисади мәнфәгатьләрен саклау;

— халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, көнкүреш объектлары, сәүдә, юллар челтәре төзү һәм авылга газ кертү;

— Татарстан Республикасының барлык халкы мәнфәгатьләрендә шәһәр һәм авыл арасында эшлекле хезмәттәшлекне тагын да ныгыту өчен бирегез.

КӨТКӘН ДУМА ХӘЗЕР ТУАР, ЛӘКИН ДУМАГА КЕМ ТУЛАР?

Бәйсезлек — җиде капка артында

Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык артисты Вафирә Гыйззәтуллина... Татарның җыр сәнгате күгендәге гаҗәеп якты, моңлы һәм илһамлы йолдызларының берсе ул. Аның җырлавын тыңлаганда тау астыннан тибеп чыккан чишмә челтерәүләрен, айлы төндә талга кунып сайраган ялгыз былбыл тавышларын ишеткәндәй буласың. Дөресрәге, читлектә сайраган былбыл сагышы яңгырый аның җырларында.

Вафирә ханым бүген нинди уй-хыяллар белән яши? Әйдәгез, аның үзен тыңлап карыйк.

— Вафирә ханым, узган ел бер митингта сез Русия гаскәрләренең Ичкериягә бәреп керүенә каршы протест йөзеннән, Русиянең атказанган артисты таныклыгын яндырган идегез. Быел исә сезне Мәскәүдәге Бөтенрусия мөселманнарының «Нур» җәмгыяте Русия Федерациясенең Дәүләт Думасына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтте. Һәм, ниһаять, «Нур» җәмгыятенең чираттагы корылтаенда ихтыяры белән сез депутатлыкка кандидат булып теркәлдегез. Беләм, бу безнең милли хәрәкәттә төрле фаразлар, имеш-мимешләр тудырды. Берәүләр бу гамәлегезне хупласа, икенчеләре моны милли хәрәкәт мәнфәгатьләренә хыянәт итү дип бәяләде...

— Хәзерге вакытта милли бәйсезлек өчен көрәш стратегиясе бөтенләй башка төрле булырга тиеш. Мин ун елдан артык милли хәрәкәтнең иң алгы сафында булган кеше. Шуның өчен дә 1994 елның июль аенда мине Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясеннән пенсиягә озаттылар. Дөресрәге, кудылар, дип аңласагыз да була. Аннары бит мин гел турысын әйтергә, сөйләргә яратам. Кемгә дә булса тәлинкә тоту миңа хас сыйфат түгел. Хәзер инде мине милли хәрәкәттән дә читләштерделәр. Митингларда Вафирә Гыйззәтуллина милли бәйсезлек мәсләгенә хыянәт итте, дип кычкыручылар да булгалады. Кычкырасылары килгәч, кычкырсыннар инде. Көрәшнең төрле ысуллары бар бит. Кайда ул мөстәкыйльлек дигәннәре? Күрсәтегез аны миңа! Биш еллыгын билгеләп үттек тә (анысы да уен гына), нафталинлап кире сандыкка салып куйдык. Күя ашап бетермәсә, бер чыгарып селкеп өстебезгә дә киеп куярбыз әле, Аллаһы боерса. Тик бу изге хыял тормышка ашсын өчен каракош синең язмышыңны хәл иткән оядa утыру, аның нинди мәкерләр корганын белеп тору кирәк. Хәзерге шартларда татар халкын дүрт йөз елдан артык читлектә тоткан каракошка фәкать шулай гына каршы торырга мөмкин. Тарих биргән форсаттан файдаланмасак, милләт безне гафу итмәс. Ә тарихта моңа мисаллар җитәрлек. Әйтик, 1905 елда Столыпин, Пуришкевич ише урыс шовинистлары Дәүләт Думасы мөнбәреннән татар матбугатын, алдынгы карашлы мәктәп-мәдрәсәләрне ябарга, татарны Шәрык дөньясыннан аерып, аны янә чукындыру сәясәтен башлап җибәрергә чакырган бер вакытта мөселман фракциясе, аерым алганда, Садри Максуди кебек татар зыялылары баш күтәрмәсә, милләт инде шул елларда ук бик зур югалтулар кичерәр иде. Әгәр без Дәүләт Думасына үз депутатларыбызны сайлаудан баш тартабыз икән, урыс депутатлары татарның язмышын үзләре хәл итәчәк. Бусы инде, кем әйтмешли, көн кебек ачык. Аннары бит әле безгә Русия тупрагында яшәүче милләттәшләребезне борчыган мәсьәләләрне дә хәл итәргә кирәк. Мисал эзләп ерак китәсе юк. Волгоградта, Ырынбурда, Владимирда һәм башка шәһәрләрдә мөселман зиратлары ябыла. Аларда мөселманнарга җирне сатып бирәләр хәзер. Бу проблема түгелмени?!

— Дәүләт Думасына депутат итеп сайланган очракта, сез иң беренче нәүбәттә нинди мәсьәләләрне күтәрер идегез?

— Мине армия мәсьәләсе бик борчый. Татар балалары Татарстанның үзендә хезмәт итәргә тиешләр, дип уйлыйм мин. Ә аларны Ичкериягә алып китеп мөселман кардәшләренә каршы сугышырга мәҗбүр итәләр. Шунысы аяныч: урыс гаскәрләрендә православие дине өһелләре дә көннән-көн ешрак була башлады. Мөселман баласы хәрби ант биргәндә, аның янында тәре тоткан сакаллы поп басып торгач, ни була инде бу? Сүз уңаеннан тагын тарихка ишарә ясыйсым килә. Инкыйлабка кадәр Русия армиясендә мөселман ахуннары булган. Мөселман солдатларга һәм матросларга көнгә биш тапкыр намаз кылу да рөхсәт ителгән. Шуның өстенә аларга тәгам дә аерым ләр, мөселман хәрбиләре чәй эчкән.

— Дәүләт Думасына сайлану хокукы булган 43 партия һәм блоклар арасында «Нур» җәмгыяте бюллетеньгә ничәнче булып теркәлде?

— Ул исемлектә «Нур» җәмгыяте җиденче урында тора. Һәм бу бик тә матур бер символик мәгънәгә иядер, дип уйлыйм. Бездә, мөселманда, 7 саны илаһи көчкә ия дигән ышану бар. Күңелемдә иман нуры сүнеп җитмәгән һәр үзен чын мөселман баласы дип санаган һәр татар кешесе 17 декабрьдә «Нур» җәмгыятен яклап тавыш бирсә, иншалла, Русия Федерациясенең Дәүләт Думасында каракошка, аның кара гамәлләренә каршы тора алырлык мөселман фракциясе барлыкка килер.

Әңгәмәне
Заһид БАРЫЙ
үткәрде.

Сандугачның туган көне

Моңыбыз Алиһәсе

1995 ел татар җыры, татар моңы елы булды. Ул бөек җырчыбыз, мөселман дөньясы сандугачы Илһам Шакировның зур юбилей тантанасы белән башланып китте, инде килеп, мәшһүр моң иябез, халык күңеленең былбылы Фәридә апа Кудашеваның юбилей бәйрәме белән тәмамлана.

Татар моңын телгә алабыз икән, күз алдыбызга шушы ике бөек шәхес килеп баса. Алар милләтебезнең визит карточкасы, иң абруйлы зыялысы, барлык мөселман дөньясының, төрки җиһанның рухи ай-кояшы, сәнгати кыйбласы һәм мәдәни эталоны. Илһам Шакировны татар дөньясы бик зурлады. Рәхмәтләр яусын.

Хәзер чират Җыр-Моң Алиһәсе Фәридә апа Кудашевага җитте. Сер түгел Фәридә Кудашева — барлык моңлы җырчыларның анасы һәм кендек әбисе. Әйтерсең лә, җырчы күңеле — моң чишмәсеннән, моң дәрьясыннан гына тора. Фәридә Кудашевасыз Башкортстан сандугачсыз карурман, чәчәксез дала, чишмәсез чүл. Фәридә апа — Татар Җыры Мәккәсе. Безнең барыбызның да күңеле аның моңы белән ашланды һәм җаныбыз аның җыры белән дәваланды, сихәтләнде.

Өлкән буын кешеләре өчен радио һәм Фәридә Кудашева төшенчәләре аерылгысыз. Элек авылда ике-өч кенә радиоалгыч иде. Аны авыл халкы, бергә җыелып, күмәкләп тыңлады. Беренче чиратта Фәридә Кудашеваны күз уңында тотты тыңлаучы. Ул вакытта радио сүзе Алла сүзе, Фәридә Кудашева җыры табигатьнең илаһи моңы булып яңгырады.

Фәридә апа күпләр өчен кыйбла да, әхлаки кодекс та, әни дә иман да. Ул беркайчан да яраклашмады ялагайланмады, төчеләнмәде мескенләнмәде һәрдаим һәм һәр даирәдә горур булды. Әле дә шулай яши. Җырчы михнәт газапларны да күп күрде. Гомер буе гастрольләрдә йөрде. Нәкъ чегән тормышы. Салкын клублар.. Ялгызы гына кызын да тәрбияләде. Җырга гашыйк кеше генә мондый кыенлыкларга чыдый сабыр итә. Тормыш-язмыш сынауларны өсти генә торды аңа. күренекле композитор һәм музыкант Бәхти абый Гайсин үлеп ике ел да үтмәде Фәридә апаның бердәнбер кызы вафат булды...

Хәзер мәшһүр җырчы ялгызы яши. Өй җыештыручы да, ашарга пешерүче дә кибеткә йөрүче дә үзе. Ул электричкага утырып, этелеп-төртелеп, талаш-сүгенү сүзләре ишетеп, кысылып, Йоматаудагы бакча-дачасына йөри, анда казына. Фәридә апаның шәхси машинасы да, шоферы, ярдәмчесе дә юк шул. Югыйсә Фәридә апа халыкка ирештергән җыр-моңнары өчен җирдәге оҗмахта яшәргә хаклы. Казан Чаллы һәм Түбән Кама эшкуарлары һәм бизнесменнары, җырчы Фәридә Кудашеваны зурлыйк, хөрмәтлик әле!

Замир НИЗАМЕТДИНОВ.
Башкортстан, Туймазы шәһәре.

Салисә **ГӘРӘЕВА**

Идел кебек иркен җаның

Фәридә Кудашевага

Фәридә апа! Юлларыңа гөл чәчелсен!
Сине тыңлап, сандугачлар тел яшерсен!
Сабый чактан җырларыңа гашыйк сеңлең
Тавыш бирсә, аңа ни дип эндәшерсең?!

Җилләр булсам, чәчләреңдә сизәр идең,
Эзләреңә синең гөлләр сибәр идем.
Җырлый-җырлый Уралларны гизгән чакта
Юлларыңа чишмә булып тибәр идем!

Фәридә апа! Идел кебек иркен җаның,
Күңелеңнең байлыгына сокланамын.
Халкым моңын йөрәгеңә туплагансың,
Бар җиһанга таралгандыр синең даның!..

Сине тыңлыйм, күзләремнән яшь агызып,
Сандугачы Агыйделнең, Уфа кызы!
Күтәрелеп кара залга — күпме халык
Сихерләнгән, җырлавыңа хәйран калып!

Чиләбе. 1965.

Игътибар: конкурс!

Туймазыда җыр бәйгесе

Туймазы республикаара «Илһам» компаниясе татар халык җырларын башкаручыларның халыкара конкурсын игълан итә. Әлеге бәйгедә Русия Федерациясендә һәм теләсә кайсы чит илдә яшәүче профессиональ һәм үзешчән җырчылар катнаша ала. Конкурсантларның яше һәм милләте әһәмияткә ия түгел. Катнашучылар өч халык җырын башкарырга тиеш: берсен — аккомпаниатор һәм микрофон белән: икенчесен — микрофон алдында, ләкин музыкаль инструментсыз; өченчесен — музыкага кушылып, әмма микрофонсыз. Җырчының өстәмә рәвештә тагын бер яки ике җыр башкарырга хокукы бар. Барлык җырлар да фәкать татар телендә генә башкарыла.

Конкурс 1996 елның 12-13 апрелендә Башкортстан Республикасының Туймазы шәһәрендә үткәрелә. 13 апрельдә кичен лауреатлар һәм дипломантларның йомгаклау концерты булачак. Конкурста катнашучылар үзләре башкарачак җырлар язылган аудиокассета һәм фонограмма алып килергә тиешләр. Видеокассета җибәрергә дә мөмкин.

Җыр бәйгесендә җиңүчеләр кыйммәтле бүләк-призлар белән бүләкләнә.

Жюри составында — күренекле җырчылар, композиторлар, музыкантлар, шагыйрьләр, Уфа сәнгать институты һәм Казан дәүләт сәнгать һәм мәдәният академиясе профессорлары. Жюри рәистәшләре — Фәридә Кудашева һәм Илһам Шакиров.

Юл, кунакханәдә яшәү һәм ашау-эчү чыгымнары конкурста катнашучылар, аларның спонсорлары һәм мәдәният бүлекләре исәбенә.

Гаризалар 1996 елның 15 мартына кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Республика Башкортстан, ул. Комарова, дом 47/1, кв. 52. Низамутдинову Замиру Валиахметовичу Телефон: 6-50-39.

Заявкада конкурста катнашырга теләүченең исем-фамилиясе, атасының исеме, туган елы, яшәү һәм эшләү урыны, һөнәре, белеме (нинди уку йортын кайсы белгечлек буенча тәмамлаган), тулы адресы, профессиональ яки үзешчән сәхнәдән кайчаннан бирле чыгыш ясавы, эш яки яшәү урынындагы телефон номеры, ә иң мәһиме — башкарырга теләгән җырларның исемнәре һәм авторлары күрсәтелергә тиеш. Шул җырлар язылган аудиокасетаны, гариза-заявка белән бергә почта аша җибәрү фарыз, теләге булганнар фотосурәтләрен һәм иҗади биографияләрен дә язып җибәрә ала.

Конкурста катнашырга теләк белдергән һәркемгә оештыру комитеты рәсми чакыру кәгазе җибәрәчәк.

Спонсорлык ярдәме кабул ителә. Теләге булган һәркем үз призын, премиясен һәм кыйммәтле бүләген тапшырырга хокуклы.

Уфа ни өчен матур

Башкортстанның һәм Татарстанның мәшһүр җырчысы Фәридә Кудашевага 75 яшь тулу уңаеннан 8 декабрьдә Уфада филармониянең зур залында зур тантана уздырыла. Анда Казаннан юбилярның иҗатташлары һәм дуслары Илһам Шакиров Хәмдүнә Тимергалиева, Рафаэль Ильясов шагыйрә Гөлшат Зәйнашева, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе директоры Әсгать Сафин һ.б катнаша.

Таш елатырлык сүз

Казан кем шәһәре?

Казан урыс шәһәреме, татар шәһәреме, дигән сорауга һәркем, ул — татар шәһәре, Татарстан Республикасының башкаласы, дип җавап бирәчәк. Ләкин бу чыннан да шулаймы соң? Һич юк. 1552 елда Явыз Иван Казан ханлыгын тар-мар иткәч, безнең мәркәзебез чын урыс шәһәренә әверелә, Казанның бары исеме генә кала. Анда, менә бу ханлык заманнарында салынган корылма, диярлек өтек кенә хәрабәләр дә сакланып калмаган. Без хәтта Казанны урыслардан саклаганда шәһит киткән каһарман бабаларыбызның кайда җирләнгәннәрен дә белмибез. Бер чәркә суда, без татарлармы, әллә болгарлармы кебек мәгънәсез бәхәсләр «давылы» куптарудан тәм табабыз.

Бәйсезлек даулавыбызга инде биш ел үтеп китте. Без тормышыбызда нәрсәне дә булса үзгәртә, татарлыгыбызны чак кына булса да яңарта алдыкмы соң? Юк, җәмәгать, коры лыгырдаудан уза алмадык. Бездә ары үсәргә дәрт тә, теләк тә юк. Элеккечә ни дә булса майтарырга югарыдан зирәк күрсәтмә көтәбез. «Өлкән туганыбыз» чабуын кулыбыздан ычкындырсак, ялгызыбызга яшәргә туры киләчәк, янәсе. Өйрәнелгән чокыр-чакырлы, баткак юлдан кемнеңдер итәгенә тотынып күз йомып атлавы, таныш түгел мөстәкыйльлек юлдан кармаланып эз салудан күпкә җиңелрәк ич. Иң мөһиме — ялгышларыңны кемгәдер аударырга, судан коры чыгарга юл кала. Кораб яндырырга ашыкмаска кирәк. Аның кирәк булуы ихтимал.

Сез минем Казанны ни өчен урыс шәһәре дип атавымны дәлилләвемне көтәсез булыр. Рәхим итегез. Казанда 1493 урам бар. Моннан дүрт ел элек мөхтәрәм академигыбыз Әбрар Кәримуллин үзенең «Шәһри Казан» гәзитендә басылган «Казан урамнары ни сөйли?» дигән язмасында болай дип яза: «..Казан урамнарының 480енә язучылар, галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре, сугыш һәм хезмәт ветераннары, педагоглар исемнәре бирелгән. Алар арасында 390 урам урыс һәм фәкать 67 генә урам татар эшлеклеләре исемен йөртә. Бу — Казанда, татарларның мәркәзендә бит! Татарстан башкаласында татар исемен йөрткән урамнар саны урысларныкыннан алты тапкыр кимрәк. Моны шәрехләп тору да кирәкмидер, мөгаен. 390 урамның 169ына үз исемнәрен «биргән» шәхесләрнең Казанга, Татарстанга, аның тарихына һәм мәдәниятенә бернинди катнашлары да юк. Калган 231е арасында 100ләбе Казанда берничә көн яки берничә ай, яки узып барышлый гына булганнар. Кайбер исемнәр шәһәребездә күп булса биш-ун кешегә генә мәгълүмдер»

Ул хаклы. Ләкин олуг галимебезнең сүзләренә колак салып, хәлне үзгәртү турында кайгыртучы булдымы? Булмады, шәһәребез башлыклары татар телендә чыга торган үз гәзитләренә төкереп карап, аны укып чыгуны кирәк санамыйлар, күрәсең. Ленин, Куйбышев, Бауман, Киров, Карл Маркс, Дзержинский һ.б. бәяләрә төшкән бик күп дөнья бутаучыларның Казан урамнарына бирелгән исемнәрен үзгәртергә атлыгып торучы юк. Аларны күренекле җирле тарихи шәхесләребез исемнәренә алмаштыру кирәклеге турында республика көндәлек матбугаты шаулап та алды. Кайсы урамга нинди исем бирү турында тәкъдимнәр дә ясалды, югыйсә. Ләкин эш Жданов урамына элекке исемен кайтару белән чикләнеп калды.

Башлыклар, урам исемнәрен үзгәртү зур чыгымнар сорый, дип акланалар. Алай дисәң, алар сазлыкта Бөек Җиңүнең 50 еллыгына бер көнлек Җиңү паркы төзүгә миллиардлар сарыф итүдән тартынмадылар бит.

Без сүздә мөстәкыйльлек яуладык, дибез, ләкин ул гамәлдә берничек тә сизелми әле. Дәүләт Советында һаман «өлкән туганнарыбыз» вәкилләренә тәлинкә тоталар, сессия утырышлары гел урыс телендә алып барыла: Татар теле фәкать авыл кешеләре теле булып калуын дәвам итә. Ана телебезгә тәңгәл килә торган үз алфавитыбыз юк, аны эшләүне тел галимнәребез инде бөтенләй оныттылар да бугай. Бу кайчанга тиклем дәвам итәр икән?..

Гурий ТАВЛИН.

Зәһид МӘХМҮДИ

МУНЧА

Ике пәрдәле трагимәзек

КАТНАШАЛАР:

Җәмил — пенсиядәге карт, 66 яшьтә
Мәчтүрә — аның хатыны
Ленин
Иблис

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кыш. Айлы төн. Авыл. Ишегалды күренеше. Һау-һау килеп этләр өрә. Урам якта һаман саен якыная барган ике исерек җырлаган тавыш ишетелә.

Туплар шартлый, җирләр тетри,
Йолдыз якты, төн кара.
Мылтык атып, кылыч тагып
Ак бандага каршы бара
Комсомолка Гөлсара.

Капкадан Җәмил карт, аның артыннан аркасына мылтык аскан Иблис килеп керә. Иблиснең өстендә яхшы тун, чәшке бүрек. Җәмил иске телогрейкадан.

Җәмил (*Иблисне суырып үбеп*). Син миңа ошыйсың, бр-рат! Кем син?

Иблис. Иблис мин, туган, Ибли-ис, аңладыңмы?

Җәмил. Менә бу исем ичмаса! Мин сине яратам. (*Тегене тагын кочаклап үбә*). Безнең күршедә Трактор да бар. Быел 50 яшен тутырды. Узган айда түбән очта Ваучер да туды. Кайсы авылныкы син?

Иблис (*колагын якынрак китереп*). Нәрсә?

Җәмил. Кайсы авылныкы, дим? Чурайданмы, Мултаннанмы? Юк, безнең якныкы түгел син. «Къ»ны «кь» дип әйтәсең. Чистайдандыр, әйеме?

Иблис (*җиргә күрсәтеп*). Юк, мин тегеннән.

Җәмил (*аны җиңеннән өстерәп*). Бик шәп! Кызык итик әле хатынны. Пәриләр барына ышанмый ул.

Иблис (*гайрәтләнеп*). Ышанмыймы? Ничек инде ышанмый? Ышандырабыз без аны, кирәк булса!

Җәмил. Киттек.

Иблис. Тукта, бераз хәл алыйк. (*Пышылдап кына*). Хатының бик явыз түгелме?

Җәмил. Явыз булмаган кая, уклау белән менә болай гына кундыра. (*Әшнәсенең яңагына китереп суга. Теге карга мәтәлә, бүреге тәгәрәп китә. Маңгаенда кечкенә генә мөгез күренә*).

Иблис (*шыңшып*). Син кунагыңны болай рәнҗетмә инде.

Җәмил (*Иблиснең мөгезеннән тотып*). Нәрсә соң бу?

Иблис. Нәрсә булсын, мөгез инде. Шуның белән генә сөзәм мин кире бәндәләрне.

Җәмил. Алай икә-ән... Хатының утырттымы?

Иблис. Тумыштан ук бар инде ул миндә.

Җәмил. Шулай, шулай, тумас борын куя хәзер яшьләр мөгезне. Безнең баш агрономның да шундый мөгезе бар. Берәү генә түгел, берничә. Хатыны көн дә берне куеп тора. Бичараның башы инде бүреккә сыймый башлады. (*Иблиснең якасыннан ала*). Дөресен әйт, кем син?

Иблис. Әйттем ич инде, Иблис дип.

Җәмил (*өскә күрсәтеп*). Чыннан да тегеннәнме?

Иблис (*аска күрсәтеп*). Юк, тегеннән.

Җәмил (*күккә карап*). Ә нигә тегеннән түгел?

Иблис (*янә аска күрсәтеп*). Тегеннән булганга күрә!

Җәмил йодрыгы белән ишек кага.

Җәмил. Мәчтүрә! Мин кайттым. Ишекне ач!

Ишек артында хатын-кыз чәрелдәгәне ишетелә: «Тагын исергән, чукынчык! Ачмыйм әле менә! Әнә, мунчаңда йокла! Сагынгандыр инде пәриләрең!»

Җәмил (*болдыр баскычына утырып, үзалдына*). Мунчада суык шул. (*Иблискә акыра*). Нәрсә карап каттың, бар, утын алып кил. Мунча ягабыз хәзер.

Иблис (*аңышмыйча*). Нәрсә алып килергә дисең?

Җәмил. Утын дим, тәмуг сарыгы!

Иблис. Нәрсә соң ул?

Җәмил. Көләсең мәллә миннән? Тегендәге әтрәк әләмнәрне казанда кайнатканда нәрсә ягасың?

Иблис. Газ.

Җәмил. Алдашма, газ күптән түгел генә керә башлады. Безгә кадәр килеп җиттеләр дә, фәлән юк, төгән юк, дип туктап калдылар, мәлгуньнәр! Брежнев исән булса, мич башында гына ятасы кеше идем мин. Әйткән диләр аны, мин үлеп бер биш ел узгач, күтемнән үбәрсез әле, дип. Ә без аны, давай, хурларга, мыскылларга.

Иблис (*моңсуланып*). Коммунистлар властьта вакытта мин дә мондый ук ятим түгел идем.

Җәмил. Син менә хәзер Брежневның күтен үбәр идеңме?

Иблис. Үбәр идем. Кайда ул? Китер аны монда! Хәзер үк үбәм! (*Җәмилнең битен үбә*). Ә битен үпмәс идем. Теләсә кем белән үбешә иде ул, заразы!

Җәмил (*хыялланып*). Сездә газ ягалар дисең алайса?

Иблис. Таптың шаккатырлык нәрсә. Африкада кебек бездә, малай. Йөрисең шунда казаннар арасында, негр кебек.

Җәмил. Алдашасың, брат, газ хәзер генә керә башлады.

Иблис. Әбием белән ант итәм, агайне. (*Чукынып куя*). Ә хөмер елгаларының, хур кызларының исәбе-хисабы юк. Анда...

Җәмил. Туктыйсыңмы син, юкмы? (*Кулларын йодрыклап, Иблискә таба килә*). Менә мине белә башлагач, утын белән яга башларсың.

Иблис (*мылтыкны аңа төзәп*). Әй, әй, син бик шаярма! Атам, валлаһи, атам!

Җәмил (*йомшарып*). Җә, җә, мин бит уйнап кына. (*Кире баскычка барып утыра*). Кил, утыр, бераз эчәкләреңне җылытып ал. (*Җырлый-җырлый куен кесәсеннән башланган аракы шешәсе чыгара*).

Утыр әле яннарыма,
Ял бирче җаннарыма...

Иблис, куркып кына, аның янына килеп утыра. Мылтыкны кулыннан ычкындырмый.

Җәмил. Син нәрсә, керәшен мәллә?

Иблис. Нигә шулай дисең?

Җәмил. Чукынганга күрә әйтәм.

Иблис (*башын селкеп*). Ыһы..,

Җәмил. Иннокентий, дип эндәшсәм, үпкәләмәссеңме?

Иблис. Эндәш сана, барыбер түгелмени?

Җәмил (*шешәне югары чөеп*). Здравья желаю! (*Авызыннан гына йотып куя да чыраен сыта*). За... за...

Иблис. Закуска кирәкме?

Җәмил укшып утырган арада, Иблис тамашачыларның берсеннән солдат котелогы белән кашык алып килеп, аңа тоттыра.

Җәмил (*гаҗәпләнеп*). Тары боткасы?.. Кайдан?

Иблис. Әмрикәдән җибәргәннәр. Гуманитар ярдәм, так ыскать.

Җәмил, боткадан авыз итеп, котелокны читкә алып куя. Иблис, теләләрен ялап, шул тарафка үреле.

Җәмил (*аның кулына сугып*). Кая үреләсең?

Иблис. Ашыйсы килә.

Җәмил. Эшләп ашарга кирәк. Калганы хатынга. Әмрикәдән килгән чүтеки. (*Якасын күтәреп куя. Аңа карап Иблис тә якасын күтәрә*). Су-ык!.. Җылы дисең инде сездә, ә?

Иблис (*калтырап*). Җ-җылы-ы.

Җәмил. Казаннарга суны кайдан агызасыз?

Иблис. Краннан.

Җәмил. Рәхәт яшисез икән. Ыслушай, таныш-белешлек белән генә миңа да шуннан су кертеп булмыймы?

Иблис. Өч көнлек дөнья мәшәкатьләре белән башыңны катырма, агайне. Син алгарак карап яшәргә өйрән. Безгә килгәч тә рәхәтләнерсең әле суга. Аерым җиз казанга салырбыз үзеңне.

Җәмил. Теләкләрең изге икән. (*Башын өскә күтәреп*). Мин инде ничек тә булса тегендәрәк урын табарга тырышырмын, Иннокентий. (*Ишек кага*). Мәчтүрә! Мәчтүрә, дим!

Ишектә өстенә иске шәл япкан Мәчтүрә күренә.

Мәчтүрә. Нәрсә җитми тагын, төрә баганасы?!

Җәмил. Ачуланма әле син, карчык, башта тыңлап бетер. (*Пышылдап*). Мин сине хәзер тегеннән килгән бер кунак белән таныштырам. (*Иблис утырган якка ымлап*). Таныш бул! Иблис, субственный пирсун. Бүген генә урамда таныштык. (*Иблисне тартып торгыза*).

Мәчтүрә (*каһкаһә белән*). Охшаган, бик охшаган. (*Җәмилгә*). Ә син Хозыр Ильяс, име?

Җәмил. Нәрсә, әллә Хозыр Ильястан берәр җирем кимме? (*Күкрәген киерә*).

Мәчтүрә. Тфү! Әстәгъфирулла!

Җәмил (*Иблискә пышылдый*). Утчыствың ничек синең?

Иблис (*колагын якынрак куеп*). Нәрсә дисең?

Җәмил (*ачуланып*). Ух, әбиеңне алгыры, бабаңның исеме ничек дим?

Иблис. Миңа тегендә Иблис дип кенә эндәшәләр.

Җәмил. Надан. Нишләп кенә ятасыз икән сез ул тәмугта! (*Мыскыл итеп*). Газ, имеш! (*Мәчтүрәгә ялагайланып*). Керт инде, җаным.

Мәчтүрә. Эчсәң, кертмим дидемме? Әнә, мунча синә! У-у, урыс карты кыяфәтләре кергән инде үзеңә!

Җәмил. Ант эчәм менә, бүтән исен дә иснәмәячәкмен!

Мәчтүрә. И, тукран тәүбәсе, күпме антлар иттең бит инде-е! Юк инде, юк, бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый, диләр. Картлык көнемдә бер терәк булыр дигән идем, булмады, каһәр. Бәхетем кирәдән тәгәлгән, күрәсең. Нинди хатлар яза иде бит Воркутадан!.. Ярый, шул кирәк миңа, бер аягың белән кабергә баскач, кияү эзләп йөрмәскә иде.

Җәмил. Син дә шул ук оялчан, ипле, назлы Мәчтүрә булып тоела идең лә хатларыңда. Болай мунчада йоклатып интектерәсеңне белсәм, эземне дә басмый идем мин монда.

Мәчтүрә. У-у, әшәке җан, мәктәптә укыганда ук өмет өзгәннәр иде бит синнән.

Җәмил. Арттырасың, хатын, арттырасың.

Мәчтүрә. Нигә, дөрес түгелмени? Хәмит абыйны мәчеткә кем бикләде?

Җәмил. Соң, ул бит бөтен класс алдында минем чәчемне кыркымакчы иде. Мин качтым. Ул, давай, минем арттан. Мәчеткә кадәр куып барды. Ә мин бик тере малай идем ул чакта. Ишек артына качып калдым да, шалт тегене йозакка! (*Моңсуланып*). Бер кулын Сталинградта өздереп кайткан чагы гына иде, мәрхүмнең. (*Иблискә таба борылып*). Иртән бирер инде бу кирәкне, дип куркып кына килдем мәктәпкә. Юк, тырнак белән дә чиртмәде. Тик чәчне кыркыды барыбер. Озын чәч үстерергә ярамый иде әле ул чакта. Аннары, үз бүлмәсенә алып кереп, кызыл билле прәннек белән сыйлады. (*Мәчтүрәгә*). И күңелләштегез инде миннән барыгыз да!

Мәчтүрә (*йомшара төшеп*). Көнләшмәскә ни, андый прәннек безгә бәйрәм көннәрендә генә эләгә иде ич. (*Авыр сулап*). Ач заманалар булса да, тәртип бар иде ул чакта. Авылда исерекләр юк иде. Булганы да синең кебек үрмәләп йөргәнче эчмәде.

Җәмил. Карчык, син бит Кәбиреңне мәктәптә укыганда ук ярата идең.

Мәчтүрә. Кит, ул чакта нинди ярату булсын ди?

Җәмил. Ярата идең, карчык, ярата идең. Үчекләп тә йөрделәр бит әле үзегезне.

Мәчтүрә (*моңаеп*). Ул сугыштан исән кайтса, минем дә йортым тулы бала-чага булыр иде. Кайтмады шул, кайдадыр Сталинград тирәсендә һәлак булды Кәбирем.

Җәмил. Карале, әгәр ул хәзер кайтып керсә, син мине куып чыгарыр идеңме?

Мәчтүрә. Тиле сүз сөйләп утырма әле, карт җең!

Җәмил (*пышылдап*). Карчык, мин сине яратам.

Мәчтүрә. Күрсәттең инде яратканыңны. Яраткан кеше болай кыланмый ул.

Иблис (*Мәчтүрәне үпмәкче була*). Мин дә яратам.

Җәмил (*аны этеп җибәрә*). Чын менә. Мәктәптә укыганда ук ярата башлаган идем. Тик моны синә беркайчан да сиздәргәнем булмады. Өтермәдән чыгып авылга кайтуга тәкъдим дә ясарга теләгән идем. Ул һаман Кәбирен көтә, диючеләр булгач, ничектер җөрьәт итмәдем. Аннары син кем идең дә, мин кем идем ул чакта? Син — коммунист, агитатор, активистка, ә мин...

Мәчтүрә. Үләр вакыт җиткәч

кенә мәхәббәттә аңлашмасаң...

Җәмил. Үлмибез әле, карчык. Кип, бер пәп итимче үзеңне (*Хатынын кочаклый*)

Мәчтүрә (*аны этеп җибәрә*). Әстәгъфирулла, нишләвең бу синең? Кит, кит, кеше күрүе бар!

Җәмил. Күрсә соң?

Иблис (*гайрәтләнеп залга кычкыра*) Карамагыз берегез дә!

Мәчтүрә (*ачуланып*) Бу исерегә нигә акыра инде тагын, ә?! Әйдә, картым, аны куып чыгар да, өйгә кер, җәме!

Җәмил Әйтмәле миңа картым дип Җәмилем дип кенә эндәш. Җегет кеше бит әле мин! (*Бии, җырлый башлый*)

Картаямыни соң йөрәк
Маңгайлар сырланса да...

Мәчтүрә. Керәсеңме син, юкмы?

Җәмил. Кермим. Мин мунчада йоклыйм!

Мәчтүрә ишекне шап итеп ябып кереп китә. Җәмил йөгереп килеп ишекне тарта

Җәмил. Кереп кенә китәсе калган икән (*Ишекне йодрыгы белән төеп кычкыра*) Мәчтүрә! Мәчтүрә, дим! (*Чүгәли*) Беттек, агайне, ачмас инде бу хәзер (*Махра төреп кабыза, тәтенне эчкә алып чыгаргач, күзе мылтыкка төшә*) Каян чәлдең бу нәрсәне?

Иблис. Югары очтан.

Җәмил. Ә-ә, теге Кытай Мансурыныкынмы?

Иблис. Каян белдең?

Җәмил. Соң, белмәскә, безнең авылда мылтык бер анда гына бар ич. Бабасыннан, гражданкадан калган мылтык. Элек аны чыпчык Мансуры дип йөрттеләр. Аракы эчте исә чыпчыкларны чүпли башлый иде. Мин чыпчыкныкы түгел, бүреләрнеке мин, дип акыра. Әүвәлерәк аның нәселен чыннан да бүренекеләр дип йөрткәннәр бугай. Менә шул революционер бабасыннан башланган инде чыпчыклар нәселе. Бүтәкә кадәр генә булса да, шушы күгәргән мылтыгы белән бөтен авылны дер селкетеп торган. Бәләкәй кеше явыз була бит ул. Батрактан сразу авыл сәвите итеп куйганнар тегене. Мансурында да, йөз грамм кабуга, бабасы каны уяна. Кошлардан издевательства ясаган өчен утыртып та караганнар иде, юк, барыбер үзенекен итте. Авылдагы бөтен чыпчыкларны кырып бетермичә туктамады. Шуннан бирле моңа Кытай шпионы дигән кушамат тагылып калды. Ул елларда Кытайда культур революция бара иде ич. Анда да чыпчыкларны бик каты кырдылар (*Сагаеп*) Тукта, син каян белдең әле анда мылтык барын?

Иблис. Белмәскә соң, көздән бирле аулап йөрим ич үзен. Тәмугта янсам янам, тющаны барыбер атып үтерәм, дип кычкырып йөрде-йөрде дә, үтермәде. Ә мин, тиле, ышанып, аңа тәмугта иң кайнар, иң зур казанны әзерләп куйган идем! Шул Кытай шпионы аркасында план да үтәлмичә калды. Тегеләй дә өйрәтәм, болай да котыртам, юк, һич кенә дә тәвәккәлли алмый. Соңыннан бу, тәмам исерләнеп, су буенда киек казлар дип кеше казларын атып йөрде. Хәзер менә, рәхәтләнеп кайнар суда ятасы урында, сары йортта ята.

Җәмил. Бер генә ятуы түгел инде. Соңгы тапкыр чыкканында шәһәргә барып коммунистлыкка язылган иде. Кызыл көннәрдә түбәгә менеп баса да «Интернационал»ны җырлый башлый.

Шул чакны еракта берәүнең җырлаганы ишетелә.

Кузгал, уян, ләгънәт ителгән
Коллар һәм ачлар дөньясы!..

Җәмил. Ишеттеңме? Тагын кайтып җиткән. Аның тавышы бу. Бабасы бик идейный кеше иде шул. Дөрес булса, ул Смульныйда Ленинның үзе белән кул биреп күрешкән, диләр.

Иблис. Булмас, минем андый кеше белән күрешкәнем юк.

Җәмил. Синең турыда сүз бармый бит әле, Ленин белән, дим мин сиңа

Иблис. Ә син мине кем дип белдең? (*Ишегалды уртасына басып, бөек юлбашчы кебек, бер кулын кесәсенә тыга, икенчесен югарыга күтәрә*) Таныдыңмы инде?

Җәмил (*алай да болай да карап*) Бераз, килештерәсең бугай үзе (*Шикләнеп*) Охшаган да, охшамаган да

Иблис Яхшылап кара.

Җәмил. Тукта, портретын алып чыгыйм әле

Мунчага кереп китә Иблис, ничек басып торган булса шулай басып кала. Эчтә чиләк, ләгән тәгәрәгән тавыш ишетелә. Ниһаять, Ленин портретын күтәреп Җәмил чыга.

Җәмил (*бер портретка, бер Иблискә карап*) Кулыңны югарырак күтәр... Булды. Хәзер башыңны алгарак суз... Менә шулай... Вәт, хәзер коеп куйган Ленин булдың инде... Юк, барыбер нидер җитеп бетми

Ул арада мунчадан костюм кигән чын Ленин килеп чыга. Ике кулы да кесәсендә. Йөзе бик җитди. Иблис тирәсендә бер-ике тапкыр әйләнә дә «Күтеңне гуңкайтма! Хаер, революция ясагач, барыбер туңкайтырга туры киләчәк». — дип, тегенең артына тибә һәм, Җәмилнең кулыннан портретны тартып алып кире мунчага кереп китә. Тегеләр икесе дә шаккатып басып калалар

Җәмил Кем булды бу?

Иблис (*пышылдап*) Үзе!

Җәмил бер сүз дә дәшмичә, куен кесәсеннән аракы шешәсе чыгарып болдыр баскычына барып утыра. Иблис куркып кына мунча ишеге янына килә дә эчкә күз сала.

Иблис (*ярым пышылдап*) Иптәш Ленин! Иптәш Лени-ин!

Җәмил (*шешәнең авызыннан гына чөмереп*) Да, брат власть алмашына бугай. Теге тиле бүген юкка гына «Интернационал»ны җырламагандыр. Капкага тизрәк кызыл флаг элеп куярга кирәк.

Иблис. Аны хәзер генә кайдан табасың?

Җәмил. Тс-с (*Тыңлый*).

Җырлаган тавыш ишетелә.

Җимерик дисәң коллык, җәберне,
Яулыйк дисәң син барын да,
Дөрләт утны, тизрәк тимерне
Сугып кал кызу чагында

Иблис шундук кесәсендә булган вак-төяк кәгазьләрне йомарлап, ишек турысына сала да, шырпы белән ут төртә

Җәмил (*яна башлаган кәгазьләрне аягы белән таптап*). Нишләвең бу синең, мәлгунь!

Иблис. Соң, учак дөрләтегез, диләр ич.

Җәмил. Дөрләтермен мин сиңа, анаңны еккан нәрсә!

Иблис. Чү! Кызма әле син, тиган Кызыл флаг элеп куярга кирәк капкага.

Җәмил. Бар ул миндә. Теге Кытай Мансуры былтыр бер ярты га бабасының сандык төбендә яткан берничә флагын бүләк иткән иде. Шулардан хатынга трусик тектерергә иде исәп. Ильцин Чечняга гаскәр керткәч, сакларга булдым тагын. Дөньялар бик тыныч түгел мәйтәм. Татарстанга да бәреп керсә, ни эшләрсең?

Иблис. Алып чык алайса тизрәк! Соңга калмагаек!

Җәмил мунчага кереп китә. Озак тормый, бераздан кеше башы сояге төшерелгән кара әләм күтәреп чыга

Иблис (*борынын җыерып*) Анархистлар байрагы ич бу

Җәмил Шулаймыни? (*Аңа ышанмыйча әләмнең төсен карый*). Тфү! Караңгы, бит берни күреп булмый

Җәмил янә мунчага кереп китә. Иблис мылтыгын аркасына асып, маршировать итеп җырлый.

Ать-два ать-два..
Дошманга каршы сугышка
Ленин чакыргач безне,
Татбригада атка менде
Сакларга илебезне
Ать-два ать-два...

Җәмил ак әләм күтәреп чыга. Аны әй яктысында карый.

Җәмил. Җен алгыры! Бусы акларныкы икән

Кире мунчага кереп китә.

Кызыл байрак күтәреп янә чыга. Җырга ул да кушыла. Икәүләп ишегалды буйлап маршировать итеп йөриләр. Ать-два, ать-два...

Ишектә янә Мәчтүрә күренә.

Мәчтүрә Нәрсә революция башланды мәллә?

Җәмил. Чык хатын, иреңне сугышка озатасың хәзер!

Мәчтүрә (*коты очып*) Һай, Ходаем ул нинди сугыш тагын?

Җәмил. Безнең сугыш! Ленин терелде. Ильцин бәреп төшерелде. Ать-два, ать-два... Хәзер председательнең безнең акчаны талап төзегән өч катлы көттиджен тартып алабыз, аннары...

Мәчтүрә (*бот чабып көлә*). Тиле дип уйлаган идем мин сине, тик мондый ук тиле дип белмәгән идем

Җәмил (*Иблискә*) Турырак атла тәмуг сарыгы!.. Ать-два, ать-два... (*Мәчтүрәгә*) Ышанмасаң, әнә мунчага кереп кара. Анда Ленин үзе утыра. Атакыны шушыннан башлыйбыз, диде. Бар.бар. күзеңне акайтып торма, кереп хәлен бел. Партбилетым һаман да матрас астында, сине бер генә минутка да онытып тормадык, күңелебез белән Хрущев, Горбач, Ильцин вакытларында да гел синең янда булдык, диген. Гомерең буе китапханәдә җитмеш төңкәгә эшләп җыйган теге хәерче мең сумыңны яндырган Горбачны нишләтәбез, дип сора.

Мәчтүрә И, тилебәрән орлыгы ашаган нәрсә-ә! Кинога төшереп аласы иде бер кыяфәтеңне. Айныгач күрсәтергә иде шуны үзеңә. Кит, кит, әстәгъфирулла, мондый да кеше булмас, ахры, дөньяда. Кылан инде, булдыра алгач.

Мәчтүрә ишекне шап итеп ябып кереп китә. Шул чакны өтәч кычкырганы ишетелә. Иблис йөзтүбән карга каплана. Аның белән Җәмил дә сузылып ята

Җәмил. Нәрсә, һава һөҗүме башланды мәллә?

Иблис (*тотлыгып*). Ә-әтәч кычкыра бит

Җәмил. Кычкырса соң?

Иблис (*күңеле төшеп*). Кайтып китим мин булмаса, агайне.

Җәмил. Аһ син! Революция башланмас борын төртә каерырга җыенасыңмы? Атам, мәхәббәтсез! (*Мунчага таба башын борып кычкыра*). Иптәш Ленин! Иптәш Лени-ин!

Янә әтәч кычкыра. Иблис, аның башын карга төртеп, өстенә ята.

Җәмил (*чәбәләнеп*). Хыянәт! Хыянә-әт! Иптәш Лени-ин! Революцияне буала-ар!

Иблис (*Җәмилне ычкындырып*). Акырма, бөтен авылны аякка бастырасың бит! Тор, мин китәм!

Торып өс-башларын кагалар.

Җәмил. Бар, кит, көчләп тотмыйбыз. Түлке мылтыгыңны миңа биреп калдыр!

Иблис (*мылтыкны биреп*). Мә, сагынганда бер истәлек булыр.

Җәмил (*мылтыкны аңа турылап*) Эләктеңме! Революцияне сатмакчы булдыңмы? Киттек мунчага, Ленин янына!

Иблис. Нишләтмәкче буласың?

Җәмил. Анысын революцион трибунал хәл итәр.

Иблис (*өтәчләнеп*). Кемне, минеме? Бик беләсең килсә, мин коммунист, мин Социалистик Хезмәт Герое!

Җәмил. Күтәр кулыңны! Өскәрәк күтәр!.. Менә шулай.

Иблис (*яный*) Исән булсак, бер күрешербез әле, агайне. Мин сине кыямәт көнгә тикле казанда кайнатачакмын!

Җәмил. Әйдә, атлавыңны бел! (*Мылтык түтәсе белән Иблиснең аркасына төртә*). Атла, дим мин сиңа!

Күктән бер кәгазь бите очып төшә. Җәмил аны шундук эләктереп ала.

Җәмил (*кычкырып укый*). «Иптәш Әлмиев! Сез иң булдыклы агентны кулга алгансыз. Аны кичекмәстән ирекә чыгарырга әмер бирәм.

Мәскәү, ВЧК, Дзержинский, 1919 ел».

Иблис (*тантана итеп*). Ышандыңмы инде?

Җәмил. Тукта, тукта, нигә унтугызынчы ел әле ул?

Иблис. Сиңа барыбер түгелмени? ВЧК дип куелганмы?

Җәмил. Куелган.

Иблис. Пичәте бармы?

Җәмил. Бар.

Иблис. Шулай булгач, сиңа тагын ни кирәк?

Җәмил. Соң, без мең тугыз йөз дә туксан бишкә кердек бит инде.

Иблис. Керсә соң. Димәк, почтада озак яткан.

Җәмил. Ә Әлмиев кем?

Иблис. Белмим. Белергә дә теләмим! Бир мылтыкны!

Җәмил. Ашыкма, агайне. Трибунал башлыгының фамилиясе дер бу. Күтәр кулыңны! Менә шулай. Атла! Нишләтергә икәнен Әлмиев үзе хәл итсен.

Иблис (*горур тавыш белән шигырь сөйләп җибәрә*).

Без бүгеннән дошман!
Дуслыгымны саклар өчен
Йөрәгемдә бер хис тапмадым.
Бел!
Бүгеннән соң
Син һәм синең кебекләргә
Пуля саклап йөри башладым.

Җәмил аны мылтык түтәсе белән этә-төртә мунчага алып кереп китә.

ПӘРДӘ.

(Ахыры бар).

Баулары җиткән икән...

«Түбән Кама — урыс революциясе көзгесе: анда өйләр гөмбә кебек тиз үсә, һәр гаиләгә берәр машина туры килә», — дип яза

«Известия» гәзите.

«Тешсез» бомба

Бөгелмә районының Карабаш бистәсе янында буадан йөз метрлар ераклыкта көтмәгәндә-уйламаганда авиабомба табыла. Бу инде Татарстанда икенче очрак икән. Әлеге хәтәр нәрсә янына килергә куркалар. Белгечләр килеп, тикшерә башлагач, аның шартлаткычы алынган булуы ачыклана. Аны кем алган, бомба ничек монда пәйда булган? Тикшерүчеләр моны тиздән ачыклар.

Компьютерны алдап булмый

Казанның Совет районы эчке эшләр идарәсе инде берничә ел җинаятьчеләрне эзләп табу һәм аларның гаебен раслауда компьютер программасыннан файдалана. Бу вакыт эчендә «Сонд» мәгълүматлар банкында 7 мең дактокарта, ә «Фейс-Менеджер»да (җинаятьчеләрнең видеопортреты) 9 меңгә якын кеше теркәлгән. Элек җинаятьченең кем булуын ачыклау өчен калын-калын «дело»лар актарган булсалар, хәзер аны компьютер үзе эзләп таба. Быел гына да ул 18 җинаятьчене ачыклауга ярдәм итте. Компьютерны алдап булмый шул.

(«Милиция, законность, правопорядок»).

Алла Дудаева кайда яши?

Быел язын Ичкерия Республикасы Президенты Җәүһәр Дудаевның хатыны Алла Дудаева һәм кызы Дана, шулай ук улы һәм башка туганнары Ичкериядән Украинага күчеп киткәннәр иде. Октябрь аенда Дудаевның хатыны һәм туганнары Украинадан Грециягә күчеп килделәр. Алла Дудаеваның «Комсомольская правда» гәзите хәбәрчесе сорауларына биргән җаваплары шактый кызыклы. Ул Грозный шәһәре бомбага тотыла башлагач та, аннан күчеп китә. Юлга пистолет, патроннар, җылы кием, үзенең шигырьләр җыентыгын һәм иренең архивын алган була. Юлда алар утырган машинага аталар, аңа ут каба. Дуаевның архивы да машина белән бергә яна.

— Мин һәрвакыт үзем белән пистолет йөртәм, ләкин ул үз-үземне саклау өчен генә, — ди Президент хатыны. Ул урыс булып туса да, милләтен хәзер чичән дип атый. Озакламый Грозныйга кайтачагына өметләнә.

Юлбарыслар дусты

Тайгадагы Бичевая авылында ике сыердан артык терлек асрамыйлар. Файдасы аз, эше кыен. Ә менә җәнлекләр асрауда аучы Владимир Круглов рекорд куйган. Ул ике юлбарыс, өч аю һәм янут асрый. 54 яшьлек бу аучыны балалары да аңламый, чөнки юлбарысларга никадәр ит кирәк, вегетариан азык белән тукланучы Һималай аюлары да туймас җаннар.

Аннары Владимир Круглов авыл читенә соя чәчеп үстергән, печән чабып әйгән. Азык эзләүче тояклы хайваннар да бөтен тирә-яктан бирегә җыела икен.

(«Комсомольская правда»).

Татарстан Әбугалисинасы

Казанда «Әбугалисина» исемле фәнни-популяр журналның беренче саны дөнья күрде. Ул урысча да, татарча да чыгачак. Аны оештыручы — татар гимназияләренең Бөтендөнья ассоциациясе (ВАТУ). Башта әле ул елга өч тапкыр «Татарстан» журналының кушымтасы рәвешендә нәшер ителәчәк.

(«Казанские ведомости»).

Телефоннан янаучы тотылды

Ширәмәт аэропортын һәм Мәскәүдәге бер вузны шартлатам, дип телефоннан янаучы ике террорчы тотылды. Мәскәү эчке эшләр идарәсе хезмәткәрләре моны махсус аппарат исәпләп чыгарган мәгълүматларга таянып башкардылар.

Әлбәттә, башта өйрәтелгән этләр белән барып ул хәбәрнең дөресме-түгелме икәнен тикшерделәр.

Ялган хәбәр таратучыларның берсе Украинада яшәүче 23 яшьлек хулиган Мәскәүгә килеп фатир телефоныннан шалтыраткан. Икенчесе шәһәр үзәгендәге таксофонны файдаланган. Аларның берсен 3 ел төрмә көтә. Икенчесе исә психик авыру кеше булып чыккан.

Район гәзитләренә ярдәм килә

Хәзер матбугатка һәркем язылa алмый, акчасы юк. Шулай да районнарда яшәүче халыкны арзанлы гәзитләр — район һәм шәһәр матбугаты аша хәбәрдар итү, аларга кирәкле мәгълүматны биреп тору мөһим. Шуны истә тотып Русия Дәүләт Думасы район һәм шәһәр матбугатына икътисади ярдәм итәргә карар чыгарган иде. Шушы көннәрдә (29.11.95) «Район (шәһәр) гәзитләренә икътисади ярдәм турында» федераль закон дөнья күрде.

(«Российская газета»).

Өй туйлары артыр

1996 елда Татарстанда 3500 гаилә начар, җимерек йортлардан яңа, уңайлы фатирларга күчәчәк, дип яза «Аргументы и факты» атналыгының Татарстандагы кушымтасы. Хәзерге вакытта республикада тузып беткән йортларда 40 мең гаилә яши икән. Шуларның 32 меңе — Казанда, калган 8 меңе Чистай, Зеленодол, Бөгелмә, Алабуга кебек шәһәрләрдә. Бу гаиләләрне уңайлы фатирларга күчереп бетерү өчен 2,5 миллион квадрат метр торак кирәк. Аны төзү өчен хәзерге бәяләрдә 5,5-7 триллион сум акча сорала. Алдагы елда 3,5 мең фатир төзү күздә тотыла. Шуның 3 меңе — Казанда. Җөмһүриятебездә бу җәһәттән 2570 фатир бүленде инде.

Төркиядә укучыларыбыз күпме?

Төркиянең Әнкара, Истанбул, Измир кебек шәһәрләрендәге дәрәҗәле университетларда Татарстаннан 100 студент укый. Шуларның 19ы, Казандагы һәм Төркиянең Иске шәһәрендәге төрек-татар колледжларын тәмамлап, быел гына төрек студентлары сафына басты.

(«Аргументы и факты» атналыгы кушымтасы).

Ябыгам ди торгач...

Кайсы гына хатын-кызның төз гәүдәле, ыспай, матур буласы килми икән? Моның өчен тазарудан котылырга, ябыгырга тырышалар. АКШта ябыгырга омтылучылар хәрәкәтенә 37 миллион хатын-кыз кушылган. Барысы да авырлыкларын 5-10 килограммга киметергә телиләр. Соңгы вакытта бу хәрәкәтнең зыянлы яклары да сизелә башлады. Табиблар кечләп ябыгу нәтиҗәсендә хатын-кызларда невроз һ.б. шундый авырулар барлыкка килүен әйтәләр. АКШта шуңа бәйле авырулардан елга 150 мең кешенең үлүен дә исәпләп чыгарганнар. Бу — 177 илдә СПИДтан (әлеге авыру билгеле булганнан бирле) үлгәннән күбрәк икән.

(«Женщина»).

Тәхетле, димәк — бәхетле

Борис Ельцин үзен рәсми төстә икенче срокка президентлыкка кандидат итеп күрсәткән. Мәскәүдә аны тәкъдим итү җыелышына Русиянең 25 төбәгеннән кешеләр килгән. Болардан тыш, бу җыелышта 200ләп кеше катнашкан. Аларның байтагы 1991 елда «Ак йорт»ны саклаучылар икән.

(«Российская газета»).

Маймылдан туган бала

Бу могҗизаи хәл турында заманында барлык гәзитләр язып чыккан иде. Быел Андрей Киевтагы мәктәпләрнең берсендә икенче сыйныфта укый. Күптән түгел ул әнисе — шимпанзе маймылы белән очрашты.

Бу — ана белән баланың гаҗәеп җылы очрашуы булды, — диде моннан сигез ел элек, 1987 елның 6 декабрендә яңа туган баланы кабул иткән акушер Алексей Густов. — Шимпанзе малайны шулкадәр яратып күкрәгенә кысты, куллары белән Андрейның бөтен тәнен сыйпап чыкты, аның күзләрендә яшь иде. Ана баласын таныды! Андрей исә үзенең биологик әнисенә — үзен тудырган шимпанзега куркынып карады. Аннары бик тиз ияләште һәм аны кочаклап ук алды. Алар бер авыз сүз сөйләшмәсә дә, әйбәт аңлаштылар. Бу — дулкынландыргыч очрашу иде. Ана белән баланың очрашуы 15 минутка сузылды.

Малай тугач, белгечләр аны бер елдан да артык тормас, дигәннәр иде. Ә ул исән һәм әйбәт кенә үсеп килә. Шимпанзе тәрбиясендә өч ай яшәгәч, малайны булачак әти-әниләренә, Украинага алып китәләр. Кеше баласының сау-сәламәт тууы үзе бер могҗиза. Яралгыны шимпанзе карынында үстерү идеясе галимнәр арасында бәхәс китереп чыгарса да, маймыл аналыгына күчерелгән эмбрион нормаль үсә. Сигез ел элек бу экспериментка галимнәр үзләре дә ышанмый, югыйсә.

— Шимпанзе тудырган бала һәр яктан сәламәт, — ди акушерлык буенча француз белгече Франсуа Жерар. — Шулай да мин сабыйның иммун системасы маймыл карынында нормаль үсәр дип уйламаган идем, чөнки кеше белән шимпанзе арасында генетик һәм гормональ яктан аерма шактый. Малайның һәр яктан сәламәт үсүе — феноменаль күренеш. Мин бу экспериментка каршы булдым, һәм ул яңадан кабатланмас, дип уйлыйм.

(«Всемирные новости»).

РЕДАКЦИЯДӘН. Кем белә, Андрейның маймыл карынында үсүе, бәлки, алай ук начар да түгелдер. Чөнки шимпанзе эчми, тартмый, сүгенми, бөтен дөньяга ачулы да түгел. Көменле чагында да, көн саен бәяләр күтәрелүне көтеп, базар икътисадыннан куркып та яшәми. Безнең бүгенге хәлебез маймыл тормышыннан күпкә кайтыш түгелме соң?

УНӨЧЕНЧЕ БИТ

Сәер самолет

Мин — самолет бүген, канатсыз...
Әхсән БАЯН.

Күтәрелештәге самолет мин...
Ник күрмисез?
Ренат ХАРИС.

Җил исүгә — очам: самолет мин,
Самолет мин, ләкин канатсыз...
Ишетмәссез мотор гүләвен дә
Күпме генә тыңлап-карап сез.

Чөнки минем моторым да юк бит —
Гаҗәп самолет мин — бензинсыз;
Иллюминатор да, койрык та юк —
Шундый самолет мин — бер нисез!

Шундый сәер, котсыз самолет мин —
Очмыйм да мин, хәтта кузгалмыйм.
Дөрес, гафу, җил искәндә очам —
Чөнки җиңел, коры тузан мин!

Әгәр берәү...

Әгәр берәү
Борын чөйсә,
элеп куярлар
шул борынга
бер җилән,
пальто-мазар...
Бикә РӘХИМОВА

Әгәр берәү
борын казыса,
бөреп чыгар аннан чишмә
һәм ул агар
түбән таба...

Әгәр берәү
колак тырпайтса,
куяннар аны
өрекмән дип уйлар...

Әгәр берәү
күзен тозландырса,
күпләр,
акча тотып,
чират торып,
аннан тоз сорар...

Әгәр берәү
авызыннан
карга очырса,
ул авыз, димәк,
карга оясы...

Әгәр мин
шушы юлларны язсам,
әгәр берәү
чигә тирәсендә
бармак биетсә,
димәк, ул
шушы юлларны
укыган булыр!



● Автошарж.

Ләбиб Лерон кытыклары

Мөдәррис рәис булгач...

(Шаяру)

XX гасырның соңгы тешләре коелыр чиккә җиткән көннәрдә татар дөньясының әдәби мохите кискен үзгәрешләр кичерде. Бер төркем каләм әһелләренең «Китмә, Сафич!» дип гозерләнеп ялваруына карамастан, Ринат Мөхәммәди Язучылар берлеге рәислегеннән китте. «Шактый йончыдым, ял итәсем килә», — диде ул яңа эшкә — әдәбият министры вазифасына керешү уңаеннан уздырган матбугат конференциясендә.

«Хуҗа урыны буш тормас», диләр. Хактыр: Ринат Мөхәммәди яңа кәнәфигә утырган арада Язучылар берлегенә рәис булып үз теләге белән шагыйрь Мөдәррис Әгъләм килде. Иң әүвәл Әгъләм урысчаны шәп белгән дусты Зөлфәтне язу-сызу, кәгазь арасында чокчыну эшләре буенча урынбасар итеп алды. Туда-суда барып килү кебек эшләр белән шөгыльләнергә тиешле икенче урынбасары урынына Эдуард Мостафинны куйды. Урындык-мазарга утырып эшләргә күнекмәгән Эдуард, Мөдәрриснең үзе белән яшьтәш күн букчасын әләктереп, шундук кибеткә, кирәк-яраклар алырга чыгып чапты.

Эш бүлмәсенең җитди үзгәрешкә мохтаҗ икәнлеген Эдуард чыгып китүгә үк чамалап алды Мөдәррис: кабул итү бүлмәсендә телефон шылтыраганын көтеп утырган сәркатиб кызны чакырып кертте дә сусыз самовар тирәсендәге уймак хәтле касәләрне кырлы стаканнарга алыштырырга кушты.

Бүлмәдә затлы телефон сайрарга тотынды. Әгъләм трубканы җәһәт кенә алды да колагына якынайтты. Әхәт Гаффар икән. Мөдәррисне рәис булуы белән котлавы.

— Кыстати, Мудрыйк әкә, быел Тукай премиясен миңа бирерсең, җәме?! Башка кандидатура эзләп маташма. Юкса хатын... халык дөрес аңламас! — дип, үгезнең мөгезеннән алды Гаффар.

Үзе Тукай премиясе лауреаты булганга күрә, Мөдәррискә бу бүләкне кем алса да барыбер иде.

— Гәзитләрдә үз иҗатың турында мәкаләләр чыгарта тор, — дип киңәш итте Мөдәррис.

— Ню! — диде Әхәт Гаффар. — «Ватаным Татарстан»да иҗат портретым ята. «Шәһри Казан»да да бар, диләр... Ә «Мәдәни җомга»га псевдоним белән үзем язам...

— Иҗат портреты дигәннән, тиздән минем яңа китап чыга, — диде рәис.

— Ню!

— Премияне сиңа бирергә исәпләп торам...

— Аңладым, Мудрыйк әкә... Сыра эчәргә бармыйсыңмы? Ню?!

— Иртәгә! — диде Әгъләм һәм трубканы куйды.

Мөдәррис пинҗәк кесәсеннән фатир ачкычы белән бергә аунап яткан кипкән балык койрыгын алып, иреннәре арасында җебетергә дә өлгермәде, янә телефон шалтырады:

— Сәлам, бөегем! Котлыйм! Нишләп ятыш?

Әгъләм тавыш иясен шундук танып алды: Марсель Гали, әле генә Азнакайдан кайткан икән.

— Чатыр тау урынындамы? Бу юлы Азнакайдан нәрсә алып килдең? — диде Мөдәррис, Марсельнең туган төбәгеннән буш кул белән килмәгәнлегенә тәгаен инанып.

— Ерунда-а-а... Ике капчык бәрәңге... Берсе-берсе карбыз чаклы... Каклаган каз... Үзең беләсең инде, бездә казны каклый беләләр... Синең Зөяңнең ун казын бер үзе бәреп ега... Өч литр бал... Натуральный! Карабодай. Тагын кайбер вак-төякләр дә кыстырып җибәрделәр... Карале, бөегем!.. Быел Тукай премиясен миңа хәл итәсе иде бит инде...

— Баягынак Әхәт Гаффар да үзенә сорап шалтыраткан иде...

— Што-што? Гаффун былтыр гына ала язды түгелме соң?! Ел саен бер үк кешеләр булмас... Әле Миңнуш, әле Гаффун... Гаффунга киләсе елга бирерсең!..

Мөдәррис трубканы куеп, балык койрыгын кесәсенә кабат шудырган вакытта ишекне шакып-нитеп тормыйча гына, бүлмәгә бер кочак кәгазь күтәргән Зөлфәт килеп керде.

— Язучылар берлегенә әгъза итеп кичекмәстән алынырга тиешле кешеләрнең исемлеген әзерләдем, — диде ул һәм кәгазьләрне Әгъләмнең өстәленә таратып ташлады. — Бу исемлектә — «Чаян» авторлары, бусында — колхоз рәисләре, ә менә монысында — пенсионерлар, сатучылар, вахтерлар, сыер савучылар...

Мөдәррис кәгазьләрне күздән кичереп алды да Зөлфәтнең сыра күбегенә охшатып таралган бөдрә чәчләренә карап:

— Араларында язгалаучылар да бармы? — дип сорады.

Зөлфәт рәиснең туры соравына туры җавап кайтарды:

— Бар!

— Алайса бөтенесен дә берьюлы алырга кирәк! — диде Әгъләм катгый төстә.

Зөлфәт кәгазьләрен кире күтәреп чыгып китүгә, Әгъләм телефон трубкасына үрелде. Исәбе Илбашка шалтырату иде аның.

— Чордаш, миңа «Халык шагыйре» исемен бирү турындагы фәрманың матбугатта нишләптер күренми әле, — диде ул Илбашның «Ни хәл, Әгъләм?» дигән сүзләрен ишеткәч. Илбаш мәсьәләнең уңай хәл ителгәнен әйтте дә сүз уңаеннан рәисне олуг исем алуы белән чын күңелдән котлады, аңа иҗади уңышлар, саулык-сәламәтлек һәм озын гомер теләде.

— Миннән соң исемне Зөлфәткә бирергә хәстәрләсәк иде. Тукайның йөз егерме еллыгы тирәсенә чамаларга була. Аңарчы бер-ике шигырь, өч-дүрт кереш сүз, минем иҗат турында биш-алты мәкалә язса, Зөлфәтнең ярсу шигърияте олпат төс алып өлгерәчәк! — дип Мөдәррис якын дусты хакында аталарча кайгыртырга да онытмады. Дәрәҗәле исемне Мөдәррис белән Зөлфәтнең икесенә бергә бирергә дип кичә кич үк пләнлаштырып куйган Илбаш рәиснең дусты турындагы үтә җитди тәкъдиме белән берсүзсез килеште.

Илбаш белән шулай дустанә сөйләшеп алганнан соң, Әгъләм рәис халкына хас дәрт-дәрман белән, каударланып, Мулланур Вахитовның гаять четереклe язмышы һәм революцион эшчәнлеге турында «Агач күпер» дигән документаль роман-трилогия язарга керешге. Моңарчы вак-вак хикәяләрдән гайре чәчмә әсәр язып карамаган Мөдәррис романга бик җиңел кереп китте. Дөрес, романның язылган кадәресе, әгәр укып карасаң, гап-гади укучы түгел, Әгъләм үзе дә аңламаслык иде. Хәер, язмышлары катмарлы булган революционерлар турындагы роман шулай катлаулы булырга тиеш тә.

Мөдәррис, язуыннан туктап, сигарет кабызды, бер мәлгә ләззәтле уйга чумып алды: «Төркиягә барып, «Агач күпер» буенча егерме бер серияле нәфис фильм төшерү мәсьәләсен хәл итәсе булыр...»

Әгъләм шулай уйланып,бөтен җаны-тәне белән тантана итеп утырган вакытта ишек тарафында икенче урынбасар — Эдуард Мостафин пәйда булды. Эдуард, туктальп, отыры кызарган чыраендагы эре тир тамчыларын кул аркасы белән идәнгә коеп төшерде дә, канәгать елмаеп, түргә таба атлады, шактый юанайган букчаны Әгъләмнең аяк очына җайлап кына куйды. Букча эчендәге кирәк-ярак, күңелгә — дәрт, җанга илһам бирердәй матур аһәңнәр чыгарып, җиңелчә генә чыңлап алды...

... Мөдәррис үз биләмәсендәге эшләрне җайга салып бетергәч, игътибарын Язучылар берлегенә кагылышлы журналханәләргә юнәлтте. «Казан утлары»ның баш мөхәррире Равил Фәйзуллинга ул көтелмәгән тәкъдим ясады:

— Мөхәррир булып эшләп арыганыңны беләм, шигырь язудан барыбер туктамаячагыңны беләм, машина ятратканыңны беләм... Әйдә, минем «Джип»ка шофер булып кил! — диде.

Ошбу тәкъдимне ишеткәч, Равил Фәйзуллинның ындыр табагы чаклы маңгае күз алдында тагы да киңәйде, баш чүмеченә елышкан чәчләренең һәммәсе үрә катты. Мөхәррир шулкадәр дулкынланды ки, хәтта Мөдәрриснең өстәл өстендә җемелдәп яткан авторучкасын үз кесәсенә салып куйганын сизми дә калды.

Ниһаять, ул телгә килде:

— Син... син нәрсә, әкә... Син нәрсә! Мин бит — шагыйрь!

— Беләм, дустым, беләм, — дип, Мөдәррис каләмдәшенең җилкәсенә кулын куйды. — Халык та шагыйрь...

— Миңа кагылма инде син, әкә... Шофер кирәк булса, әнә, Хөсниярны ал... Ул шәп йөртә машинаны.

— Йөртүен аны мин дә йөртергә могу... Миңа шофер кирәк! Ватылган саен төзәтә белгән шофер! Иә, ярый, мин шаярттым гына... Журналны әлегә чыгара тор. Шулай да минем тәкъдим турында уйлан.

Сөмсерә коелган Фәйзуллин рәис бүлмәсеннән чыкты. «Бу — Мөхәммәди генә түгел бу! Бу — өлләкем бу!» — диде Фәйзуллин коридорның бер башында сигарет төтәтеп торган Рөстәм Мингалимгә.

— Эшләр болай барса, киләчәктә тагын да матуррак яшәрбез әле! — диде Мингалим һәм, төтенне аралап, матур итеп елмайды.

Фәйзуллиннан соң чират «Салават күпере»нең баш мөхәррире Зиннур Хөсниярга күчте.

— Бала-чага журналын күп тарттың, «Казан утлары»на җигелергә вакыт сиңа, — диде аңа Әгъләм.

Хөснияр бу хәбәргә сөенергә дә, көенергә дә белмәде.

— Фәйзуллин китәмени, минем урынга кем килә? — диде ул, «Салават күпере» редакциясенең ремонттан башы чыкмаган машинасы турындагы уен очлый алмыйча.

— Заһид Мөхмүди килергә атлыгып тора, — диде Әгъләм. — Мин эшләп карамаган редакцияләрдән бердәнбер «Салават күпере» генә калды, ди... Төкшту, уйлана тор, Хөснияр!

Зиннур «Казан утлары» журналы редакциясенең «Волга» машинасы хакында уйлана башлаган иде инде...

— Мине котлый аласың, — диде Хөснияр Мингалимгә коридорга чыккач.

— Котлыйм! — диде Мингалим.

— «Казан утлары»ның баш мөхәррире мин хәзер!

— Шәп. Бик шәп булган! — диде Мингалим.

— Әгъләмгә мине Илбаш үзе тәкъдим иткән!

— Булыр, булыр, — диде Мингалим. — Була торган хәл...

... «Идел» журналының баш мөхәррире Фәез Зөлкарнәй мәсьәләсендә бераз сабыр итәргә булды Әгъләм. Ник дигәндә, әле генә шул журналда Мөдәрриснең бер көлтә шигыре басылып чыкты. Өстәвенә, «Идел» бухгалтеры шактый мул гонорар тоттырды Мөдәррискә...

Әгъләм сигарет кабызды да тәмләп төтен суырырга тотынды...

Татар язучыларының күрәчәге алда иде әле.

Тиздән Татарстанның Милли китапханәсе оешуга 130 ел тула. 14—15 декабрь көннәрендә Казанда бу уңайдан зур фәнни-гамәли конференция узачак. Әңгәмәгә без Милли китапханәнең директоры, шагыйрь Разил Вәлиевне дәштек.

Разил ВӘЛИЕВ:

«Без халыкның хәтере өчен җаваплы»

— Разил әфәнде, Татарстанның баш китапханәсенә 130 ел... Аның инде үз җисеменә туры килердәй исем белән яши башлавына, ягъни милли китапханә дип аталуына да дүрт ел. Әлеге статус китапханәбезгә нинди төп үзгәрешләр алып килде?

— Үз эшен китапханә 130 ел элек, хәтта аннан да элегрәк башлаган дидек. Әмма Татарстан Автономияле Республикасының В.Ленин исемендәге китапханәсе буларак, ул әле ниндидер бер өлкә китапханәсе — Ульяновски, Рязань, Вологда кебек өлкәләрнең китапханәләре статусында иде. Менә шушы Милли китапханә исемен алгач, безнең офыкларыбыз киңәйде. Бурычларыбыз, эшебез дә артты, билгеле. Тик без эш артканга һич кенә дә көенмибез, киресенчә, сөенәбез генә. Чөнки без бу статусны үзебез сорап, үзебез таләп итеп алдык. Әгәр без Татарстанның баш китапханәсе икәнбез димәк, татар халкының хәтере өчен җаваплыбыз, аның рухи хәзинәләрен туплап, саклап, барлап торырга тиешбез.

Татар халкы бер Татарстанда гына да яшәми бит әле. Димәк, без — Татарстанның гына түгел, татар халкының да баш китапханәсе.

Яңа статус алуга ук яңа бер бүлек — кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге ачтык. Татар халкы 1917 елгы түнтәрелешкә чаклы (әле кайчан гына рөхсәт бирелеп бит әле!) 15 мең исемдәге китап бастырып чыгарган. Ул вакыттагы Русиядә урыслардан кала иң күп китап бастырган халык без. Нәкъ менә шушы хәл, бәлки, безне халык буларак саклап та калгандыр. Әмма бүгенге көндә ул китаплар, кулъязмалар аяныч хәлдә. Хәтта шундый очраклар да бар: картаеп-олыгайгач, рәнҗетелмәсеннәр диптер инде, күпләр иске кулъязмаларны, китапларны зиратларга күмгәннәр. Шуны белеп, әлбәттә, Милли китапханә тиз арада иске кулъязмаларны, сирәк китапларны җыю эшенә керешә. Әгәр 1991 елда китапханәдә гарәп язуындагы нибары берничә йөз татар китабы булса, хәзер аларның саны 3 меңгә якынлашып килә, ә кулъязмаларның саны тагын да күбрәк. Безнең бу эшне ишеткән әбиләр-бабайлар, шулай ук яшьләр дә үзләрендәге китап-кулъязмаларны безгә китерергә тырышалар. Без ул китапларны яхшылап төплибез, рәтлибез, дәвалыйбыз.

Аннан соң инде менә җиде ел рәттән, безнең китапханәдә гарәпчә язуны өйрәтү дәресләре бара, ел саен 60—70 кеше шул язуны укырга өйрәнеп чыга.

Гомумән, Милли китапханәнең әһәмияте турында шуны да әйтеп үтәсем килә. Әгәр без тулы хокуклы, бәйсез дәүләт төзергә телибез икән, әгәр без дөнья халыклары алдында цивилизацияле халык булырга телибез икән, үзебезнең үткәнебезне яхшы белергә тиешбез. Ә бит еш кына бүгенгебезне дә белеп бетермибез. Әйтик, татарның төгәл санын да белмибез бит. Берәүләр аны җиде миллион, ди, берәүләр — унбиш, берәүләр егерме миллион, ди. Без үз халкыбызның бүгенге санын да белмәгәч-ачыкламагач, ничек итеп инде тагын үз тарихыбызны белик?

Менә шулай уйлап, без үзебезнең Милли китапханәнең бу бәйрәмен бәйрәм итеп кенә түгел, ә эш рәвешендә билгеләп үтәргә булдык. Әлбәттә, театрга җыелып, җырлап-биеп, бүләкләр тапшырып та бәйрәм итеп була. Анысы да кирәктер. Әмма эшлисе эш күп әле, сөйләшер-аңлашыр сүзләр күп. Өч тиенлек эш эшләп, биш тиенлек бәйрәм үткәреп йөреп әллә ни кырып булмас. Менә шуңа да фәнни-гамәли конференция итеп үткәрәбез 130 еллыкны. Бу елда иң зур эшләнгән эшебез, бәлки, шул булыр.

— Милли китапханәнең мәһабәт бинасына һәркем сокланып, аның белән горурланып үтәдер. Соңгы елларда аның төс-кыяфәте тагын да матурайды кебек. Ә эчке яктан ул Сезгә ничегрәк күренә?

— Әлбәттә, китапханәнең төп матурлыгы эчендә. Безнең Милли китапханә исә Казандагы иң матур биналарның берсенә урнашкан. Гомумән, ул матур бинада булырга тиеш тә, дөньяның барлык китапханәләре иң гүзәл биналарда эш итә.

Ә инде безгә килгәндә, китапханәбез эчке яктан тагын да ныграк үзгәрде. Әйткәнемчә, анда сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге ачылды. Биредә гыйльми консультант булып академик Әбрар Кәримуллин да эшли. Менә дигән галим егет-кызларыбыз бар. Ул да түгел, китапханә эшләрен компьютерлаштыру бүлеген ачтык. Эшне заман таләпләренә җавап бирерлек итү өчен егермедән артык компьютер сатып алдык. Бу бик мөһим: әгәр дә мәгълүматны туплап, тәртипкә сала белмәсәк, заманнан артта калачакбыз. Шулай ук китапханәдә электрон почта урнаштырдык. Үзебезгә килгән бөтен мәгълүматны без компьютерга кертеп, туплап барабыз. Аннан әле тагын нәни генә бер типография дә ачып җибәрергә уйлыйбыз. Киләсе елда үзебездә бик үк зур булмаган китаплар да бастырып чыгара алачакбыз, дип уйлыйм.

Дөньяның башка зур китапханәләре белән элемтәдә тору өчен тагын бер яңа бүлек — халыкара китап алмашу бүлеген ачтык. АКШ Конгрессы китапханәсе, Төркиянең, Франциянең Милли китапханәләре, Британия дәүләт музее, Германиянең Бундестаг китапханәсе, Япония, Кытай һәм башка кайбер илләрнең милли китапханәләре белән элемтә урнаштырдык, килешү төзедек. Үзебезгә кирәк мәгълүматны без алардан сорап алабыз, үзебездән биреп торабыз. Бу искиткеч зур эш. Беренчедән, Милли китапханәнең фондларын баетсак, икенчедән татар халкының һәм Татарстанның исемен, исемен генә түгел — җисемен дөньяга таныту белән шөгыльләнәбез.

Мин үзем АКШ Конгрессының китапханәсендә булдым, анда безнең белән нык кызыксыналар. Шул китапханәдә үземә таныш булган, әле үзебезнең чорда яшәгән шагыйрьләрнең — Зөлфәтнең, М.Әгъләмовның, Р.Әхмәтҗановның, Ф.Сафинның һәм башкаларның китапларын күрдем. Бездә юка гына дәфтәр калынлыгында гына чыккан ул китапларны калын тышлык белән матур итеп тышлаганнар, алтын хәрефләр белән исемнәрен язганнар, сакларга куйганнар.

Ул китапханәнең директоры Джеймс әфәнденең бездә дә булганы бар. Тик ул китапханә директоры гына түгел, ә бәлки АКШ Президентының мәдәният һәм мәгълүмат буенча киңәшчесе дә. Анда әлеге китапханә директорын Президент үзе сайлап, билгеләп куя.

Ярый, бәйрәм булгач, бәйрәмчә булсын, үз хезмәткәрләребезнең бик тә тырыш, фидакарь булуларын да әйтеп китим әле. Менә бер мисал. Без хәзер революциягә кадәр чыккан китапларның тулы фәнни каталогын төзү белән дә шөгыльләнәбез. Бу бик зур эш. Әлеге дә баягы унбиш мең исемдәге китапның һәрберсен эзләп табарга кирәк. Бу китап, мәсәлән, ничәнче елны, кайда чыккан? Аның авторы кем? Кайларда саклана? Рәсемнәре бармы? Гомумән, һәр китапка җентекле тасвирлама бирү кирәк. Бу китап, әйтик, Татарстан Милли китапханәсенең кайсы шүрлегендә урын алган, ничәнче сан белән билгеләнгән?

Урыслар биш меңнән артык китапларына әнә шундый тасвирлама-каталог төзеделәр. Кырыктан артык фәнни оешма бу эшне ун елдан артык вакыт эчендә башкарды. Бездә исә Ә.Кәримуллин җитәкчелегендәге 3—4 кеше менә шундый зур эшне үз җилкәләрендә алып бара. Шулай булгач, бәйрәмебезнең дә эш белән, бик тә җитди эш булып узачагына шикләнмисездер...

- ***Татарстанда дәүләт карамагында барлыгы 1656 китапханә эшли.***
- ***Әлеге китапханәләрдә 1995 елның 1 гыйнварына 24 миллион 832 мең 799 данә китап теркәлгән.***
- ***Республикабызда 3 мең 231 китапханәче эшли. Шуларның 1 меңгә якыны югары һәм махсус белемле.***
- ***Татарстан Милли китапханәсенең китап фонды 3 миллионнан артып китте. Анда 152 китапханәче хезмәт күрсәтә, 132 се — югары һәм махсус белемле.***
- ***Татарстан Милли китапханәсе республикабыздагы барлык китапханәләр өчен методик үзәк булып тора.***

«Белем — иң кыйммәтле капитал»

Әңгәмәдәшем — Казан дәүләт университетының физика факультеты деканы профессор Альберт Ваганович Аганов. Урысча сүз башлавым булды, ул саф татар телендә сөйләшүгә күчмәсенме!

— Әйе, мин яртылаш әрмән, — дип башлады ул сүзен. — Әтием белән әниемне язмыш сугыш алдыннан Монголиядә таныштырган. Сугыш вакытында миңа әбием белән авылда яшәргә туры килде. Шунда кереп калган инде миңа татар теле. Ә соңгы вакытта ике-өч ел инде менә, сүзлек байлыгымны арттырырга тырышам. Безгә укырга килә торган кешеләрнең яртысы татар бит. Теләсәң-теләмәсәң дә, аның үз телендә сөйләшергә кирәк. Гомумән, безнең факультет, студентлары университетта беренче буларак татар телен өйрәнә башладылар, һәм бернинди мәҗбүриятсез! Факультетыбызда укучы студентларның яртысы — татарлар. Университетта бу норманы үти торган бердәнбер факультет без.

Быел безнең физика-математика факультеты составыннан аерылып чыгуыбызга 35 ел тулды. Ә физика-математика факультетына беренче кабул итү 1805 елда булган, ягъни без инде 190 яшьтә дигән сүз.

— Факультетыбызда 450 кеше эшли, шуларның 200е фәннәр докторы һәм кандидаты (үзе бер институт дигән сүз!) Русиядә ул элита санына керә, ә Аурупа университетларының беренче дистәсендә тора.

Факультетыбызда белем бирү иң югары стандартка җавап бирә.

— Сездә укып чыккан белгечләр кайларда эшли?

— Шәһәребезнең барлык югары уку йортларында безнең белгечләр эшли. Факультетыбызны быел тәмамлаган Назарецкий дигән егетебезне, мәсәлән, Германиянең Байрот университетына, Ирек Мөхәммәтшинны Япониянең Каназава университетына аспирантурага чакырдылар. Тагын биш егетебез Германиядә, Америкада укый. Шулай гел чакырып торалар. 15—20 кешебез өзлексез чит илдә йә укып, йә эшләп тора.

Аннары шуны да әйтергә кирәк: Казан шәһәрендәге югары уку йортларында 18 студент Сорос стипендиясе ала (хәтерем ялгышмаса, алар барысы да безнең университетта), шуның 12се — физика факультетында. Берничә студент Президент стипендиясе (Русиянекен билгеле) ала.

— Ә Татарстан Президентыныкы юкмы?

— Андый стипендия булдырылмаган әле. Аннары физика һәм башка кайбер фәннәр буенча исемле стипендияләр, Казан шәһәре хакимияте стипендияләре булдыру артыннан да йөрибез...

— Алайса сез бернинди проблемасыз яшисез дияргә була.

— Проблемасыз яшәсәң, дөнья гомумән үсүдән туктар иде. Урта мәктәпләрдәге белемнең, әзерлекнең начараюын гына алыйк. Мәктәп программасыннан физика юкка чыкты. Шуннан киләләр бит инде безгә абитуриентлар!..

— Бу хәлдән чыгу юллары бармы соң?

— Университет каршында эксперименталь мәктәп-лицеебыз бар. Анда физика, математика һәм башка фундаменталь фәннәр укытыла. Чаллыдагы физика-математика мәктәбе, Казандагы 131 нче, Зеленодолдагы физика-математика мәктәбе белән турыдан-туры килешүебез бар, анда безнең үзебезнең укытучыларыбыз укыта, һәм безгә алардан бик көчле абитуриентлар килә. Ләкин безгә авылдан аз киләләр. Ә без аларны бик кирәксенәбез. Менә бу әңгәмәне укысыннар иде дә мәктәпне тәмамлаучы авыл егетләре-кызлары, безгә таба юл белән борылсыннар иде.

— Факультетыгызда укуны заманга яраклаштыру максатыннан ниләр эшләнә?

— Бу мәсьәләдә без укуны бик нык үзгәрттек. Компьютерны һәм башка шундый техниканы профильле уку йортлары дәрәҗәсендә укытабыз, чит телләрне укытуны бик нык көчәйттек (һәм түләүсез укытабыз), ул да бит бүгенге көн таләбе. Ике баскычлы укыту формасын үзләштердек. Студент, 4 ел укыгач, бакалавр булып, тагын ике ел укыгач, магистр булып чыга. Бүген белем — иң кыйммәтле капитал. Коммерция нигезендә аерым программа буенча индивидуаль укыту бүлеге ачарга да ниятлибез.

— Уңышларыгыз да күп, эшлисе эшләрегез дә бихисап икән әле. Бәйрәмегез котлы булсын!

Әңгәмәне Саимә ИБРАҺИМОВА үткәрде

НИК ДӘШМИСЕЗ, КЕШЕЛӘР?

АРАКЫНЫ КЕМ ЧЫГАРГАН?

21 — 22 ДЕКАБРЬДӘ ТАТАРСТАН ХАТЫН-КЫЗЛАРЫНЫҢ III КОРЫЛТАЕ АЧЫЛА

Мин аны үзе үлгәч тә сагынып, юксынып яшим. Бөтен авыл халкына ярдәм итеп, үзенең киңәшләре, шифалы куллары белән һәркемнең күңел түрендә урын алды ул. Сөмбелә шәфкать туташы иде. Үз эшен шулкадәр белеп, яратып башкарды ки, кем баласының нинди авыру кичерүе, кайчан прививка ясалуына кадәр белә иде. Куллары шифалы иде Сөмбеләнең, сүзләре шифалы иде. Сызылып киткән кара кашлы, ай йөзле, ыспай гәүдәле, җиңел сөякле иде ул. Аның ире укытучы. Белемле, кызыксынучан, музыканы ярата, үзе дә бик матур балалар җырлары иҗат итә иде.

Галимҗан белән Сөмбелә укытучылар йортында яшиләр иде. Аннан авыл читендә яңа урамга бер дигән йорт салып чыктылар. Балаларының икесе дә югары белем алды.

Балаларын аракы сөременнән саклый алды Сөмбелә, ләкин нинди бәягә! Үзен корбан итү бәрабәренә. Сабыр иде Сөмбелә, кайгы-хәсрәте булса да кешегә сиздермәс иде. Миңа берара аларның күршесе булырга туры килде, шунда гына мин аның нинди газаплар чигеп яшәгәнен белдем. Галимҗан эчкеч бөтенләй йокламый икән. Авызына аракы керсә, лыкынганчы эчә икән. Сабыр савытының тулган чагы булдымы, Сөмбелә шундый кичләрнең берсендә мине дә үзләренә дәште. Шулкадәр дә итагатьле, әдәпле Галимҗанны җен алыштырган диярсең. Беркемне тыңламый, эчкән саен исерә, исергән саен бәйләнчекләнә бара. Кулына гармун алып ике-өч көйне дүрт сәгать буе уйнады. Хатыны да, балалары да, мин дә, тамашачылар булып, аның талантына сокланырга, мактау сүзләре әйтергә тиеш идек. Инде ярты төн узды, әллә кайчан йокларга вакыт, сәгать ике, өч тулды. Бөтен күршеләрне бимазалап, Галимҗан һаман гармун уйнады. Эчә-эчә аракысы бетте, төнге сәгать өчтә Сөмбеләне, теләсәң каян аракы тап, дип чыгарып җибәрде, үзе ишекне бикләп куйды. Ярый әле сарайда яшергән аракысы булган, Сөмбелә бу юлы бик тиз әйләнеп керде. Галимҗанның бәйрәме иртәнге бишкә кадәр дәвам итте. Мин күршемне кызганып йокыга китә алмадым.

Тора-бара Галимҗан Сөмбеләне дә үзе белән эчәргә кыстый башлады, риза булмаса, кыйный иде. Шулай бер ун еллап вакыт узды. Мин авылдан шәһәргә күчеп киттем. Сөмбелә белән ара-тирә очрашкалап яшәдек. Аның йөзе шактый таушалган, үзе куллары белән авызын каплап йөри, күзләрен күтәрми, гел аяк башына карап сөйләшә. Без аның белән Галимҗан хакында бер дә сөйләшмәдек, ул җаны-тәне белән тартына, ояла иде.

Тагын ике-өч елдан, көзге салкын бер иртәдә бөтен авылны тетрәндергеч хәбәр таралды. Гәүдәсе кара янып беткән, башы ярылган Сөмбеләне үле килеш канаудан табып алганнар. Үләсе төндә урамнан узып баручы бер агай ишеткән аның иңрәп ыңгырашканын. Тик ишетеп тә янына бармаган. Исерек Галимҗан хатынын гадәттәгечә аракы эзләргә чыгарып җибәргән дә, кара төндә аракысыз кайтып кергәч, аны үтергәнче кыйнап, урамга куып чыгарган, капкасын дөбердәтеп бикләп куйган икән.

Иртән авыл «аһ!» итте. Озак еллар гөл кебек хатынын эчкечелек чоңгылына этәргән һәм соңыннан аны кыйнап салкынга куып чыгарган Галимҗан җәзасын алды дип беләсезме? Юк. Бөтен тәне кара янса да, патологоанатом Сөмбеләне туңып үлгән, дигән белешмә язып биргән. Дөрес, хатынының үлеменнән соң аны мәктәпкә якын да җибәрмәделәр. Әмма эш узган иде инде. Башын аска иеп кенә кибеткә барып кайта да, өнендәге аю кебек ята Галимҗан. Тагын ике-өч елдан үзе дә үлеп китте, пенсия яшенә җитә алмады. Үлеме Сөмбеләнеке кебегрәк булды — үзе кебек бер исерек иденендә тәгәрәп үлгән. Әллә үзе үлгән, әллә шешәдәшләре хәл иткәннәр, анысын тикшереп торучы булмады.

Истәлеккә яшьлектә төшкән фотолары гына калды. Һай, нинди матурлар, ничек пар килгәннәр! Яшьлекнең чишмә суыдай саф, чиста бер мизгелендә гомер юлларын башлап җибәргән шушы пар аккошның язмышы шундый фаҗигале бетәр дип кем уйлаган?!

Ә бит ул авылда исерек ирләр, исерек хатын-кызлар бихисап. Бер генә мәҗлес тә, бер генә бәйрәм дә аракысыз узмый. Корбан чалалар, корбан ашы уздыралар. Хәтта шул изге көннәрдә дә яшьрәкләр табынга аракы чыгарып куялар.

Галимҗан белән Сөмбелә фаҗигасе төрле гаиләләрдә төрле рәвешләрдә кабатлана тора. Гыйбрәтләр күп. Тик аракы эчүчеләр генә кимеми, бу коточкыч чир яшьләр хисабына һаман саен аза, зурая бара. Әмма афәтнең бөтен масштабын, бөтен тирәнлеген аңлаган, үлчәгән кеше бармы?

Татар авылларында аракы хәзер төнлә дә сатыла, самогон чишмә булып ага, көмешкә куучыларны эзәрлекләгән кеше дә юк хәзер. Печән китерү, салам ташу, утын кисү, мал чалу кебек эшләрнең берсе дә аракысыз башкарылмый. 70-80 яшьлек карчыклар, иманнарына хилафлык кылып булса да, пенсия акчаларына иң беренче итеп аракы алып куялар: булышкан өчен акча алыш юк, ирләргә аракы кирәк. Аракың булса, теләсә нинди проблемаң хәл ителә. Долларларың бер якта торсын. Гадәттә, куллары алтын кеше тора-бара эчкечегә әйләнә, чөнки эше өчен аңа хәмер белән түлиләр. Эчкән кеше гаиләсенә кайта, аракының бөтен авырлыгы балалар белән хатын-кыз җилкәсенә төшә.

Галимҗан белән Сөмбелә фаҗигасе һәр авылда бар. Ләкин ни өчендер без аңа «бу — һәр гаиләнең үз эше, аңа тыкшынырга кирәкми» дип карыйбыз. Безгә янгын чыккандагыдай чаң кагарга кирәк мондый чакларда, чаң! Бу — гаиләнең шәхси эше түгел, бу — дәүләт күләмендәге мөһим мәсьәлә. Ходай тарафыннан хатын-кызга бөек бурыч йөкләнгән: ул дөньяга Кеше бүләк итә, ул — Ана кеше. Карагыз әле безнең хатын-кызларга, җәмәгать. Алар авыр эш белән изелеп, исерек ирләреннән кагылып-сугылып, сүгенү сүзләренә күнеп, типкегә түнеп яшиләр.

Күпме хатын-кыз ирләре тарафыннан кыйналып гомер итә, инвалид булып кала! Сөмбеләләр яшәгән авылда бер ир хатынына сугып, аның күзен чыгарды, икенчесе кыйнап кабыргаларын сындырды. Тагын берсе сыер сауган җирендә хатынының башына лом белән сугып үтерде. Бу кешеләрнең берсенә дә җинаять эше кузгатылмады. Икенче бер авылда моннан егерме еллар элек тагын да тетрәндергечрәк хәл булды: исерек ата җиде айлык баласын ишек яңагына бәреп миләрен агызган иде.

Татар авылларына шуышып килеп кергән яшел елан үзенең җимергеч эшен дәвам итә. Аның үзеннән-үзе бетәчәге юк, безгә үз киләчәгебез, балаларыбыз, оныкларыбыз, киләчәк өчен көрәшергә кирәк.

Кайвакытта язгы чәчү, урак өсте, көзге эшләр чорында авылларда ирләр бер-ике атна «коры паек»та утыра. Хатыннары сөенеп туя алмый шул чагында, әти бүген ничек кайтыр икән, дип балалары да шомланып яшәми. Халык авыз иҗатына гына игътибар итегез: элекке гасырларда хәмерне харам дип яшәгән мөселманнар чыгарган табын җырлары, мәзәкләр ни турында сөйли? Урынсыз булса да, шуларның бер-икесен генә исегезгә төшерәм. Аның берсе совет чоры мәзәге, икенчесе — «җыру».

Дөрес бара. Укытучы балаларга: «Без бөек совет илендә яшибез. Иркен мәктәптә, якты классларда белем алабыз», — дип сөйли. Шунда бер бала аны бүлдерә.

— Әйе шул, апа, күгәрченнәр кебек яшибез... — ди.

— Бигрәк матур әйттең, Сәлим, әйт әле, күгәрченнәр кебек яшәүне ничек күз алдына китерәсең?

— Әти акча алган көнне әни тәрәзәдән, без форточкадан чыгып очабыз...

* * *

Аракыны кем чыгарган?
Алпавыт дигән явыз.
Шул явызны эчәр өчен
Менә, малай, миң сиңайтим,
Шапылдап тора авыз.

Ялгыз каен кайда үсә,
Үсә диләр күлләрдә...
Менә, малай, мин сиңайтим,
Аракыдан да кадерле
Нәрсә бар бу көннәрдә?!

Динен инде тотмасак та,
«Ураза»сын күп тоттык.
Менә, малай, мин сиңайтим,
Шөкер, Аллам, әл дә бездә
Аракыга юк кытлык.

Керләремне элеп куйдым
Алма бакчаларына.
Менә, малай, мин сиңайтим,
Карчыклар да эчә хәзер
Хәер акчаларына.

Карурманда зәңгәр чәчәк
Уралган каеннарга.
Менә, малай, мин сиңайтим,
Эчкече ир белән торып,
Уралдым кайгыларга.

Әдхәт Синугыл җыеп җибәргән шушы кара мәзәк күзләргә яшь китерә, йөрәкне өтеп ала.

Тиздән Татарстан хатын-кызларының III корылтае була. Анда нинди мәсьәләләр тикшерелер? Миңа калса, анда хатын-кызларны социаль яклау мәсьәләләре төп урын алып торырга тиештер. Әйе шул, Татарстан хөкүмәте эчкечелек проблемаларын да искә алып, ниндидер карар кабул итәргә, аракыга бюджетка иң күп керем кертүче буларак кына карамыйча, менә шушы күзлектән чыгып та үз мөнәсәбәтен белдерергә тиеш. Юкса, бу татар халкына карата җинаятьчел сәясәт, һәм аңа күптән чик куелырга тиеш инде.

Күптән түгел «Аргументы и факты» гәзитендә җан өшеткеч бер мәкалә басылды. «Әгәр иремне үтерсәм, мине төрмәгә утыртырлармы?» — дип сорый газаплары чиктән ашкан бер хатын. Эчүче ирләре белән якты дөньяда ук тәмуг газапларын кичергән миллионлаган хатыннарның җан авазы бу.

Кем ишетер? Кем?!

Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА,
махсус хәбәрчебез.

Сәхнә биеклегендә калу

Лена ШАГЫЙРЬҖАН

Халкыбызның җыр

Алтмышынчы еллар ахыры. Хәзерге шикелле, һәр сарайда, һәр мәйданда татар җыры, татар моңы, татар сүзе шау-гөр килеп, яңгырап тормый... Җаннар милли сүзгә, милли моңга, милли тавышка, милли иреккә сусаган. Мәктәпләрдә туган телгә кадер беткән чаклар иде. Татар теле, татар әдәбияты укытучыларын санга да сукмыйлар шикелле... Йөрәк әрни, тын бетә. Әллә ниләрнең астын өскә китерү, үзгәртү теләге уяна. Һич югында (яшьлек бит!), милли киемнәребез — читек, калфак, куш итәкле озын күлмәк киеп, бер үзәк урамнан үтеп китәсе килә!.. Һай, исләре китсен иде... Хыялымда гел шул булды, студент чактан бирле.

Менә шул елларда язмышым мине — яшь мөгаллимә кызны — мәктәп юлларыннан бөтереп алды да, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә китереп кертте. Шунда инде мин тәүге тапкыр башыма чын милли калфак, өстемә чын милли күлмәк, аягыма чып-чын чигүле читекләр кидем. Сәхнәдә генә булса да... Ә милли моңнарыбыз турында әйтеп тә торасы юк...

Иа, Ходаем! Әнием миңа мәктәптә укыганда, сәхнәдә биер, җырлар өчен, марля яки ситсыдан шундыйрак күлмәкләр тегеп бирә иде. Калфагын да ялтыравык чәй кәгазе белән бизәп, катыргыдан үзебез ясаган була идек. И, Әнием!.. «Бабайларда чын энҗе, чуклы калфаклар кечкенә бер сандык тулы иде», — дип сөйләгәне хәтердә... Бабалары бай сәүдәгәр булган... Без күргәне — истәлеккә дигән бер ефәк затлы шәле генә калган иде алардан әниебезнең... Алкаларын тактырмаганнар, йөзек-беләзекләрен кидермәгәннәр — сатылып беткән...

... Яшь йөрәктә менә шундый хисләр, кичерешләр кайнап торган шул елларда милли сәнгатебезнең йөзек кашы булып саналган җыр һәм бию ансамбле миңа ниндидер бер серле яшел утрау яисә кырыс чүлдәге яшел бер оазис булып күренде... Ул чактагы танылган җырчылар, биючеләр белән дә бергә эшләргә туры килде. Ансамбльдә җырлап, пенсиягә чыккан яисә аерым бригадаларга таралган артистлар турында безгә үзе кызыклы, үзе гыйбрәтле истәлекләр сөйлиләр иде. Ә без әлеге җырчыларның тавышын радиодан тыңлап үскән... Артистлар тормышы серле дә, кызыклы да, авыр да. Гастрольләр исә — үзе бер бәйрәм, үзе зур газап. Ярты гомер юлда уза, яшәү шартлары походтагыча. Күңелгә бер-бер артлы төрле истәлекләр уела бара...

... Әгәр мин оста рәссам булсам, үзем яраткан һәрбер сәнгать остасының портретларын язар идем. Иң ачык, иң якты буяулар белән... Ләкин мин — шагыйрь. Ә нигә — сүз белән дә портретлар язарга була бит! Дөрес, элегрәк андый әсәрләрне «альбом шигырьләре» дип кимсетәләр иде. Ә бит Тукаебыз иҗатында шигъри портретлар гаять күп. Пушкинда да... Димәк, мөмкин! Ихтимал, мондый тыю-чикләүләр теге яки бу шәхесне томалау, үзенчәлекле йөзен күрсәтмәү өчен махсус уйлап чыгарылган булгандыр. Янәсе, халык — тоташ масса, аерым шәхесне үсендерәсе юк...

Күз алдына китерегез әле: менә без Милли мәдәният музеенда йөрибез, ди. Акрын гына «Әллүки», «Тәфтиләү», «Зиләйлүк»ләр агыла... Диварларда халык күңелендә эз калдырган әдәбият һәм сәнгать әһелләренең оста рәссамнар тарафыннан язылган гүзәл портретлары... Һәр йолдызның үз урыны... Һәрбер сурәт астында күренекле шагыйрьләребез иҗат иткән шигъри портретлар — багышламалар... Монда бит бөтен сәнгать төрләре үзара берләшә ала! Мин мондый музейга атна саен килер идем. Никадәр энергия, никадәр илһам алыр идек без!..

Күптән түгел Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле бик тә игелекле бер эш башкарды: халыкка үзенең элекке сәхнә осталары катнашында гүзәл концертлар күрсәтте. «Йолдызлар сүнми» дип аталган бу тамашада безне сагындырып өлгергән өлкән артистларыбыз катнашты. Күренекле сәнгать эшлеклесе Лима ханым Кустабаева тамашаның сценариен язганда, һәрбер артистның иң үзенчәлекле җырларын һәм, димәк, чын асылын күрсәтергә тырышты. Әле миңа да эш тапты: «Әйдә, Лена, һәрбер артистыбызга шигъри портрет яз», — дип үтенде. Рәхмәт аңа! Мин, әлбәттә, рәхәтләнеп риза булдым... Бүген менә хөрмәтле газета укучыларыбызга шуларның кайберләрен тәкъдим итәм.



Лима ханым Кустабаевага

Ансамбль ул — халкыбызның
Җыр һәм бию бакчасы.
Шул бакчаның шифасыннан
Сихәт таба барчасы.

Яшәргәннән-яшәрә бу
Милли гөлләр бакчасы.
Лима ханым шул бакчада —
Гүя, мәшһүр бакчачы.

Шунда үтте ничә кышы,
Язы, җәе, көзе дә.
Шул бакчада Лима ханым
Чәчәк атты үзе дә...

Күпме еллар, армый-талмый,
Гүзәл гөлләр үстерә.
Шуңа аны халкыбыз да
Якын итә, үз күрә.

Ул бакчаның чәчәкләре
Сибеләдер җилләргә,
Таратып Татарстанның
Дәнын ерак илләргә...

Җыр-бакчага керәбез без
Арган-талган чакларда.
Ул безне саклый, безгә дә
Кирәк аны сакларга...

Җыр һәм бию бакчасы ул —
Безнең йөзек кашыбыз.
Сокланып карыйбыз аны,
Яратып — һәркайсыбыз.

Җыр һәм бию бакчасына
Җыелышып килегез...
Күкрәп, яшьнәп чәчәк атсын
Телебез һәм илебез!

Разия ханым Тимерхановага

Исә җилләр, өзелә үзәк,
Сибелә чәчәк, «Сибелә чәчәк»...
Данлы «Казан сөлгесе»нә
Чигелә чәчәк, чигелә чәчәк...

Әй, гармунчым, гармуныңның
Төймәләре ничә рәтле?
Сыздыр әле, Разия апа
Җырлый торган «Сүнмәс дәрт»нә!..

Үтсен өле тамырларга
Сагыш-моңнар, кайнар хисләр.
Искә төшсен яшьлектәге
Алсу таңнар, зәңгәр кичләр...

Килеп чыксын офыклардан
Зәңгәр күзле моңлы бер кыз...
Балкып китсен күңел күге,
Калыккандай якты йолдыз!..

Галия ханым Гафиятуллинага

«Һай, бормалы, бормалы ла»,
Моңлы гомер юллары...
Галия апа җырлаганда,
Чыңлый күңел кыллары.

Көмеш чишмә челтерәвен
Хәтерләтә тавышы.
Агымсулар агышыдай,
Баса йөрәк сагышын.

Сыгылып-сыгылып сагына аны
«Актаныш басмалары».
Язмыш буйлап җилфердәгән
Озын юл тасмалары...

Һәр җырыннан аның дуслар
Моң ләззәтен татырлар.
Күз алдына килә тезелеп,
Даладагы «Чатырлар»...

Зур бәхетләр — милләт белән
Җыр телендә сөйләшү.
Соңгы тамчысына кадәр
Халкыңа моң өләшү...

Зәйтүнә ханым Әхтәмовага

... «Эңгер-меңгер...»
Йомшак талгын моң —
Төшләрендә бодрә талыңның...

Тавышында — бәллүр сафлыгы,
Назакәте сылу ханымның...

Тесле сүзләр эзлим язарга:
Каләм белән рәсем ясарга...

Җәй сурәте — баллы кәрәздә,
Кыш сурәте — бәсле тәрәздә...

Энҗе-мәрҗәненә тиң безнең
Милли моңнар — тирән диңгезнең.

Зәйтүнәкәй, кая йөзәсең,
Шул моң дәрьясынмы гизәсең?..

Чакыра мәллә «Акчарлаклар»ың?
Сагындыра нинди чакларың?!.

Яшьлегеңә кайтып килдеңме,
«Зөлхиҗә»нең хәлен белдеңме?..

Сагына булыр икегезне дә
Яшь гомернең яшел сукмагы.

Бәхетле ул — үзенең җырын тапкан,
Халык җырын чөнки җуймаган!..

Сөләйман абый Йосыповка

«Урап-урап карлар» явып үткән,
«Юллар-юллар» көртке күмелгән...
Җырчы күңелендә ни-зар барын
Кем тыңлаган — бары шул белгән.

Тавышы кор аның — Сөләйманның,
Чын ирләрчә — калын тавышлы...
Ник соң үзе — яз башында шыткан
«Умырзая» кебек сагышлы?..

Һәрбер гөлнең була үз вакыты...
Кышын чәчәк аткан гөл дә бар.
Үксеп торган җырлар күп татарда,
Көлеп торганын да ул табар!..

Кышлар үтәр, кабат язлар килер,
Сагындыра шулай да...

Көчле тавыш, мәгърур буй-сын
Буйсындыра үзенә...
Чулман Суның зәңгәрлеге
Иңеп калган күзенә...

Әллә ул төс — күк чәчәкле
Арышлы кырларданмы?
Әллә үзе эзләп тапкан
Сагышлы җырларданмы?..

Онытылган көйләр шулай
Бер яңара, күрәсең...
Ишеткән саен, ис китә,
Һай, моңлы бу кәрешен!..

Фәйтүнә ханым Абдуллинага

Әллә көләч күбәләк ул,
Әллә җитез бал корты?
Фәйтүнә ул — очып бии,
Сәхнәләрне балкытып...

Үзен дә, бал күк, йотарлык
Кашыкка салып кына...
Шулай уйныйдыр суларда
Көмеш ак балык кына...

Аккош кебек йөзеп китә,
Бөтерчек күк өйләнә.
Карлыгачка әверелә,
Ак каенга әйләнә...

Анда китереп баса да,
Монда китереп баса...
Мәңге биеп торыр иде,
Читекләре тузмаса...

Сәхнәләрне гене түгел,
Күп илләрне гизде ул.
Сылу татар кызларының
Биюе дә изге ул!

Мансур абый Гатиятуллинга

Тиңнәр юк — бию дигәндә,
Татар егетләренә!
Тиңләү мөмкин аларны тик
Кыя бөркетләренә...

Тыпыр-тыпыр биергә дә
Имән иденнәр кирәк...
Биюче Мансур абый күк
Менә дигәннәр кирәк!

Бөтерелеп китсә биеп,
Җитез чалгычы егет,
Яшәреп китә сәхнәләр,
Ямь-яшел болын кебек.

«Мәдрәсә» биюе белән
Калды тарихка кереп.
Гыйбрәт алды тамашачы,
Күз яше аша көлеп...

Бик күп шәкертләре аннан
Өйрәнде осталыкка...
Мәйданнарның киңе кирәк
Бии белгән халыкка!..

һәм бию бакчасы

Зилзиләләр купты, давыллар —
Бәдрә тал»ны яшен сукмады!

Җыр саклады аны, ышыклап,
Җыр күңеле һаман изге ле...
... Энҗе калфак кигән сурәтең
Чагылып китте хәтер-көзгедә...

Габдулла абый Рәхимкуловка

Даны шулай күптән еракларда...
Казаннан ул — Татар иленнән.
Төгәлрәк итеп әйтсәк, әгәр —
Җыр һәм бию ансамбленнән...

Ул — Габдулла Рәхимкулов булыр!
Туган авылы — гүзәл Шәйморза.
Җыр-суына гашыйк кеше гене
Гомер буе шулай җыр суза.

Тавышына аның калган сеңеп
Сайрап торган тальян чыңнары.
Рәхәтләнеп җырлый — чын татарча,
Дөнья гизә татар моңнары...

Чылбырдай тезелеп еллар үткән,
Торналарга җырлар ияргән.
Яз нуры да агыла, көз нуры да
Ул җырлаган моңлы көйләрдән.

Дәрт сүнәрме җырчы йөрәгендә, —
Дуслар әле тыңлап туймаган...
«Буразналар» кабат яшәрер...
Күңелгә бер кереп калган җырлар
Онытылмас, мәңге яшәр ул!

Габделхак абый Шаһиевка

Иң беренче чиратта
Әйтик әле шул хакта:
Моң да, дәрт тә, хис тә, көч тә
Җитәрлек Габделхакта...

Чәчәкләрне уятты ул
«Кыңгыраулар»ы белән.
Тавышының тигез гене
Яңгыраулары белән...

Тибрәтте аннан күңелне
Шигърият канатында:
Җыр көенә җилкендерде
Тукайның «Пар ат»ын да...

Ә «Рәйхан»ы рәхәт бирде —
Моңлы җырдан кем туйган?
Моң шул җанны сафландырган,
Моң ул — бәгырьне уйган...

Рәйсә ханым Тимофеевага

«Аллар үсә, гөлләр үсә
Идел буе тугайда»...
Җырчылар бар... Рәйсә апа

Татарстан Мәдәният министрлыгы
Халыклар дуслыгы орденлы
Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле

1995 ел, 12 декабрь

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия
опера һәм балет театры бинасында
Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленең
сәнгать җитәкчесе, Татарстанның һәм Русиянең
атказанган сәнгать эшлеклесе

Лима КУСТАБАЕВАның
иҗат эшчәнлегенә 30 ел
тулуга багышланган

КИЧӘ БУЛА.

18 сәгатьтә башлана.

Камил САТТАРОВ:

«Мин укучыларым белән бәхетле»

— Бәхет, язмыш, үткән юлдагы сөенеч-көенечләр, кояшлы, нурлы мизгелләр турындагы сорауны, гадәттә, соңыннан бирәләр 60 ел гомер узган да киткән. Әйтегез әле, Сез бәхетлеме?

— Әйе Мин укучыларым киләчәккә дәвамым йөзек кашына өйләнгән кешеләрем сәхнә йолдызларым булу белән бәхетле Татарстанның халык артисты Горький премиясе лауреаты Алсу Гайнуллина Татарстанның атказанган артистлары Әсхәт Хисмәтов. Хафиз Хамматуллин. Ләлә Миңнуллина — минем укучыларым. безнең театрдан олы иҗат юлына чыккан сәләтле артистлар Алар Г Камал. К Тинчурин. Минзәлә театрларында эшлиләр һәм спектакльләрдә каһарманнарны уйныйлар

Эшеңне дәвам иттерүчеләр күп булу яшәү мәгънәсен тирәнәйтә. Димәк, синнән соң да эшең кала, аны әйдәп баручылар була Казан театр училищесын 15 укучы тәмамлады дүртесе үзем белән эшли. Кырыклабы мәдәният институтында белем алды Хәзер үзләре режиссерлар Алабуга мәдәният училищесында да минем дәвамчыларым эшли

Кызым Резидә дә минем юлны сайлады Консерватория каршындагы мәктәптә укыды, консерватория тәмамлады аспирантурада белем алды

Тазалык-саулык та бәхет. Шөкер бу яктан да зарланмыйм. Елмаеп йөрү дә бәхет. Тормыш-яшәешне күпме генә авыр дисәләр дә, ул кайгы-хәсрәткә бирелерлек дәрәҗәдә түгел Бары тик һәр туган көннең кадерен, яшәүне максатчан итә белергә кирәк.

Безнең халык иң авыр сугыш елларында да михнәтләргә бирешмәде сынмады. Язлар җитеп, елга буйларында кар сулары китү белән яшьләр гармун алып, уенга чыга иде Биеп-җырлап, алар яшәү дәртен арттырды. Әтием-әнием туган-үскән Әтнә ягы әнә шулай җырга, биюгә маһирлыгы белән күңелгә кергән

Акыллы, зирәк укытучыларым, остазларым белән дә бәхетле мин Роальд Сәгъдиевнең әнисе Сәҗидә апа мине ана теленнән укытты I съезд делегаты. Крупскаяны күргән Бөнат Сабитова да белем бирде миңа Бишенче сыйныфта укыганда ук сәхнәгә аяк бастым Артистка Асия Хәйруллина безнең мәктәпкә килеп, уенга малайлар сайлады мине дә алды Менә шуннан минем сәхнә тормышым башланды дип саныйм

— Сез укытучыларыгызны олылап телгә алдыгыз, ә үзегез кайда укыдыгыз соң?

— Без гаиләдә ун бала үстек. Ул елларда татар баласына кайсы мәктәпкә барасы дип баш ватасы юк иде Син татар икәнсең, татар мәктәбенә барасың Мин дә барлык туганнарым кебек К.Маркс урамындагы 18 нче мәктәптә укыдым Туган телемдә белем алу зур мөмкинлекләр ачты, сигезебез югары белем алды.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң Ташкентта эчке эшләр министрлыгы училищесында укыдым Казан университетының тарих факультетын тәмамладым Ленинградта режиссерлык факультетында белем алдым Дөрес, мин үзләштергән кайбер һөнәрләр тора-бара җәмгыятькә кирәкмәскә әйләнде Ташкентта училище тәмамлагач, Казан егете булгангамы, эшкә мине Татарстанга чакыртып алдылар Әмма бу һөнәрне (балалар колониясендә эшләүне) юкка чыгардылар. кыскарттылар. Эшсез калгач, слесарь өйрәнчеге булырга бер ай чират тордым, әмма анда белемле кеше кирәк, диделәр. Һәм 5 нче һөнәр училищесына укырга барырга мәҗбүр булдым Ел ярым гомер шунда узды.

— Сезгә үз гомерегездә мәшһүр иҗат кешеләре белән очрашырга туры килдеме?

— Салих Сәйдәшевне мин балачактан күреп, белеп үстем. Чөнки ул безгә килеп йөри иде. Касыйм Мөхәммәтҗанов, Дилүс Ильясов, Касыйм Шамил, Кәрим Мурзаханов минем остазларым иде Рәшидә Җиһаншина, Һидият Солтанов үзешчән сәнгать, халык театрына ихлас күңелдән карадылар, аралаштылар, үзләренә алмашка артистларны безнең коллективтан таптылар Алсу Гайнуллина белән дә нәкъ шулай килеп чыкты Ул «Кияүләр» спектаклендә Айсылу ролен уйнады. 9 нчы сыйныф укучысының осталыгы шунда ук үрнәк иде. Спектакльне карагач. Рәшидә апа белән Һидият абый аны театр училищесына укырга керергә өндәделәр Бу эшкә кызның гаиләсе дә, хәтта үзе дә каршы иде Алсуны бергәләп үгетләдек, күндердек. Театр училищесының икенче курсына кабул иттеләр үзен. Уртак тырышлык кызны сәхнә йолдызы итте.

Артистлар Гөлсем Болгарская, Фатыйма Ильская, язучылар Ибраһим Нуруллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Нәкый Исәнбәт, Мирсәй Әмир һ.б иҗат кешеләре белән тыгыз элемтәдә тордым. аралаштым, әсәрләрен сәхнәләштердем.

— Сез Урицкий, Төзүчеләр мәдәният йортларында халык театрын әйдәп барган режиссер. Шул хакта сөйләгез әле.

— И, театр дигәндә, һәммә нәрсәгә дә әзер мин. Чөнки гомер буе театр, сәхнә тормышы белән яшәдем. Мирсәй Әмирнең 18 ел сәхнәгә куелмаган «Тормыш җыры»н 70 кешелек коллектив, оркестр белән сәхнәгә куеп, уйнап, тамашачыны таң калдырган идек. Мирсәй ага халык театрына олы рәхмәтләрен җиткерде. Автордан

җылы сүз ишетү, ә тамашачыны әсәр белән канатландыру — артист тормышында иң кадерле мизгел инде.

Безнең халык театры бөтенсоюз фестивальләре лауреаты булды. Театрда үзешчәннәр тарафыннан бик күп әсәрләр куелды. Шәриф Хөсәеновның «Чулпан» драмасы, Юныс Әминовның «Тамырлар» комедиясе, Чыңгыз Айтматовның «Талчыбыктай гүзәлем» лирик драмасы, К.Шангытбаев һәм К Бәйсәитовның «Кияүләр» музыкаль комедиясе, Нәкый Исәнбәтнең «Рәйхан» музыкаль драмасы, Туфан Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» драмасы һәм башка бик күп әсәрләр уйналды Тамашачы аларга югары бәя бирде 50 ел эчендә Урицкий исемендәге мәдәният йортының халык театрында 34 әсәр куелды.

Чиратта 35нчесе әзерләнә. Без бу юлы тамашачылар өчен яңа драматург ачарга телибез һәм аның пьесасын алар үз итәр дип өметләнәбез

Режиссер буларак, мине үзешчән артистларның бирелгәнлеге, сәхнәгә тугрылыгы, матурлыкка омтылышы сокландыра Алар театр өчен барлык авырлыкларны кичәргә әзерләр.

Урицкий клубына 1957 елдан бирле йөрим. Чынлап та ике халык театрына нигез салынды — Урицкий һәм Төзүчеләр мәдәният йортларында. Үзешчәннәр сәнгатен күрсәтергә чит илләргә бардык, Германиядә, Чехословакиядә. Болгариядә, Швециядә гастрольләрдә булдык.

— Сез Мәдәният министрлыгының фәнни-методик үзәгендә баш режиссер да, бүлек мөдире дә бит әле...

— Әйе, татар халкының бай мирасы, бүгенге иҗаты саклансын, киләчәге өметле булсын өчен, Татарстанда да, аннан читтә дә җиң сызганып эшләргә туры килә. Татарлар яшәгән өлкәләрне, республикаларны аркылыга-буйга узарга туры килде, гомумән, татар кайда, мин шунда булдым. Шунысы сөенечле, татар үзен саклап калган, аның тамашачысы бар. Мәсәлән, Ташкентның үзендә генә дә биш иҗат коллективы эшләп килә.

Күптән түгел Яңа Чишмәдән отчет концертыннан кайттым. Анда булачак сәхнә йолдызларына юлыктым. Ләйсән Хисаметдинова, Марат Фәйрушин, Илнар Шәйхетдинов әнә шундый кабынып килүче йолдызлар Тик аларның ышанычлы кулларга эләгүе, дөрес юлдан китүе шарт. Киләчәктә аларны зур сәхнәләрдә күрергә насыйп итсен.

Әңгәмәне
Сәрмәдия СӨЛӘЙМАН үткәрде.

● **Камил Саттаров (уртада) Г.Зәйнашеваның «Кем гүзәл?» әсәрендә.**

Адәмне исем түгел, җисем бизи

Болгавыр матди яктан кысынкы, җан тынычлыгы югалган заманда яшәсә дә. халкыбыз үзендә рух бөтенлеге күңел күтәренкелеге тоеп яшәргә тырыша Безнең хәлне аңлагандай, радиодан да телевидениедән дә. концерт залларында да өлкәннәргә алмашка килүче яшь буын артист җырчылар халыкның күңеленә хуш килердәй яңа җырлары белән куандырып торалар Тамашачы җырчылар арасында яңа тавыш, яңа исем ишетсә, икеләтә сөенә

Башкалабызның зур концерт залларында баручы «Сандугач» фестиваленең афиша-игъланнары белән танышам Исемнәр, фамилияләр Танышлары да таныш түгелләре дә бар. Араларында Кайбицкая да бар!

Кайбицкая — 30 нчы. 50 нче еллар арасында җыр сәнгатендә халыкның чиксез мәхәббәтен яулаган драматик спектакльләрдә дөнья классикаларының операларында төп партияләрне уйнаган зур талант иясе иде Ул — Мәскәүдә бик яхшы билгеләренә генә консерватория тәмамлаганнан соң Татар опера һәм балет театрын оештырып җибәрүдә катнашкан, аның беренче нигез ташларын салышкан карлыгач. Г Кайбицкая — «Алтынчәч» образын беренчеләрдән булып иҗат итүче Татарстанның халык артисткасы Галия Мотыйгуллинаның сәхнә кушаматы Ә бүгенге афишалардагы Кайбицкая кем соң? Баксаң ул да Кайбыч ягыннан, ди Ике җырчының бер кушамат белән йөрүе җыр-музыка сөюче тамашачыларны гына аптырашта калдырмыйча, хәтта сәнгать өһелләре арасында да гаҗәпләнү тудырды. Хәйран дәрәҗәле артистлар да. «Кем бу яңа Кайбицкая. данлыклы Кайбицкаяның оныгымы әллә?» — дип бер-берсеннән сораша башлады

Мин — өлкән буын кешесе Миңа Галия Кайбицкаяны эстрада җырчысы буларак та, классик операларда төп партияләрдә, татар драматургларының драма әсәрләрендә баш рольләрдә уйнаган чагында да күрергә насыйп булды Үзенең табигый гүзәллеге өстенә Ходай аңа җырчы тавышын да мулдан биргән һәм ул образга шулкадәр кереп уйный иде ки, хәтта тәнәфес арасында еш кына аның йөзендәге гримын төзәтеп чыгаралар иде. Кыскасы ул катнашкан кечә-спектакльләр кешегә бәйрәм халәте бирә иде.

... XX гасыр башларында татар артистлары арасында үзенең шәхси фамилиясеннән тыш яңгыравыклы, җиңел бигрәк тә «ский», «ская»га тәмамланган фамилия-псевдонимнар белән мавыгу күренә башлады Шулай итеп Шамильский. Иманский. Казанский, Ашказарский, Волжская, Уральская, Камская. Болгарскаялар пәйда булды Фатыйма Хуҗасәитовага да, фамилияң афиша өчен отышлы түгел, дип, Ильская булырга тәкъдим итәләр Мин моны хәзер югарыда утырган чит миллəт җитәкчеләре тарафыннан татарны татарлыгыннан читләштерү өчен эшләнгән бер ялган уйдырма дип бәялим Шөкер, «ский», «ская»лар белән мавыгу чоры үтте, хәзер берниндн артист та язучы-шагыйрь дә үзенең татар фамилиясеннән читләшми Безнең миллəттә хәзер халык мәхәббәтен яулаган шагыйрь-композиторларыбыз Чуганаевлар. Чурагуловлар бар Җырлап җибәрсә. зур концерт залларын алкышларга күмдерә торган Татарстанның халык артисткасы Хәмдүнә Тимергалиева да үзенең чын татар исем-фамилиясен горурланып әйтә торгандыр

Яңадан-яңа үрләр яулый-яулый дөнья сәхнәсенә чыккан, хәзерге көндә Лондонның король химаясендәге театр сәхнәсендә биюче Ирек Мөхәммәдев тә. ниһаять, дөнья күләмендә «бию алласы» булып танылган мәрхүм Рудольф Нуриев та саф татар фамилияле безнең миллəт кешеләре. Димәк, исемеңне хезмәтең белән бизәргә кирәк. Ә бездә әле «тәрәзә төбем исле гөл...» дип ике җыр җырлап сәхнәгә менәләр дә. халыкның мәхәббәтен казанырга азапланалар Киләчәктә Кайбыч төбәгеннән чыгып үзен җырчыга исәпләгән һәрбер кеше Кайбицкая кушаматын дәгъвалый башласа, тора-бара аларның саны төрле чорларда патшалык иткән француз корольлегe Людовиклар төсле 18 (!) гә җитмәсме? Нигә шундый буталчыклык кертергә? Ә Кайбыч төбәген Галия Кайбицкая күптән мәңгеләштердe инде.

Сәнгать кешеләренең шәхси тормышы да халык игътибарыннан читтә кала алмый Галия Кайбицкая бу яктан да бик күпләргә үрнәк булды Ул ике улын академик, кызын табиб итеп гәрбиялəп олы тормыш юлына чыгарды, никадәр оныклар, оныкларының балаларын үстердe Әйе, сәләтле кешеләр күп, ә талантлы кешеләр аз. Ә Татарстанның халык артисткасы Галия Кайбицкая яхшы әни, әйбәт дәү әни һәм чын мәгънәсендә талантлы артистка иде Шулай булгач, үзеңне шундый олы шәхес белән янәшә куярга азапланy кирәкме икән?! Сөйләүләренә караганда, Кайбыч төбәгендә Бәрле елгасы бар, диләр. Теләгән кеше Бәрлинская булып яңа кушамат алсын үзенә Матур бит

Һаҗәр ЗАРИПОВА.
Казан.

Укы да уйла

Алтын казып баеп буламы?

(Ахыры. Башы 6 нчы битте).

— Сәяси тоткыннар турында җирле халык сөйли идеме?

— Хатыннах дигән алтын ятмалары янында концлагерь булган. Выгон исемле яһүд кешесе сөйли: «Һәр көнне төнлә белән приискада булган барлык тракторлар, бульдозерларны кабызып, бар көчләренә үкертеп эшләтә башлыйлар икән. Шулвакыт бичара тоткыннарны алып чыгып автомат, пулеметлар белән кырып салалар икән. Ирекле алтын юучылар ату тавышларын ишетмәсен өчен шулай эшлиләр». Шул лагерьдан нибары дүрт кеше исән кала, исән калучыларның берсе — Выгон. Соңра ул шул приисканың директоры булып эшли башлаган. «Мин дә бер тапкыр шулай тайгага киттем. Без яши торган пүчинкәнең таулар ягына сузылган сукмагыннан йөрергә ярамый иде. Анда бүрәнә куелган. Ни өчен анда барырга ярамый? Берәү дә әйтми. Ярамый, бетте-китте. Заманасында ул якта сакчылар да кизү торган. Кешеләрне ул якка җибәрмәгән. Махсус полк киткән иде инде, тыючы юк. Киттем сопкалар-таулар ягына. Барам-барам, сопкаларга карыйм. Җәй уртасында тау араларында кар була, ләкин тау битендә кар юк. Эреп бетә. Әмма сопка итәгендә нидер ялтырый. Кар ятмасына охшаган. Ләкин андый ачык, кояшка каршы ясылыкта җәй уртасында кар булалмый. Барып җитсәм, һуштан китеп, егыла яздым. Кеше сөякләре. Башлары тишек, кабыргалары ядрәләр белән теткәләнеп беткән. Рәт-рәт булып, тезелеп алып баргандагы кебек, кеше сөлдәләре ята. Бу урында 1938 елда бер мең алты йөз кешене берьюлы атканнар, селкенергә дә өлгермәгәннәр мәрхүмкәйләр, өелешеп шунда ауганнар... Кан өши моны күргәч, ничәмә-ничә еллар дәфен ителмәстән кояш астында ауныйлар... Соңра ашыгыч рәвештә сөякләрне бульдозерлар белән күмдереп куйдылар», — дип сөйли иде Сокольский. Ул комсомол юлламасы белән 1946 елда Колымага килгән булган... Сопкаларга юлны тоткыннардан салдыралар. Тар гына юл. Бер кырда төпсез упкын — Колыма елгасы. Икенче кырда кыядан киселгән дивар. Төрмәдәге ике дошман төркемне шушы тар юлда кара-каршы очраштыралар. Бер якта утыз сигез кеше, икенчесендә утыз бишәү була. Бер-берсен үтереп, упкынга төртеп төшереп, җәмгысе җиде кеше исән кала бу сугыштан соң. Бу — Бериянең, җинаятьчеләрне җинаятьчеләр кулы белән бетерергә кирәк, дигән өндәвеннән соң була.

— Күпме эшче кул һәлак булган. Алтынны бушлай чыгара торган шундый күп эшче көчне нигә юкка чыгарганнардыр, аптыраш?

— Кышын да эшләп, тоткыннар ике-өч елдан сафтан чыга. Туберкулез башлана, аяк-куллар өшеп, чери башлый, йөрәкләр түзми, кеше чынлыкта эшли алмас гарипкә әверелә. Боларын атып, яңа, таза тоткыннар партиясен кабул итү өчен урын бушату, дип уйлыйм мин. Шул мәхшәрләрне үз күзләре белән күреп тә, исән калган берәү сөйли иде. Аңа шул төрмә табибы әйткән. Өшеп төшкән кул-аяк тырнакларын без һәр көн олы-олы тазлар белән чыгарып түгә идек, дигән. Илле градустан да салкынрак шартларда, чынлыкта ялан кул алтын юу, агач тураунын ни икәнен чамаларга була.

— Сез анда ничек яшәдегез, торак шартлары ничегрәк иде?

— Башта чатырларда, бушаган казармаларда, авыл сымак пүчинкәдә яшәдек. Анда элек үк килгән каторжаннарның балалары йорт салып, яшәп ята иде. Без Дебин дигән пүчинкәдә тордык. Дебинга килгәч, без шаккаттык, тайга уртасында зур гына авыл. Бик шәп йортлар белән рәттән такта-токтадан корылган алачыкларда да кеше яши. Пүчинкә уртасында менә дигән ресторан эшли. Яшәү шартлары начар, ә халык яхшы киенгән. Элек монда махсус Колыма полкы булган, җәза өтрәтләре. Алардан бушаган казарманы хастаханә иткәннәр.

— Җирле халык очрый идеме?

— Юк!.. Бары тик әнә шул хастаханәдә туберкулез белән авыручы берничә коряк, бераз чукча кешесе бар иде.

— Кешеләр тайгада нинди могамәләдә? Тайга тулы җыен өтрәк-өләмме?

— Җинаятьчеләр бар, әмма ирекле халыкның үзара ярдәмчеллеге мине бүген дә гаҗәпләндерә. Урамда очраган таныш түгел кешедән син бурычка шактый зур суммада акча сорый аласың. Ул сиңа сынап карый, йөзеңә, күзеңә ышанса — бирә. Алдашу юк. Вакытында кайтарасың. Йомышыңны йомышларга диеп, юлда машинаңны туктатып торсаң, икенче бер шофер туктап, ярдәм кирәк түгелме, туган, димәенчә узып китми. Закон — тайга!

— Син, Зиннәт дус, бу эшнең пионеры идеңме, әллә инде әзергә-бәзер бардыңмы?

— Мин үземне бу эшне башлаучы, дип әйтә алмыйм. Әмма Колымадагы беренче чатырларны без кордык. 1912 елда Ленадагы атулардан соң ике татар кешесе, Бари абзый белән Сафи Шәфигуллин тайгага кача. Дөрес, алар урыс сәүдәгәрләренә каюр булып яллана.

— «Каюр»ы нәрсә инде тагы?

— Этләрне мичәүләп чанага җигеп йөрүче кешеләр каюр дип атала. Бари белән Сафи тегеләргә тире-яры җыеша, якутча белгәнгә күрә, бу татарлар урыслар өчен бик файдалы эшләр башкара. Шулай йөргәндә Бари абзый дустына бу тирәләрдә алтын эзләргә кирәклеге турында әйтә. Болар тире җыюны ташлап, тайганың кеше аягы басмаган җиренә китә. Магадан ягында Ола дигән пүчинкә бар. Анда коряклар, чукчалар яши. Бу ике абзый Оладан Среднякан ягына бара. Тайга эчендә ерак кергәч, алып килгән ризыкларының бер өлешен туңга күмеп, икенче өлешен агачларга асып куялар. Бари абзый өлеге урынны дөрес сайлый. Монда иң өстә ята торган, иң сыйфатлы алтын ятмалары була. Дүрт метрдан алтын катламы башлана. Шунда болар алтын казый башлыйлар. Шактый алтын туплыйлар. Ләкин берзаман ризыксыз калалар. Әллә селәүсең, әллә аю аларның ризык базын актарып ашап китә. Агач башындагыларын да кош-корт юкка чыгара. Алтынчылар ачыга башлый. Бари абзый юлдашы Сафига алтын биреп, кирегә, пүчинкәгә кайтырга да, алтынны сатып, азык, дары, кирәк-ярак сатып алып, боланнарга төяп килергә куша. Сафи ялгызы кайтып китә. Ялгыз кеше тайгада төнне ничек үткәрә? Нодья белән җылына кеше.

— Нәрсә ул «нодья»?

— Юан агачны егып, балта белән ялгаш ясыйсың. Шул ялгашка учак ягасың, ут агач үзәгеннән янып барып, көүсәне җылыта. Кеше әнә шул эче өкрен генә янган агач белән янәшә ятып йоклый, әнә шул «нодья ягу» дип атала... Атна буе кайта торгач Сафи абзыйның, бәлки, чакмасы беткәндер, җылысыз калгандыр. Ул бик каты салкын тигезеп, ялгызы гына нодья янында авырып ята. Аны аңсыз килеш, үлем хәлендә якутлар табып ала һәм чумнарында дәвалап, терелтә. Аякка баскач, Сафи олау белән кире китә, Бари янына юл ала. Аңынчы инде бер ай узган була. Килсә, Бари ачтан үлгән, яхшы хром итекләрен, яңа күлмәген кигән дә үзе казыган алтын чокырына сикергән. Юкса, естә калса, аны селәүсен-аю ботарлаган булыр иде. Сафи Барины гүргә иңдерә... Бу турыда урыс матбугатында язылган... мин Колымада чакта, 1974 елда Сафи абзый әле исән иде, диделәр. Биш йөз чакрым араны бара алмадым, ул легендар шәхесне күрә алмадым. Аңа якынча сиксән дүрт яшьләр чамасы булгандыр... Русиянең иң затлы һәм иң арзан юл белән табыла торган алтын ятмаларын, күрәсез, татар кешесе — Бари абзый ачкан. Хәзер ул алтын приискасы «Борисконо» дип атала да. «Бари» исеменнән килә. Күптән түгел Бари абзыйның гәүдәсен үз исемендәге әнә шул приискага күчереп җирләделәр. Кабер өстенә ядкяр ташы да куйдылар. Бик олы тантана ясадылар. 1978 елда булды бугай бу хәл. Анда мәңгелек туң. Бари абзый бүген үлгән кебек иде, диләр күргән кешеләр. Күлмәге дә ап-ак, чип-чиста, хром итекләре дә саф килеш сакланган. Чырае да геп үзгәрмәгән икән.

— Авыр туфрагы җиңел булсын! Татарлар күп идеме алтын тирәсендә?

— Бар... Алтын юучылар әртилен төзегәндә нәчәлникләрнең үз ысулы була. Әйтик, әртилдә егерме-утыз кеше эшли. Иң беренче кайсы милләттән икәнеңне сорыйлар. Татарларны шундук алалар. Кавказ, Урта Азия кешеләрен бик теләп алмыйлар, алсалар да алар йөз сынау аша узарга тиеш. Бу халыклар алтынны яшереп, урлап сатудан курыкмый. Татар алтынга кагылмый ул. Татар закон бозудан курка. Апа калса, тотыла. Татар хөкүмәт түләгәнгә риза булып, җене өзелгәнчә карусыз эшли.

— Кеше аяк басмаган тайгага килеп кергәч, иң башта эш нидән башланды?

— Юл салыр өчен урманны теодолит дигән прибор белән ярып визирка ясыйсың. Әнә шул тәз ярык, сукмак — визирка дип атала. Без якташым Миңнулла Насыйбуллин белән икәү булачак олы юл өчен урман ярдык. Без ярган эздән Дебин-Сенигория юлы салынды.

— Чынлыкта син бу эшнең пионеры икәнсең бит...

— Аннан соң нәкъ шул юл буеннан Спорный-Дебин-Сенигория электр трассасына баганалар утыртып, чыбык суздык. Үзебез электрик та, бульдозерчы да, җир казучы да. Бу эштә мин өч ел эшләдем дә, алтын юарга киттем. Якташым Әсхәт чакырды. Дебин пүчинкәсеннән 17 чакрымераклыкта «Труд» әртиле алтын юа иде. Яхшы сыйфатлы алтын юалар иде анда. Бер граммын без хөкүмәткә бер сум егерме җиде тиеннән тапшырсак, сатуда шул алтынның бер граммы кырык сум иде. Алты бульдозер, 30 кеше алтын юабыз. Өч-дүрт алачык-чатыр. Брезент ашханә, утыра-ята торган җир — киртә, бүрәнә. Алтын юу май аеннан башланып, сентябрь беткәнчә дәвам итә.

— Алтынны ничек казыйлар, ничек итеп юалар?

— Алдан разведка йөри. Ул җирне бораулап, алтынның барлыгын, күләмен үлчи. Алтын ятмалары кыялар арасыннан ага торган инеш төбендә, инешнең ян-якларында, җир астында була. Разведка иллешәр метр ара калдырып, җирне бораулый, балчыкны ала, алтын микъдарын билгели. Һәр казылган тишеккә, квадрат метрга ике грамм, квадрат метрга илле грамм алтын, дип билге куеп китәләр. Алтынлы җирдәге агачлар аударыла, бульдозерлар алтынсыз катламны елгадан читкә эттерә. Ауган агачлар шунда чери. Шул чыршы, нарат, имәннәрне турап, төзү материаллары, ягулык итү турында уйда да юк. Алтын планын үтәргә кирәк.

Берничә метр өске катны ачып, алтын катламына җитәбез. Анысы «ыспай» дип атала. Ягъни алтын ябышып каткан туң катлам. Шуннан соң алтын юу иләге куела. Иләк — ул тимер бункерга, тимерче күрегенә охшаш нәрсә. Яткызып куелган иләккә бульдозер алтынлы балчыкны эттереп кертә. Көчле басымлы насослар шул бозлы балчыкны юдыра башлый, ялгашның төбе тишек-тишек итеп эшләнгән, пычрак су агып китә, алтын борчаклары тишектән астагы резин паласларга төшеп кала. Аста шундый унбишләп келәм була. Баштагы өч-биш келәмгә алтын күп җыела, иләктән ерагайган саен алтын азая бара.

— Йодрык-йодрык табигый алтын кантарлары табыла, диләр. Хәтта Мәҗит Гафури ат башы чаклы алтын табылганы турында да язып калдырган.

— Ат башы чаклысы булмас, мин хәтта йодрык хәтлесен дә күрмәдем. Үзем тапкан иң зур алтын ярты килолап иде. Ул шырпы кабы чамасы зурлыкта иде. Ул вакыттагы акча белән йөз алтмыш мең сум, ягъни гомереңә җитәрлек байлык.

— Нишләттең инде ул алтын кантарын?

— Колодага ыргыттым. Актарылачак чокырга.

— Ни өчен?

— Менә мин алтын кантары таптым, дип, кантурга илтсәң, сиңа граммына 20 тиен түлиләр. Яшерергә ярамый. Шул 20 тиен өчен пычранасым килмәде. Аннан соң син ялгыз гына тапкан алтын кешеләрне шикләндерә. Ялгыз тапкан алтынның акчасын алу янәшәдә эшләүче иптәшләреңнән өлешенә керү булачак. Икенче көнне шул алтын кисәген без әртил белән эшләгәндә таптык.

— Алтын урлап тотылучылар була идеме?

— Булмыймы соң? Тотсалар, аталар. Әз күләмдә урлаган булса, имгәтеп, зинданга ташлыйлар. Аннан чыкканда син инде кеше булмыйсың.

— Ничек тотыла инде алар?

— Алтын юучылар арасында әләкләүчеләр була. Кайберләре юри котыртып урлатырга мөмкин. Котыртканы — котыла, урлаганы — тотыла. Бу — бер ысул. Икенчесе, әйтик, урланган алтынны берәрсенә саттың, ди. Ул аны үз иленә озата, тегеләре исә чит илгә алып чыгарга тырышачак һәм тотылачак. Бер инеш төбеннән табылган алтын төсе, сыйфаты белән янәшәдә генә ага торган инеш алтынына һич охшаш булмый. Кайда, нинди алтын чыкканлыгы турында КГБ, ОБХСС кулында таблица бар. Җәһәннәмдә дә бу алтынның кайсы илдә, кайсы якта, кайсы елгада табылганын белеп була. Эзләп киләләр, әртилгә килеп тереләләр. Әртилдә 20-30 кеше. Табалар. Бер кавказ кешесе тайгада бәрелеп үлгән иде. Туганнары килеп, аны калай табутка салып алып кайтып китте. Магадандагы аэропортта табутны ачтырганнар — 20 кило алтын. Икенче берсе, Мәскәү кешесе, туганнарына бүләк җибәрәм дигән булып, курчак эчләренә, төенчекләренә алтын салып, очучыларга тапшыра торган булган. Мәскәүдә бүләкләрне ышанычлы кешесе ала барган. Шулай итеп, ул җитмеш кило алтын озаткан. Барыбер тотылды.

— Тайгада, Магаданда алтын бетеп барадыр инде?

— Алтынның чуты-кырые юк, Батулла. «Бишьеллык» исемле инешнең озынлыгы 20 чакрым чамасы, шуннан җәмгысе биш тонна алтын алдылар. Табылмаган, табылса да, яшерен тотыла торган алтын ятмаларының хисабын кем алган? Ләкин хәзер бу эшләр шикле кешеләр кулына кереп бара.

— Алтын тауларын күргәнең булдымы, һич югы алтын кешелен?

— Бервакыт прииск нәчәлнигe кайгыга калган, җегетләр. Мәскәү алтын таләп итә, план үтәлмәгән, коткарыгыз, ди. Өч тартма аракы китерт, шәп кабымлык, ди безнең әртил башлыгы, бер көндә планыңны үтибез. Тинька пүчинкәсе ягында бер гәүлеккә 78 кило алтын чыкты. Бу — кеше ышанмаслык рекорд иде. Ул алтын өеменә баксаң, күз камаша. Ләкин бер кеше дә бер генә бөртек тә алтын алмады. Кантурга тапшырдык.

— Чирек гасыр алтын типкәләп йөри торгач, гомерлеккә җитәрлек мая туплагансыңдыр инде...

— Бер якташым 30 ел алтын юып, йөз егерме мең сум акча җыйган иде. Ул акчага яхшы фатир, шәп дача, гараж салып, тагын ун «Волга» алып була иде. Перестройка барысын да яндырды. Минем ул кадәр күп түгел иде, шулай да тернәкләнерлек акчам бар иде. Мин дә акча көле янында утырып калдым.

— Шулай итеп, алтын җәһәннәмендә еллар буе иза чигеп, син буш кул белән кайттыңмы?

— Алтын юучылар арасында киң таралган мәзәк бар. 30 ел алтын казып, берәү авылына, карт анасы янына кайтып төшә. Җылашып-күрешкәннән соң, әнисе — карчык, улым сыртыңдагы ул биштәреңне салып куй инде, ди. Улы, сагышлы елмаеп, биштәр түгел ул, әни, бөкре, ди.

Шулай да мин бер йөк машинасы бер «Жигули» алып калдым.

— Хәзер Казанданиләр майтарасың?

— Иске генә бер йорт сатып алып сипләдем. Аллага шөкер, бүгенге көндә үз гамагымны үзем туйдыра алырлык хәлдә мин...

Татаргамы соң байлык! Ач татарның итәгенә бер уч бодай салсаң.. анысын да түгеп бетерә, ди.

Нефть өстенә басып йөри татар, саф алтын өстенә басып йөри татар — үзе һаман ыштансыз. Бер Зиннәт кенәмени ярык тагарак янында калган! Бөтен милләт шулай бушка эшләде, рәхмәт урынына нәләт алды.

— Шул кирәк сиңа, мәхлук татар! — дияргәме ачылып, әллә сәламәт сеңерләре өзелеп беткәнче эшләп тә, гарип-хәерче калган бу халыкны кызганыргамы?

Үкереп җылыйсылар килә шундый чакларда...

Әңгәмәне **БАТУЛЛА** оештырды.

Дудаевта күпме атом-төш коралы бар?

Зәки Лотфулла улы Зәйнуллин. Отставкадагы полковник. Техник фәннәр докторы. Иркутски хәрби авиация училищесын тәмамлаган. Семипалатински полигонында өйрәнү үткән. Оборона министрлыгының 12нче баш идарәсендә эшләгән (белгечлеге — атом һәм водород бомбалары). Ригадагы хәрби ракета училищесында укыткан. Каты ягулык зарядларының ныклыгы буенча докторлык диссертациясе яклаган. Совет Армиясендә 36 ел хезмәт иткән. Хәзер Казанда яши. Татарстандагы милли хәрәкәт лидерларының берсе.

Шалидагы база — пейзаж элементы

1992 елның августында Зәйнуллин татар Милли Мәҗлесе исеменнән сөйләшүләр алып бару өчен Грозныйга килә. Анда ике көн булуы турында ул «Идел» журналында болай дип яза:

«Дудаев миңа мөрәҗәгать итте:

— Мин сезгә Русия гаскәрләре ташлап калдырган коралны күрсәтермен. Алар арасында атом һәм водород бомбалары да булырга мөмкин.

Вертолет белән Шали янында урнашкан хәрби базага очтык. Җәүһәр болай дип сөйләде:

— 1949 елда монда Мәскәүдән бер генерал килә. Тау башына менеп җиткәч, аңа: «Бу Ичкерия бәгырендәге иң матур, иң уңайлы урын», — диләр. Генерал исә: «Бик тә яхшы. Монда хәрби база булдырырбыз!» — дип җавап бирә.

Бинаның тимер капкасы яхшылап эретеп ябыштырылган. Сак юк. Дудаев өмере буенча капканы тимер кискечләр ярдәмендә ачтылар. Эчтә ни генә юк! Танклар, БТРлар, тягачлар...

Минә өч автокран кызыксындырды. Болар — стационар краннар булмаганда кырда атом һәм водород бомбаларын күтәрә-төшерә торган махсус машиналар.

Йөри торгач, мин җирдә аунап яткан күн тоткычлы, сигез кырлы һәм өллә ни калын булмаган өрҗәгә игътибар иттем.

— Бу, Җәүһәр, атом бомбасы шартлаткычлары өчен кечкенә генә махсус контейнер, — дидем мин. — Менә, кара, монда 32 тишек бар, һәркайсында берәр шартлаткыч.

Аннары брезент чехол капланган тягач янында туктадык. Чехолны салдыргач, тягачның тәгәрмәчләренә басып аягүрә эшли торган махсус мәйданчыкка менеп бастым. Тикшерәм. Тягач өстендә өч тактик ракета ята. Каты ягулык белән эшли торган бу ракеталар 200-300 чакрым ераклыктагы объектларны юк итүгә исәпләнгән. Алар үз күчәрләре тирәсендә әйләнеп очалар. Җә, карап карыйк, бомбалар ракета головкаларына тоташтырылганмы? Юк, берсе буш күренә. Ашыккан вакытта бомбасын алып ыргытканнар, киселгән кабель шул турыда сөйли. Люк та «ите белән» каерып алынган.

Нинди дә булса бер таяк бирүләрен сорадым. Шундук себерке китереп тоттырдылар. Аны бомба корпусы эченә тыгам. Буш.

Калган ике атом бомбасына кагылмаганнар. Корпуска сугып карыйм. «Диагноз» шундый: икесе дә СГ-1 хәлендә (хәзерлек дәрәҗәсе № 1). Икенче төрле әйткәндә, барысы да үз урынында, шартлаткычлар койләнгән. Хәзер үк эшкә җигәргә мөмкин!

— Президент әфәнде! Менә сезгә ике бомба! — мөйтәм. — Рәхим итеп алыгыз!

— Яхшы, Зәки ага, син аларның атом бомбалары икәнен ничек дәлилли аласың?

— Кара! Күрәсеңме, корпуска 120 градус почмак белән Пито трубкалары куелган.

— Әйе. Мондый трубкалар һәрбер самолетта бар.

— Дөрес. Алар нәрсә өчен, дип уйлыйсыз?

— Самолетның тизлеген үлчәр өчен.

— Ә бу трубкалар ярдәмендә бомбаның нинди биеклектә шартларга тиешлеген билгеләләр. Гадәти бомбаларда мондый трубкалар юк.

— Тагын нинди дәлилләр китерә аласың?

Металлга суккалап, люкларны тикшерә торгач, тиздән үземне кызыксындырган нәрсәне эзләп таптым.

— Бомба эченә дым үтеп кермәсен һәм кинәт температура үзгәрмәсен өчен корпуска 5 атмосфера басым белән гелий тутырыла, — дидем мин, люктагы болтларны бушатып. — Хәзер менә бу люктан гелий газы чыга башларга тиеш.

Шулай дип әйтүем булды, люктан чыҗылдап кысылган газ чыга башлады.

— Борып куй тизрәк! — диде Җәүһәр, елмаеп. — Тизрәк, юкса шартлый хәзер.

Икебез дә көлеп җибәрдек».

«Ике бомба»ның дәвамы бармы?

Зәки Зәйнуллин белән без Казанда очраштык.

— Ике бомба турындагы әсәрегез иң кызык урында тәгәлләнә. Аннан соң нәрсә булды? — дип сорадым мин.

— Җәүһәр минем каршымда ук корпусларның номерларын, атом бомбаларының индексларын язып алды һәм Президент Ельцинга хат җибәрде. Эчтәлеге якынча менә мондыйрак: «1991 елда Чечнядан чыгып качкан вакытта, сезнең гаскәрләрегез кайбер нәрсәләрен онытып калдырганнар. Әйдәгез, очрашыйк, сөйләшик, килешик». Әмма аңа җавап хаты килмәгән.

— Өч ел вакыт узганнан соң сездә Шалида күргән нәрсәләргә карата шик тумадымы?

— Юк, алар чыннан да атом бомбалары иде. Мин стратегик корал буенча белгеч. Тактик корал буенча белгеч булмавым аркасында кайбер детальләрдә ялгыш ихтималым булса да, төп нәрсәләрдә ялгыша алмыйм.

— Алайса, әйдәгез, снарядлар характеристикасы турында сөйләшүгә кайтыйк.

— Аларны «Марс» һәм «Ай» дип атыйлар. Каты ягулык белән эшлиләр. Соры төстә. Куәтә 0,15 мегатонн, диаметры 1, озынлыгы 8-9 метрга кадәр. Шалида укыту-өйрәтү үзәге дә бар. Анда атом снарядының макеты урнаштырылган. Дөрес, очучылар үз карамакларына нәрсә тапшырылганын һәрвакыт белеп тә бетермиләр. Мин моны самолетларга хезмәт күрсәткән элекке техник-механик һәм инженер-механик буларак әйтәм.

— Сез Дудаев белән тагын очраштыгызмы?

— Очраштык. Икенче очрашу тагын да кызыклырак булды. Шул ук 1992 елның ноябрендә ул мине бәйсезлекнең бер еллыгына чакырды. 9 ноябрьдә тантаналы җыелыш булды. Ә 10 ноябрьдә Назрань ягыннан Русия танклары керә башлады. 20 гә якын танк Грозныйга керәсе урында, Урус-Мартан янында шосседан тауларга таба борылды. Без Җәүһәр һәм аның куркынычсызлык министры белән шунда юнәлдек. Генерал картасына күз салабыз. Моннан ерак кына түгел бер урында (Бамутта) хәрби гарнизон булган икән. Дүрт катлы йортлардан торган бу хәрби шәһәрчектә хәзер чичәннәр яши иде. Техпозицияләргә чыгабыз. Менә тикшерүләр стендлары, махсус стеллажлар, дивардагы «Сөлтеле аккумуляторлар» дигән язу. Кислоталылардан аермалы буларак, болары атомлы һәм водородлы зарядларда кулланыла. Анда «Сыек һәм газ хәлендәге гелий» дигән язу да бар иде. Бу матдәнең нинди максатларда кулланылуы турында мин язган идем инде.



Атом запасы Ичкериядә сугыш башлануга сәбәп булмадымы?

Чичәннәрдән: «Монда җирле кешеләр арасыннан хезмәт итүчеләр булдымы?» — дип сорагач, бер карт чичәнне китерделәр. Бетон юл кая илтә, плитәләрне кая алып ыргыттылар, дигән сорауга ул юлның юнәлешен күрсәтеп бирде. Бездән 5-6 чакрымда урыслар ташып бетерергә өлгермәгән бетон плитәләр өелеп ята икән. 1991 елда бу юлны маскировкалау өчен анда чирәм чәчкәннәр. Уңда зур кран күренә. Төп-төзек, энергетикасы гына алынган. Барча детальләре һәм трослары солидол белән майланган. Якында гына корыч ишекле җир асты юлы бар. Эченә ком тутырылган мондый корыч ишекләр шариклы җайланмаларда хәрәкәт итәләр. Тагын да алдарак әйләнәсе биш йөз метрга җиткән аланлык ята. Шунда рельсларда зурлыгы 6-8 метрлы чуен «капкачлар» тора. Алар астында кимендә өч җир асты ракетасы булырга тиеш. Бу ике баскычлы стратегик ракеталар базасы булган, мөгаен. «Хуҗалар» кире кайтырга уйлыйлар, ахры, юкса, барча юлларны, «капкачларны» һәм кранны шартлаткан булырлар иде, дим Дудаевка. Алар бит кранны майлап та куйганнар әле. Гомумән, бу безне нык уйга калдырды.

Җәүһәр бик борчыла башладымы, кызып китеп, бөтен җир асты юлларын да ачарга өмер бирде. Әмма мин аны туктатып калдым: «Ә сез, генерал, аларга мина куелмаганлыгына ышанасызмы соң?» — дидем. Вакыт бетеп бара, кире кайтып китәргә кирәк иде.

— Зәки Лотфуллович, әйтелгәннәргә йомгак ясыйк инде. Сезнеңчә, хәзер Ичкериядә күпме атом коралы бар?

— Заманында яртылаш җир астында урнашкан биналарның берсендә (Чернобыль янындагы база) 100-150 бомба саклана иде. Бер базада өч-дүрт бүлек булганын исәпкә алсаң, анда 600гә якын атом бомбасы да сакланырга мөмкин. Монда мин Грозный янындагы атом-төш кораллары базасын күздә тотам (Грозный — 20, 12 ГУМО хәрби часте). Аңа матрос формасындагы хәрбиләр хезмәт күрсәтә иде. Кырымдагы Акборын базасына һәм Мурманскидагы базага да шундый ук хәрбиләр хезмәт күрсәтте. Продукцияне турыдан-туры заводтан алып китеп, аның торышын тикшерәләр, контейнерларга салып, махсус режимда саклыйлар иде. Мондый запасны кире алып китү өчен бер километрлы автомобильләр колоннасы кирәк. Ул Назрань яисә Махачкала ягына юл тотарга тиеш. Бу колоннаны күрмичә калу мөмкин түгел. Без фараз кылган бомбаларга Бамуттагысын (30лап бомба) һәм Шалидагысын да (2 бомба) өстәп куйсаң...

— Нигә нәкъ менә Ичкериядә шуның кадәр корал сакларга кирәк булды соң?

— Совет хәрби доктринасын исегезгә төшерегез. Көньяк группа өчен корал арсеналын кайда тотарга кирәк? Мөселман Урта Азиясе ышанычсыз, носарилар Әрмәнстаны чик буена якын тора. Ә Ичкерия артында — носарилар Грузиясе Шуңа күрә дә ул идеаль база булырга тиеш иде.

Генерал үзенең хәнҗәрен кемгә ышанып тапшырыр?

— Дудаевны кем коралландырды, дигән сорау тирәсендә күпме гәп куертылганын хәтерлисезме?

— Русия армиясе һөҗүм итәр алдыннан, чичәннәр корал складларын үзләре ачтылар. Аңа кадәр Җәүһәр Югары Совет аша чичәннәр үз ватаннарында хезмәт итәргә тиешләр, дигән карарны гамәлгә кертергә өлгергән иде. Якынча менә болай килеп чыга инде батальонда өч рота, аларның берсе тулысынча чичәннәрдән тора. Алар читтән килгән хезмәттәшләренә: «Коралыңны калдыр да, яхшылык белән китү ягын кара», — дип әйттеләр. Аннан соң инде армия кача башлады. Автоматларны гына түгел, башка төр коралларны да ташлап качтылар.

— Зәки Лотфуллович, хәрби кеше буларак, сез атом-төш коралы белән сак эш итәргә кирәклеген яхшы беләсез инде...

— Сез миннән Ичкериядә тиешле профильдәге белгечләр бармы, дип сорарга телисез инде... Әйе, бар, андый белгечләр. Әле күптән түгел генә мин кайдадыр, атом бомбасын шартлата да белергә кирәк, дигән сүзләрне укыган идем. Нигә мәсьәләне шулай катлауландырырга? Инде бер дә булмаганда, аны самолеттан да ыргытырга мөмкин бит. Үз куәтенең 20-30 процентын чыгарачак атом бомбасы. Хәтта АПР да (авария вакытында шартлаган ракета) 12шәр процент радиация, яктылык нуры һәм удар дулкын бирә ала.

Борис ВИШНЕВСКИЙ.
Казан.
(«Комсомольская правда»).

Җөй коне «Гринпис» Русия территориясендәге атом-төш кораллары саклана торган базалар турында мәгълүмат биргән иде. Докладта Чечнядагы сугыш хәрәкәтләре барган бер җирдә Русиянең стратегик бурычлы ерак авиация базасы урнашуы турында хәбәр ителә. Моздокта 316 атом-төш боеголовкасы белән коралланган ТУ-95 бомбардировщиклары урнашкан булган.

Бу мәгълүмат халыкара җәмәгатьчелекнә куркуга салды. Чөнки ул Буденновскида булган вакыйгалардан соң гына билгеле булды. Дөрес, «Гринпис»ның Русия вәкилләре әлеге докладны әзерләгәндә 1992 елгы мәгълүматларны файдалануларын яшермәделәр. Тикшерү барышында шунысы ачыкланды: 1995 елның гыйнварында дудаевчыларны ике сәгать эчендә парашют-десант полкы гына түгел, Русия армиясе дә җиңә алмаячагы аңлашыла башлагач, атом-төш боезарядлары Энгельс шәһәрендәге авиабазага күчерелә. Бу турыда безгә Русия Хәрби һава көчләре командованиесенә якын торган кеше хәбәр итте.

Бомбардировщикларның дислокация урыны үзгәртелүе бәхәссез. Моздокта һәйкәл сыйфатында (ул постаментка куелды) бер ТУ-95 калды. Ә инде Русия армиясендәге хәзерге дисциплина дәрәҗәсен исәпкә алсаң, барча атом-төш зарядларының да башка урынга күчерелүенә шик туа. Хәер, бу сорауга тәфсилле аңлатмалар алу җиңел эш түгел: атом-төш зарядларына хезмәт күрсәтүче белгечләрне авиациядә «телсезләр һәм чукраклар» дип атыйлар.

Сергей ПЛУЖНИКОВ.

АТНАЛЫК МАНЗАРА TV

ДҮШӘМБЕ

11 ДЕКАБРЬ

Саба, Кукмара, Шәмәрдән, Әбде һәм Чепья төбәкләре телевизор караучылар игътибарына!
13, 14, 15 декабрь көннәрендә элемтә чараларына капиталь ремонт үткәрелү сәбәпле, «Санкт-Петербург» каналы тапшырулары иртәнге 8дән кичке 5 нче яртыга кадәр трансляцияләнми.

«ТАТАРСТАН»

7 00—8 00 «Чулпан» информацион программасы 18 10 Мультфильмнар 18 45 Балалар өчен «Тамчы» (Ютазы районы) 19 00 «Татарстан» 19 30 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19 40 «Дәһлидә ярминкә» 20 05 «Әлли-бәлли-бәү» 20 15 «Күзгә-күз — сүзгә-сүз» Академик Индус Таһиров 21 00 Халык моңнары 21 15 Нәфис фильм премьерасы «Победа любви» 1 нче серия 22 45 «Сайлауларны каршылап» «Җаваплылыкны үземә алам» 22.55 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10. 18 50 — «Эфирда — музыка» 7 30 Тамаша залы 8.00 «ПОСТ» — музыка яңалыклары 8 15, 9 10 — «Юл патрулә» 8 30 14 45 — «Даруханә» 8 40 «Мине сайла» 9 20 12 55 — «90х60х90» 9 35 Балалар сеансы «Самый сильный» 11 00 Юмористик сериал «Один к десяти» 11 25 Атна фаразлары 11 55 Сериал «Мстители» 13 10 Нәфис фильм «Свечи во мраке» 15.00 Динле кешенең тантаналы тавышы 15.30 Сериал «Флиппер» 16 25 «Минем кино» Никита Михалков 19 00 Сайлаулар читтән караш 19 20 «Лариса» яңалыклары 19 50 «Кыюлар һәм матурлар» 20 20 23.05 — «Шәһәр» информацион программасы 20 45 Видеомода 21 05 Тапшыру премьерасы «Кстати» 21 15 Телеэкспресс. 21.35 Криминаль хроника тележурналы. 22 05 Вивьен Ли «Анна Каренина» фильмында (Бөекбритания) 23.30 Телесериал «Особое подразделение» 3 нче фильм «Месть»

1 НЧЕ КАНАЛ

7 45 9 10 «Уяныгыз!» телеканалы 8 45 «Пастырь сүзе» Митрополит Кирилл 9 00 15 00, 18.00, 23.35 — Яңалыклар 10.30 Балалар өчен күңел ачу программасы «Оттырма» 11 00 Иртәнге почта 11 35 «Төмле» 11 50 «Кеше һәм закон» 12 20 «Бомонд» 12 40 Мультфильм 12 55 Нәфис фильм «Дама с собачкой» 14.30 15 20 — «Кайту» 15 50 Хайваннар дөньясында 16.30 Америка М Таратута белән 17 00 «Шулай бервакыт ..» 18 25 Мультфильмнар 19 00 «Т С Н» телесериалында мажара эзләүчеләр 20 45 «Тыныч йокы «Нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 45 Алла Пугачева «Жди и помни меня» сериалында 1 нче серия 22 50 «Аңа кадәр һәм аннан соң» 23 50 Нәфис фильм «Человек из мрамора» 2 30 Музыкаль программа. «Урыс кадаклары» 3.05 Телефильм «Голубой карбункул»

«РУСИЯ»

8.00 14.00 20 00. 23 00 — «Хәбәрләр» 8 25 «Йолдызнамә» 8 30 «Вовкулакия яки Доктор Никодимның табышмагы» 8.45 «РОСТ» компасы 9 00 Балалар өчен телесериал: «Одиссея» (Канада) 9 25 «Алтын ачкыч» 9 45 «Әдәплелек» 9 55 Сәүдә йорты «Ле Монти» 10 00 Парламент атнасы 10 45 Карьера 11 15 «Ничек яшибез?» 12 00 «Пилигрим Русиянең сәяхәтләр бюросы» 12 45 НБАның иң яхшы уеннары 13 45 «Кайнар Уңлык» 14 20 «Де-факто» 14 35 Өй экраны «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм «Покойный господин Галле» 15 25 «Биш катлы йортлар турында баллада» 1 нче тапшыру 15 55 «Беренче нөсхә» 16 05 «Англетер» кунакханәсе серләре» 1 нче тапшыру 16 35 Футболга чикләр юк 17 20 Санкт-Петербург балеты 18 55 Күп серияле документаль фильм премьерасы «Битлз» Великая четверка 20 25 В Дэвис, П Устинов Э Тэйлор «Смерть на Ниле» фильмында (Бөекбритания) 22 45 Һава торышы 23 40 «299-00-00» хезмәте 23 55. 1 26 — Телеэкран премьерасы Нәфис фильм «Одна на миллион»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

10 00 Яшәү стиле 10 20 Телефильм «Тайна пирамид» 11.15 «Минем музыка» Игорь Наджиев «Грим белән һәм гримсыз» 11 50 Овертайм 12 05 Теледоктор 12 25 Тарихи альманах 12 55 18 00 23 00 — «Төбәкара телевидение Телекупер» 16 05 «Иң дәрәҗәле кешедән» 16 20 «Гыйбадәтханә» Владыка Иоанн хатирәләре» 16 40 «Декабристлар йортында шәмнәр кабынып» Декабристлар восстаниесенең 170 еллыгына 17 15 «Битлз иленә хисле сәяхәт» 22 00 Музыкаль-шоу «Телекомпакт» 23 15 Нәфис фильм «Дом на Кэррол-стрит» (АКШ)

СИШӘМБЕ

12 ДЕКАБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 00—8 00 «Чулпан» информацион программасы 17 50 «Җыр — ул бәйрәм!» Балалар җыры конкурсыннан 19 00 «Татарстан» 19 30 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19 40 Документаль фильм 20 00 Нәфис сүз кичәсе 20 15 «Әлли-бәлли-бәү» 20 30 Рәшит Сөләйманов җырлый 21 00 Телесериал премьерасы «Вспышка» 6 нчы серия 22 30 «Сайлауларны каршылап» «Русия язмышлары тан да олы» 22 40 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 «Эфирда — музыка» 7 30 220 20 23 35 — «Шәһәр» информацион программасы 7 55 Телеэкспресс (11 декабрь тапшыруын кабатлау) 8.15 11 20 17 30 — «Юл патрулә» 8 30 11 45 — «Даруханә» 8 40 «Мине сайла» (MTV) 9 10 13 00 — «90х60х90» 9 30 Мультфильм «Аленький цветочек» 10 15 «Минем кино» Никита Михалков 10 55 Юмористик сериал «Один к десяти» 11 35 16 45 — «Атна һәлакәтләре» 12.05 «Кызык өчен генә түгел» Геннадий Хазанов 13 15 Нәфис фильм «Не могу сказать прощай» 15 00 «Динле кешенең тантаналы тавышы» 15 30 «Төгәләр кемнәр » 15 50 Музыка һәм матбугат «Каләм осталары» Илья Резник 17 15 «ПОСТ» — музыка яңалыклары 17 45 Диск-канал Глен Хьюз Мәскәүдә 18 10 Гражданнар оборонасы 18 25 Мохит һәм сәламәтлек 18.40 Сериал премьерасы «Лови удачу на лету» 19 40 «14 нче каттан караш» 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20 45 «Коммерция әйләнмәсе» 21 05 Мультфильм «Как Ниночка царицей стала» 21 15 Телеэкспресс. 21 35 Нәфис фильм «Анна Каренина» 2 нче серия (Бөекбритания) 23 00 Русия киносы көне Нәфис фильм «Холод»

1 НЧЕ КАНАЛ

7 30 «Иртә» 9 00 15 00 18.00 0 20 — «Яңалыклар» 9 15 Мультитроллия 9 45 Фильм-әкият «Иван да Марья» 11 10 Константиново авылы җырлары 11 40 Мультфильм 11 55 Фильм-спектакль «Мещанин во дворянстве» 14 25 Фильм «Честь имею» 15 20 Автомобиль һәм мин 15 40 Фильм «Зеркало для героя» 18 20 Мультфильм 18 50 КВН-95 20 45 «Тыныч йокы нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 45 Алла Пугачева «Жди и помни меня» сериалында 2 нче серия 22 50 Олег Табаков белән биш кич 0.00 «Мәскәү-Кремль» 0.35 Сериал «Т С Н.» 1 30 Спорт биюләре буенча Спартак Халыкара ачык кубогы 2.30 Хит-парад

«РУСИЯ»

8.00. 14 00 20 00 23 00 — «Хәбәрләр» 8.25 «Йолдызнамә» 8 30 Мульти-пульти «Царевна-лягушка» 9 00 Балалар өчен телесериал «Одиссея» (Канада) 9.25 Провинция җәүһәрләре «Изге Тобольск шәһәренә кайту» 9.55 «Тынлыкта җиде нота» 10 25 Уенсыз киноның ачык фестивале «Үзегезгә күз салыгыз » 10 55 Галина Преображенскаяның «Чакыру билеты» 11 25 Э Гаррин «Обыкновенное чудо» фильмында 13 20 Информацион-әдәби программа «Фаэтон» 13 50 Клип-антракт В Меладзе О Газманов 14 20 Нәфис фильм «Мы из джаза» 15 50 «Биш катлы йортлар турында баллада» 2 нче тапшыру 16.20 «Тайны животных» телесериалыннан документаль фильм «Акула» (Бөекбритания) 17 15 Петербург сезоны 17 45 Русиянең телевизион театры «А чой-то ты во фраке?» 19 00 Клип-антракт Д Лирк А Аивазов 19 10 «Л» клубы 20 25 Нәфис фильм «Жестокий романс» 22 45 Һава торышы 23 30 «Вакыт елгасы» 23 35 «Автомизгел» 23 40 «299-00-00 хезмәте» 23 55 0 25 — Футбол буенча 1998 елгы дөнья чемпионаты турнирына сайлап алу өчен жирәбә салу Париждан тапшыру

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

10 00 Яшәү стиле 10 15 Мультфильм «Небесный дар» 10 30 Нәфис фильм «Открытые двери» (Италия) 12 20 Фильм премьерасы «Опыты гражданской войны» 13 30 Балет сөючеләр хөрмәтенә 14 50 Телефильм «Машина моды» (Франция) 16 20 Буи-буй хит 16 55 Нәфис фильм «Между нами девочками» (АКШ) 22 15 Фрэнк Синатрның 75 еллыгына карата тапшыру 23 00 Нәфис фильм «Игра всерьез» (Украина)

ЧӘРШӘМБЕ

13 ДЕКАБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 35—8 00 «Чулпан» информацион программасы 19 20 «Татарстан» 19 50 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19 55 «Әлли-бәлли-бәү» 20 05 «Татарча сөйләшәбез» 20 15 «Сайлауларны каршылап» 21 00 Лирик концерт 21 15 «Китапка китап» Татарстан Республикасының Милли Китапханәсенә 130 ел тулуга багышлана 21 55 «Пульс» Медицина программасы 22 10 «Яп сәгатендә» 22.55 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

